ЯҢАШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN
ISSN 0130-2410
1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ
ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА
№ 9 (356)
СЕНТЯБРЬ 2021

ТАСВИРЛАУ ГЫНА ҖИТМИ – УКЫРГА КИРӘК!

Әйдәгез, Минтимер Шәриповичтан үзенең яраткан журналлары турында сөйләвен сорыйк!
Ә мин Милли китапханәнең яңартылган бинасын күреп шаккаттым!
Берәр язучы әдәби кафеда китаптагына әзерләнгән нинди дә булса ризык белән сыйласын!
«Минем өйдәге китапханәм» дигән фотопроект та кызыклы булыр иде!»
Сүз уңаеннан, Аккош күлендәге иҗат йортына бәйле хатирәләрне дә барласак була!
Бердәмлектә – көч!



ТАСВИРЛАУ ГЫНА ҖИТМИ – УКЫРГА КИРӘК!

«Татарстан» редакция коллегиясенең яңа командасын җыя. Кабул итү чакырылган мөхәррир вазыйфасы тарафыннан «тикшерү» аша алып барылды. Йөзьеллык тарихын яхшы белгән «Татарстан» журналы үзе белән кайчандыр республикабызның беренче затлары җитәкчелек итүе белән горурлана: тарихта беренче РКП(б) Татар өлкә комитеты секретаре Александр Таняев, ВКП(б) Татар өлкә комитетының беренче секретаре Александр Карпов, ТАССР Халык Комиссарлары Советы Рәисе урынбасары Гасыйм Мансуров, ВКП(б) Татар өлкә комитеты секретаре Мендель Хатаевич… Шуңа күрә беренче чакырылган мөхәррир вазыйфасына без Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыеваны чакырдык. Һәм аның белән бергә бу санныбызның темасын да уйлап таптык. Темабыз Татарстанның тиңдәше булмаган тәҗрибәсе турында. Татарстанның укырга яратмый торган яңа буынында китапка мәхәббәт тәрбияләргә омтылуы хакында. Китапханәләрнең яңартылып, гаҗәеп кызыклы мәйданчыкка әверелүе турында. Россиянең иң күп китап укый торган ил абруен кире кайтарып, дөнья күләмендә беренче урынга чыгарга тырышуы хакында.

– Биредә барыгызны да күрүемә бик шат, – дип сәламләде редакцияне Ләйлә Фазлыева. – Яза белүегез өчен бик зур рәхмәт сезгә! Миңа «Татарстан»ның теләсә кайсы теманы ача белүе, тәмле телле, үткен сүзле булуы, текстларының дөрес язылуы, кызыксыну уятуы ошый. Хәзер бик начар язалар, яңадан җитди рәвештә язарга өйрәнергә кирәк. Һәм моның өчен, әлбәттә, күп уку таләп ителә. Чөнки уку – гаять кызыклы, уку – мавыктыргыч, уку – матур! Немец археологы Людвиг Борхардның патшабикә Нефертитиның бюстын тапканнан соң көндәлегенә язган сүзләре искә төшә: «Тасвирлау гына җитми – күрергә кирәк!» Әйдәгез, бергәләп, «Тасвирлау гына җитми – укырга кирәк!» дип әйтерлек номер ясап карыйк! Журналлар шуның өчен басыла да бит! Китап уку турында уку – санныбызның төп темасы әнә шундый!

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары:
Нияз Әхмадуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Олеся Бондаревская, Ольга Туманская,
Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алина Бакирова
Авторлар: Илдус Зәһидуллин, Катерина Котова,
Ксения Сёмина, Луиза Шарова
Фотографлар: Ната Смирнова, Александр Ефремов
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Игорь Глушков, Олег Бурилов
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Лайсан Һадиева
Тышлыктагы фотода: Дина Юнысова,
Татарстан гүзәле-2021. Рамил Гали фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек
буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы
ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри.
Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә
мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция
җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: Е-3087
Басарга кул куелды: 22.09.2021
Басмадан чыкты: 28.09.2021
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com
Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru
тел.:(843) 222-09-79
Коммерция директоры:
Юлия Фасахова, 89272483384 _pr@mail.ru
тел.:(843) 222-09-76, +7-9272-483-384

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә
тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

**«Татарстан» журналына язылу барлык
элемтә бүлекләрендә кабул ителә**
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе:
960 сум 00 тиен

**«Татарстан» журналына
РФ буенча онлайн-язылу:**
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Калимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фарит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмагыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Калимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

**«ТАТМЕДИА» Республика
матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
ярдәме белән чыгарыла**

**Басма Матбугат
һәм массакүләм
коммуникацияләр буенча
федераль агентлык
ярдәмендә нәшер ителә**

ТАТ МЕДИА
Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

КУЛДАН ЭШЛӘНГӘН «РУБЕНС»

Татарстан Милли китапханәсе тупланмаларында «Петръ Павелъ Рубенсъ» дип аталган уникаль китап саклана. Аның уникальлеге размерында гына да түгел (гадәти форматтагы китаптан дүрт мәртәбәгә диярлек зуррак), хәтта яшендә дә түгел (XIX гасыр ахыры). 240 битлек китап тулысынча – башыннан ахырына кадәр кара белән, кулдан язылган. Әлеге искиткеч авыр хезмәтне Григорий Мешков дигән статский советник башкарып чыккан. Алай гына да түгел, ул китапны француз теленнән русчага да үзе тәрҗемә иткән. Авторның язуы идеаль дәрәҗәдә матур, хәрефләре төз. Автор үзенең хезмәтен – борынгы гравюралар, китап битләрен ул заманда модада булган виньеткалар белән бизәгән. Калын тәпләмәсе дә, әлбәттә, кулдан эшләнгән. Китапны Григорий Мешков 1881 елда Казан шәһәр җәмагать китапханәсенә бүләк иткән.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

4. Үз йөзегезне югалтмагыз!
Журнал журналистларына укучы Шәймиевтән киңәшләр

10. Китап модасының соңгы сүзе
Ничек яңача укырга

14. Кыю яңарышлар
Китапханәләр ничек үзгәрә

16. Китап галәме
Милли китапхананең яңа бинасы

18. Авылдагы үзгәрешләр
Мөслим китапханәсе мич белән интернетны ничек яраштыра

20. Гыйлемле балачак
Казан балалары вакытларын ничек үткәрә ала

22. Бармак башлары аша күрү
Начар күрүчеләр кайда һәм ничек укый

24. Китап алмашу урыны
Мураками китапларын кайдан табарга

26. Кемгә – Монте Кристо, ә кемгә – Вера Фигнер
Татарстандагы иң үзенчәлекле китапларның беренче бишлеге

28. Кунакка!
Кемдә иң бай китапханә

40. Редакция кухнясы
Яшь граф Толстойны Казанда нәрсә белән сыйлаганнар

48. Китапларның киләчәге
Сыйфатлы китап яшәячәк

50. Аккош күле
Шагыйрь Равил Фәйзуллинның дачасында мөгез ничек пәйда булган

54. Илдар Сәгъдәтшин фикерләре
Укучыга таба электрон адым

56. Оптимист галим фаразлары
Кешелек клиплы фикерләүдән котылачак

58. Тарих галиҗәнапләре
Иң борынгы һәм иң кыйммәтле китаплар кайда саклана

66. Уңышны көзен санылар
Корылык эзе...

74. Тарих сәхифәләре
«Галия» мәдрәсәсенә нигез салучы

82. Татар авыллары
Кычытканлы – туган нигезне онытмау

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
protatarstan.ru

Фото: Нурсюя Шайдуллина

БЕР-БЕРЕГЕЗДӘН ӨЙРӘНЕГЕЗ, ҮЗ ЙӨЗЕГЕЗНЕ ЮГАЛТМАГЫЗ!

Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе **Минтимер Шәймиев** типография буяулары исе, кәгазь битләр кыштырдавы, йотлыгып уку һәм татарстанлыларны шушылар белән инде икенче гасыр дәвамында тәэмин итеп килгән Татарстан журналлары турында.

– Безнең буын китаплар, газета-журналлар укып тәрбияләнде, ул заманнарда мәгълүматның, хәзергечә әйтсәк, башка чыганаклары юк иде. Ә күп нәрсә беләсе килә иде! Апам Мәрзия безгә китапларны кычкырып укый һәм алар шулкадәр кызыклы ки, берәр сүзне төшереп калдырмаса ярар иде, дип борчылып утырасың. Шуңа күрә иң зур теләгем – тизрәк укырга өйрәнү. Биш яшьтә мин апамнан хәрефләрне күрсәтеп-аңлатып бирүен үтендем. Әткәй, хәреф тануымны белгәч, мине тантаналы төстә өстәлгә утыртты да кулыма газета тоттырды. Үзе каршымда минем район газетасыннан ниндидер хәбәрне кычкырып укуым белән горурланып, күңеле булып тыңлап утырды. Бәлки шуңадыр, яңа газета-журналлардан, яңа китаплардан килгән типография буяулары исе – балачагымнан калган иң яраткан исләрнең берсе. Бу ис һәрвакыт ниндидер кызыклы, яңа нәрсәләр вәгъдә итә. Ә кәгазь битен кыштырдатып ачып, моңарчы күрмәгән серле дөньяга керәсең...

Мәктәп елларында минем иң яраткан җирләремнең берсе район китапханәсе иде. Китап алыр өчен чиратка язылырга кирәк. Җитди укучы икәнсең – өстәвенә тәртипле кеше дә булырга тиешсең. Әгәр дә ниндидер китапны алгансың икән, аны билгеләнгән көнгә кире кайтарырга кирәк: ни генә булмасын – китапханәгә китереп бирергә бурычлы. Шуңа күрә буранмы, яңгырмы, кармы, юллар начармы – һава торышы нинди булуга карамастан, район үзәге Пучыга, китапханәгә барып җитәсең. Китапны укып бетердеңме – шунда ук илтеп тә тапшырасың. Бары тик шул очракта гына сиңа яңа китап бирәчәкләр. Бу – мәҗбүри шарт, чөнки башка балалар да нәкъ синең кебек үк китап көтеп чиратта тора. Әнә шулай йотлыгып укый идек.

МИНЕМ КАРАШКА, НӘКЪ МЕНӘ ЖУРНАЛ УКЫГАНДА КҮҢЕЛДӘ КҮПТӨРЛЕЛЕК, матурлык хисе туа һәм фикернең җай агышы тоела.

Уку – балачактан килгән һәвәслегем, ул гомерем буена рухи ихтыяҗыма әйләнде. Инде сөйләгәнем дә бар: кайда гына, кем генә булып эшләсәм дә, иртән, беренче эшем итеп, газета һәм журналлар карыйм, республика басмаларыннан башлыйм. Беренчедән, бу – халык белән элемтә. Икенчедән, тирә-якта ниләр булганын белеп тору – минем гадәти халәтем.

Шуңа күрә бүгенге компьютерлар һәм интернет заманында да басма матбугатны өстенрәк күрәм. Интернет киңлекләрендә, социаль челтәрләрдә «яшәүче» яшь буын өчен бу бераз сәер тоеладыр, әмма миңа, чынлап та, чын газеталарны, журналларны, китапларны кулга тотып уку ошый. Безнең буын шулай гадәтләнгәнгә генә түгел. Кулдагы китап дөнья мәшәкатьләреннән читкә китеп, фикер туплаларга мөмкинлек бирә. Шулчакта гына әлеге китапның үзең өчен мәгънәсе-сабагы турында ныклап уйланып була. Компьютерның бертуктаусыз җемелдәп торган экранына карап, үз уйларыңа тулысынча бирелү мөмкин түгел. Өстәвенә, китап укыганда сине һәрвакыт каяндыр чыгып торган реклама да аптыратмый. Синең өчен, мәсәлән, журнал тудырган мавыктыргыч дөньяда тыныч кына сәяхәт итәсең. Мин журнал укырга яратам, республика журналларының барысын да диярлек карап барам. Газеталарның, китапларның, башка басмаларның әһәмиятен киметергә теләмим. Һәрберсенең – үз урыны. Әгәр дә газета – тормышның көндәлек пульсы булса, китап темага, вакыйгага әкрен-әкрен алып керә. Алар бер-берсен алмаштыра алмый, әлбәттә. Минем карашка, нәкъ менә журнал укыганда күңелдә күптөрлелек, матурлык хисе туа һәм фикернең җай агышы тоела.

Ә журналлар бездә күптөрле, кызыклы, һәм шунысын әйтергә кирәк: күбесенең 100 еллык тарихы бар. Алар 100 яшьлек

Татарстан Республикасы мәдәниятенең һәм традицияләренең аерылгысыз өлешенә әйләнгән.

Татар телендә чыга торган журналлардан башлыйм. Аларның хәле хәзерге вакытта бик катлаулы, чөнки барлык һөнәри бурычларыннан ана телен саклау бурычы алгы планга чыга. Бүгенге көндә бу – аларның төп вазыйфасы. Барлык җаваплы затларны моңа игътибар итәргә һәм журналларыбызның әлеге юнәлештәге эшләренә булдыра алганча булышырга өндәр идем.

«БЕЗНЕҢ МИРАС» – ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ МӘДӘНИ МИРАСЫ ХӘЗИНӘСЕ

«Безнең мирас» журналына аерым игътибар бирәм. Ул халкыбызның тиңсез мирасы киңлегендә уңышлы эшләп килә. Мин бу журналны татар халкының мәдәни, шул исәптән сөйләм һәм язма мирасы хәзинәсе, дип атар идем. Аның сәхифәләреннән күренекле галимнәр, тарихи шәхесләр, әдәбият һәм сәнгатьнең уникаль әсәрләре турында күпме файдалы һәм кирәкле мәгълүмат алып була! Акыл сандыгы! Журналның «Мәдәни мирас: борынгы Болгар шәһәре һәм утрау-шәһәр Свияжск» проектын тәмамлауга багышланган махсус саны исә әлеге бөтенхалык проектының дөньякүләм әһәмиятен лаеклы чагылдырды. Бу – мирасны саклау темасына оста һәм тирән мәгънәле юл табу үрнәге. Мәгълүм булганча, 2022 елда ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы комитеты утырышы Россиядә, Татарстан җирендә узачак. Бу исә Татарстанның халыкара дәрәҗәдә тарихи мираска сакчыл карашлы республика булып танылуын аңлата. Бу – безнең уртак казанышыбыз. Әлеге вакыйга «Безнең мирас» журналында лаеклы чагылыш табар, дип ышанам.

Минем карашка, бүген татар журналларының төп вазыйфасы – ана телен саклау. БАРЛЫК ҖАВАПЛЫ ЗАТЛАРНЫ МОҢА ИГЪТИБАР ИТӘРГӘ ҺӘМ ЖУРНАЛЛАРЫБЫЗНЫҢ ӘЛЕГЕ ЮНӘЛЕШТӘГЕ ЭШЛӘРЕНӘ БУЛДЫРА АЛГАНЧА БУЛЫШЫРГА ӨНДӘР ИДЕМ.

«СӨЕМБИКӘ»НЕ УКУ ИР-АТЛАРГА ДА ФАЙДАЛЫ!

«Сөембикә» – «Азат хатын» – безнең әнкәй һәм апаларым журналы. Мин яхшы хәтерлим: алар яңа санның Казаннан безнең бик ерак авылга килеп җитүен түземсезләнеп көтә иде. Һәр санны чиратлашып, йотлыгып, берничә кат укыйлар. «Сөембикә» – хәләл җефетем Сәкинә Шакир кызының да яраткан журналы иде. Аның матбугат белән аралашырга яратмавын күпләр белә, мөгаен. Әмма «Сөембикә» журналының Сәкинә ханым якын иткән һәм берничә тапкыр интервью биргән беренче һәм бердәнбер журнал булуын белүчеләр аздыр. Бу журналны уку хатын-кызларның уй-омтылышларын белергә теләгән ир-атларга да файдалы дип саныйм. 20 ел Президент булып эшләү тәҗрибәмнән чыгып шуны әйтәсем килә: бу журналны ешрак караган саен, көндәлек мәсьәләләрне хәл итү җиңелрәк булды. Чөнки хатын-кызлар проблемаларга җентекләп карый, ә безгә – колачлы фикер йөртергә гадәтләнгән ир-атларга әлеге сыйфат җитенкерәми. Бүген «Сөембикә»не укыганда булдыклы, уңган хатын-кызларыбыз күп булуына гына түгел, журналның булачак киләшләрне, хәләл җефетләрне һәм аналарны





матур гына тәрбияли белүенә дә шатланам. Быел Татарстандагы Туган телләр һәм халык бердәмлеге елына багышланган уникаль кушымтаны кызыксынып карап барам. Әлеге яңа «Дус-күршеләр» проектында укучылар журнал битләрендә республикада яшәүче төрле халыкларга – мари, чуваш, удмурт, төрекмән, грузин, әрмән, мордваларга һ.б. кунакка йөриләр. Шәп идея!

«КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫ – БЕЗНЕҢ ӘДӘБИ КОДЫБЫЗ

«Казан утлары» журналы – безнең әдәби кодыбыз, дияр идем. Татар әдәбиятының очсыз-кырыйсыз дәрьясында юл күрсәтүче ул. Безнең халык талантлы, күп кенә язучылар үз каләмнәрен беренче мәртәбә «Казан утлары»нда сынап карый. Шуңа күрә журналның чираттагы санын һәрвакыт түземсезлек белән көтеп алалар. Чөнки иң яхшы әсәрләр иң элек «Казан утлары»нда басыла, аннан соң гына нәшер ителә. Элек тә шулай иде, хәзер дә бу матур гадәт дәвам итә. Хәзерге вакытта журнал битләрендә хәзерге заман әсәрләре белән классик әсәрләр уңышлы ярашып килә. Бүгенге көндә мондый тигезлек тоту җиңел түгелдер, чөнки укучылар санын да киметмәскә кирәк. Ә укучы талымлы бүген, дөнья ачык – зәвыклар күптөрле. Ә мин, шигърият сөюче буларак, иң элек шигырьләр укыйм, ошаган юлларның астына сызып барам...

«Казан утлары» журналы янәшәсендә Чаллы шәһәрендәге «Мәйдан» журналы да уңышлы гына атлый.

«СӘХНӘ» – СӘНГАТЬ ӘҺЕЛЛӘРЕНӘ РУХИ ЯРДӘМ ҺӘМ ИЛҺАМ

Безнең мәдәният һәм сәнгать шулкадәр бай, ә сәнгать әһелләре шулкадәр талантлы һәм алар, безнең бәхеткә, шулкадәр күп ки, шуңа күрә театр һәм мәдәният тормышын яктырткан яңа, махсус **«Сәхнә»** журналын гамәлгә куюны шатланып кабул иттем. Чыннан да, журнал сәнгать сөюче күпсанлы укучылар өчен генә түгел, артистларның үзләренә дә рухи ярдәм һәм илһам булып тора. Журналның беренче саннары күренекле язучыбыз, драматург Туфан Миңнуллин җитәкчелегендә басылган иде. Журналны бүген дә рәхәтләнеп укыйм һәм Туфан нигез салган традицияләрнең дәвам итүен күрәм.

ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН БАЛАЛАРЫ ҺӘМ МӘКТӘП ДӨНЬЯСЫ ТУРЫНДА

«Яңарыш» Республика фондының «Адымнар» күптелле белем бирү комплекслары булдыру проектын башлап җибәргән вакыттан алып, «Мәгариф», «Гаилә һәм мәктәп», балалар журналлары – **«Салават күпере», «Ялкын», «Сабантуй»** – безнең өчен бердәм төркем тәшкил итәләр. Алар безнең проектны гамәлләштерүдә ярдәм итә, чөнки әлеге журналларда хәзерге заман балалары һәм мәктәп дөньясы турында күптөрле мәгълүмат табып була.

«МӘДӘНИ ҖОМГА» – ЖУРНАЛГА ОХШАГАН ГАЗЕТА

«Мәдәни җомга» газетасын аерым билгеләп үтәсем килә. Минем карашка, эчтәлеге буенча ул журналларга авазлаш һәм кайвакыт аларга үрнәк булып та тора.

«КАЗАН» – БАЛАШОВ ҖИТКЕРГӘН ЮГАРЫ ДӘРӘҖӘНЕ ТОТА

«Казан» журналына һәрчак сокландым, аны республика журналлары арасында иң яхшылардан берсе дип әйтә килдем. Анда акыл өчен дә, күңел өчен дә – барысы да бар. Барысы да укырлык, карарлык, шатланырлык, уйланырлык. Форсаттан файдаланып, журналның беренче мөхәррире Юрий Анатольевич Балашовка рәхмәт әйтәсем килә, ул журналны оештырды







һәм үрнәк дәрәҗәгә җиткерде. 2019 елда «Казан» журналы безнең «Яңарыш» фонды белән берлектә Болгар һәм Свияжск турында махсус сан чыгарды. Эшчәнлегебезнең нәтиҗәләре укучыларга югары дәрәҗәдә – эчтәлекле һәм яхшы бизәлештә бирелүе күңелле булды. Бүген журналны укыганда редакциянең яңа составы Балашов җиткергән югары дәрәҗәне тотуына сөенәм. Миңа аеруча мәркәзебез Казан турындагы тарихи язмалар ошый, күптән таныш урамнар һәм йортлар турында бик күп яңалык беләсең.

РУС ҺӘМ ТАТАР ТЕЛЛӘРЕНДӘ ЧЫГА ТОРГАН ЖУРНАЛЛАРНЫҢ ДА ЮЛЫ КАТЛАУЛЫ, АЛАРНЫҢ НИНДИ БУЛЫРГА ТИЕШЛЕГЕ ТУРЫНДА БӘХӘСЛӘР ТЫНМЫЙ: ЭЧТӘЛЕГЕ БУЕНЧА БЕР-БЕРСЕН КАБАТЛАРГА ТИЕШЛӘРМЕ ЯКИ ҺӘР ТЕЛДӘ АЕРЫМ КОНТЕНТ КИРӘКМЕ. Бу журналларның һәрберсе – «Идел – Идель», «Чаян» һәм «Татарстан» – бу мәсьәләне үзенчә, нәтиҗәле хәл итә. Ничек кенә булмасын, бездә ике телле журналлар популяр, димәк, укучылар бар – нәтиҗә бар.

«ЧАЯН» – ИҖТИҺАДЛЫ ЮМОРНЫҢ ЮГАРЫ ДӘРӘҖӘСЕ

Мисал өчен, **«Чаян»** – ул да балачагым журналы. Ул үзенең кызык рәсемнәре белән җәлеп итә иде. Без аларның күбесен мәктәп газеталарына күчереп ясадык. Бүгенге «Чаян» заман белән бергә атларга тырыша, шул ук вакытта – иң мөһиме – игелекле һәм акыллы юмор традицияләрен саклый. Хәзерге вакытта, һәрьяклап ачык җәмгыятьтә, иҗтиһадлы юморның югары дәрәҗәсен тоту, әлбәттә, җиңел түгел.

«ТАТАРСТАН» – АКЫЛЛЫ, ИГЕЛЕКЛЕ, МӘҢГЕЛЕК

«Татарстан» башка журналлар арасында һәрвакыт алдынгы урында булды, ул йөз ел элек Татарстанның беренче хөкүмәте тарафыннан оештырылган. Бүген ул, тирәякта күпләр шаккатыргыч хәлләр артыннан куганда, бик оста һәм уңышлы итеп «акыллы гамәлләр», «игелекле эшләр», «мәңгелек кыйммәтләр» орлыклары чәчә. Әйе, бик күп кызыклы язмалар бар анда, аларның әнә шулай өч өлешкә бүленеп бирелүе уйланырга мәҗбүр итә, яхшы гамәлләргә рухландыра, гомумән – яхшы үсентеләр шытып чыга!

Журналның бик шәп бер идеясен билгеләп үтәм: бу –ел саен март санында өлкәннәр йортларында яшәүче әбиләрне гүзәл ханбикәләргә әверелдерү буенча «матурлык десанты». Кайчак бик онытылып китүче бу кешеләргә игътибар бирүегез – бик игелекле, ихлас гамәл. Безнең заманда бу аеруча кадерле! Журналның Татарстанның 100 еллыгын үткәнгә бик кызыклы сәяхәт рәвешендә бирүе ошады. Журналның тышлыгына язып та куйдым: «Редакциягә һәм редакторга рәхмәт! Заман рухы тотып алынган!»

Әлеге кыскача күзәтүемне төгәлләп, шуны әйтәсем килә: цифрлы технологияләр үсешенә карамастан, журналлар, басма матбугат, китаплар юкка чыкмаячак. Чөнки аларны укучылар һәрвакыт бар, һәм аларга мәгълүмат алуның әлеге гадәти, уңайлы ысулы кадерле. Хикмәт хәтта укучыларның яшендә дә түгел. Мәсәлән, безнең балалар да китап укып үсте. Бүген исә, берничә гаджетка ия булуларына карамастан, оныкларым кулында да еш кына китап күрәм. Оныкчаларым да матур сурәтле китапларны карап утырырга ярата. Сүз уңаеннан, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе, Татарстан китап нәшрияты белән бергәләп, балалар бакчалары өчен язучыларның рәсемнәре төшерелгән, шигырьләре язылган плакатлар чыгарган. Бик яхшы булган!

Минем барлык журналларга теләгем бер: бер-берегездән өйрәнегез, үз йөзегезне югалтмагыз. Көндәшлек – акыллар көрәше, ул киләчәк уңышларга этәрә!

ТАТАРСТАН
КИТАПХАНӘЛӘРЕ ДӨНЬЯСЫ



Барлыгы 1511 китапханә*, шулардан
– **муниципаль** – **1507**
– **дәүләтнеке** – **4**
((Татарстан Республикасы Милли китапханәсе, Республика балалар китапханәсе, Республика яшүсмерләр китапханәсе, Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсе)

Уртача **2577 татарстанлыга бер китапханә** туры килә

1 миллион 381,6 мең кеше – теркәлгән кулланучылар саны

35,5% – халыкны китапханә тәэминаты белән колачлау дәрәҗәсе. Яңа Чишмә һәм Чүпрәле районнарында – 97,3% һәм 95%. Яр Чаллыда һәм Казанда – 8,4% һәм 15,4%

435 000 татарстанлы
китапханәгә килгәч, бердәм укучы билетыннан файдалана

1407 муниципаль китапханә **бердәм укучы билеты** буенча хезмәт күрсәтә



Барлык дәүләт һәм 94% муниципаль китапханә
Интернетка һәм Милли электрон китапханәгә**, «Татарстан Республикасы Милли электрон китапханәсе» мәгълүмат системасына*** керү мөмкинлегенә ия.

Барлык китапханәләрнең 86%ы авыл җирлегендә урнашкан

100 китапханә 200дән дә кимрәк кеше яшәгән торак пунктларга хезмәт күрсәтә

88 муниципаль китапханә (5,8%) – **балалар өчен**

888 китапханәнең 1839 күчмә пункты бар

5 модельле китапханә

«Мәдәният» милли проекты кысаларында оештырылды

Модельле стандартына туры килә торган 83 китапханә «2006 – 2011 елларда Россия мәдәнияте» Федераль максатчан программасын һәм «Татарстан Республикасында китапханә эшен үстерү» Республика программасын гамәлгә ашыру кысаларында оештырылды.

28 миллион 795,81 мең – халык укырга алган басмалар (китаплар, брошюралар, белешмәлекләр, вакытлы матбугат) саны

14 миллион 068,2 мең

– китапханәгә килүчеләрнең теркәлгән саны

19 327 655 данә

– физик йөртүчегә күчерелгән муниципаль китапханә фонды

69% китапханә фонды – **рус телендә**

30% – татар телендә

0,7% – чуваш телендә

0,1% – удмурт телендә

0,2% – мари, башкорт, мордва һ. б. телләрдә

Авыл китапханәләре фондының **53%ы – матур әдәбият,**

11%ы – балалар әдәбияты

Авылда балалар әдәбияты, авыл хуҗалыгы, психология, экология, спорт, белешмә әдәбият буенча кытлык күзәтелә

2020 елда муниципаль китапханә фондларына **449560 данә яңа әдәбият** кайтты

2020 елда муниципаль китапханә фондларыннан **503 689 данә иске басма юкка чыгарылды**

2020 елда муниципаль китапханәләргә кайтартылган басмаларның **28%ы – социаль әһәмияткә әдәбият**

*Вузлар, фәнни учреждениеләр, ведомство китапханәләре исәпкә алынмады

**Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының шәбәкә китапханәләрендә, музейларында һәм архивларында урнашкан цифрлаштырылган документлар белән танышу мөмкинлеге тудыручы проекты.

***«Татарстан Республикасы Милли электрон китапханәсе» мәгълүмат системасы Татарстан, Россия һәм чит ил китапханәләре хезмәткәрләренең һәм гражданнарының ТР китапханәләренең җыелма электрон каталогына керү мөмкинлеген тәэмин итү өчен булдырылды.

МОДЕЛЬЛЕ КИТАПХАНӘ НӘРСӘ УЛ

Модельле китапханәләр – Россиядә «Мәдәният» милли проекты кысаларында ачылучы «яңа буын» китапханәләр ул. Зәвыклы бизәлешне, бүлмәләрнең уңайлылыгын һәм өр-яңа мәгълүмати технологияләргә керү мөмкинлеген үзендә туплаган чын интеллектуаль һәм мәгариф үзәкләре.

Биредә китап уку белән беррәттән, кызыклы очрашулар үткәрәләр, ялны файдалы итеп оештыралар. **Модельле китапханәдә иң яңа компьютер һәм күчереп алу техникасы, электрон китаплар, түләүсез Wi-Fi, 3D-принтерлар, VR-күзлек һәм башкалар бар.**

Россия Федерациясендә бүгенге көндә **130 дән артык модельле китапханә** исәпләнә. Китап фондына керә алу, ирекле аралашу, лекторияләр өчен бүлмәләрнең булуы, сирәк китапларның цифрлаштырган варианты белән танышa алу – **болар барысы да «яңа буын» китапханәләренең оештырылуы нәтиҗәсендә пәйда булган мөмкинлекләр.**

> – Хәзер инде бу сөйләшүләрне тыя торган катгый кагыйдәләре булган учреждение түгел. Бәлки **актив аралашу мәйданчыгы,** биредә һәркем үзенең интеллектуаль үсеше өчен мөмкинлекләр таба ала.
>
> Лидия Федякина,
> РФ Мәдәният министрлыгының мәгълүмати һәм цифрлы үсеш департаменты директоры урынбасары

Модельле китапханәләрдә **Милли электрон китапханәгә керү мөмкинлеге бар.** Әгәр зур булмаган муниципаль китапханә фондында **уртача 10–15 мең басма исәпләнә икән, әлеге мөмкинлек нәтиҗәсендә ул 4,5 миллионга кадәр арта.**

Барлык модельле китапханәләр дә уку-укыту һәм тәрбия процессына ярдәм итү максатында мәктәпләр белән бергә эшли. **Китапханә базасында төрле предметлар – әдәбият, дөнья мәдәнияте, тарихы һәм төрле илләрнең мәдәниятләре буенча дәресләр үткәрелә.**

Шунысы кызык: **Ямал-Ненец АОның Муравленко шәһәрендә ачылган модельле китапханәдә килүчеләргә Федор Михайлович исемле робот-китапханәче хезмәт күрсәтә, ул теләсә кайсы тема буенча әңгәмә корырга сәләтле.**

! **Татарстанның дүрт китапханәсен яңарту максатына федераль бюджеттан – 5әр миллион сум, Болгардагы үзәк китапханәгә 10 миллион сум акча бүлеп бирелде.**

ТАТАРСТАНДАГЫ МОДЕЛЬЛЕ КИТАПХАНӘЛӘР

Белобезводное китапханәсе
(Яшел Үзән районы)

Яңартылганнан соң ул күпфункцияле киңлеккә әверелгән – килүчеләр өчен уен бүлмәсе, видеозал, аралашу, мастер-класслар үткәрү зонасы, китап уку, аудиокитаплар тыңлау өчен уңайлы урыннар, коворкинг оештырылган. Музыка җиһазлары, цифрлы микроскоп, виртуаль чынбарлык белән баетылган интерактив глобус, уен консольләре, электрон һәм аудиокитаплардан торган бай фонд, электрон ресурсларга керә алу мөмкинлеге китапханәне төрле яшьтәге төркемнәрне җәлеп итү, кызыксындыру үзәгенә әйләндергән.

Әсән-Елга китапханәсе
(Кукмара районы)

Уку, өйрәнү, иҗат һәм ялгыз калу өчен уңайлы зоналар бар. Биредә китапларны укырга гына түгел, тыңларга һәм карарга мөмкин. Килүчеләр өчен планшетлар, персональ компьютерлар, югары тизлекле интернет урнаштырылган. Фондта – мультфильмнар, аудиокитаплар, үстерелешле уеннар һәм, әлбәттә, популяр әдәби әсәрләр һәм фәнни басмалар. Мөмкинлекләре чикле кешеләр өчен махсус автоматлаштырылган эш урыны да җиһазландырылган.

Чернышевка китапханәсе
(Биектау районы)

Мондагы урыннар килүчеләрнең төрле төркемнәре бер-берсенә комачауламаслык итеп эшләнгән. Китап киштәләре ачылып-ябылып, залны чаралар үткәрерлек итеп үзгәртергә мөмкинлек бирә. Югары тизлекле интернеты булган сигез компьютер, ноутбук һәм планшетлар федераль электрон һәм мультимедиа ресурсларына тоташтырылган. Бинага керү урынына пандус ясалган, шулай ук хәрәкәте чикләнгән кешеләр өчен махсус бокслар да бар. Китапхандәдә интерактив тактасы булган конференц-зал да ясалган.



Болгар китапханәсе
(Спас районы)

Китапханәдә компьютерлар, кинозал һәм планетарий өчен проектор, башка заманча җайланмалар, уңайлы яңа җиһазлар пәйда булган. Балалар өчен дә кызыклы яңалыклар күп. Алар хәзер, мәсәлән, яктыртылган өстәлдә ком белән рәсем ясый ала – иҗади һәм интеллектуаль сәләтләрне үстерә торган система буенча. Китап фонды берьюлы өч мең данәгә арткан, яңа әсәрләр укучыларның соравы буенча кайтартылган.

Яңа Кырлай китапханәсе
(Арча районы)

Биредә мәгълүмати-китапханә хезмәте күрсәтү зонасыннан тыш, балалар зонасы, күргәзмәләр үткәрү, ял итү урыннары барлыкка килгән. Компьютерлар урнаштырылган, планшетлар, ноутбуклар кайтартылган, сыйфатлы интернет үткәрелгән. Хәрәкәте чикле кешеләр өчен дә тиешле шартлар тудырылган. Китап фонды алты мең яңа басмага баеган, алар арасында матур әдәбият, балалар әдәбияты әсәрләре, белешмәлекләр бар. Балалар өчен китапханәдә интерактив идән ясалган, проектор урнаштырылган.

PRESSA

ЙОТЛЫГЫП УКУ



Саргайган газета төпләмәләре, таушалган китап томнары, халык ябырылып укый торган китапка чират... Китапханә турында ерак балачагыбызда тәрбияләнгән күзаллауларыбыз, ахрысы, бүген бөтенләй искергән. Дөньяда бөтен нәрсә кебек үк, уку заллары да бик тиз үзгәреш кичерә. Бүген авыл китапханәсендә, милли китапханә сайтына кереп, уникаль, раритет саналган басмалар белән танышырга мөмкин. Яисә планшетка берәр яңа китап яздырып алырга һәм укырга. Фильм карарга яисә үзеңә видео төшерергә. Уңайлы кәнәфигә утырып, егерме ел элек кебек, яраткан язучыңның китабын актарырга – кемгә нәрсә ошый. Бүген яңалыкның соңгы сүзе – суперзаманча интерьерлы модельле китапханәләр. Алар, кызыксынулар буенча чын клубларга әверелеп, кешеләрне үзләренә тартып тора. Хәер, гадәтләребезне үзгәртүче яңалыклар нинди генә кыю булмасын, китапханәнең асылы саклана. Ул китапны, укуны, белемне яратуга сәләтлеләрне берләштерүче үзәк булып кала бирә.



КИТАП ГАЛӘМЕ

«Кешенең бөтен нәрсәсе: йөзе дә, киеме дә, күңеле дә, уйлары да гүзәл булырга тиеш», – дип язган Чехов. Башка йөзләрчә мең басма белән бергә Антон Павлович китаплары да Казанда бөтен яктан да күркәм йортка күченде – Татарстан Республикасы Милли китапханәсенә бирелгән бинага кереп сыенды. Мәскәүнең ХОРА бюросы архитекторлары элекке Ленин мемориалы бинасының эчен танымаслык итеп үзгәрткән: диварларны күчергән, Казансуга карап торган панорамалы тәрәзәләр өстәгән. Китапханәгә беренче тапкыр кергәндә киңлек һәм яктылыктан баш әйләнгәндәй була хәтта. Фойе түшәме астында йолдызлардай балкыган хәрефләр исә биредә иң мөһим нәрсә китап булуын искәртеп тора.

Автор: Ксения Сёмина

ӨЙГӘ ДӘ БИРЕЛӘ

Яңа бинада фондлар да, хезмәткәрләр дә иркенләп урнаша алган.

– Без беренче тапкыр абонемент – өйгә китаплар бирү бүлеген ачтык. Абонемент фондында заманча әдәбиятның иң шәп кырык меңгә якын китабы бар. Алар Татарстан Республикасы Президенты бүлеп биргән 27 миллион сумлык грант акчасына алынды. Хәзер бер укучы җиде китапны егерме бер көнгә өенә алып китә ала, кирәксә, вакытны тагын да озайтырга була. Ихтыяҗ искиткеч булып чыкты! Тәүге тапкыр мине таң калдырганы шул булды: без Гүзәл Яхинаның «Эшелон на Самарканд» романының 10 данәсен кулга төшерә алдык. Ул без ачылыр алдыннан гына нәшер ителде. Китапханә ачылган көнне үк ун китапны да алып киттеләр, – дип сөйли китапханә директоры Мәдинә Тимерҗанова.

Классик китапханә, ягъни уку залы, уңайлы стеллажлар (хәзер җыелма баскычлар кирәкми инде), заманча җиһазлар, электрон каталог, укучыларга китап бирү кафедралары, гаджетлар өчен розеткалар белән җиһазландырылган – җентекләп эшкә керешү һәм текстка тулысынча кереп чуму өчен вактыйгенә кадәр уйлап бөтен мөмкинлекләр дә тудырылган. Уку елы башлануга, классик залда буш урыннар калмаган диярлек.

ТӨБӘКНЕ ӨЙРӘНҮ – ТРЕНД

Ихтыяҗ иң зур булган басмалар – психология, икътисад, медицина буенча китап һәм дәреслекләр.

– Без элегрәк бөтенләй диярлек ихтыяҗ булмаган басмаларга кызыксыну артуны күзәтәбез. Төбәкне өйрәнү, Казан тарихы (бигрәк тә Казан губернасы чорындагы) ту-

Фото: Александр Ефремов, Ксения Сёмина

рында китапларны еш сорыйлар, моннан йөз ел элек парк һәм скверлар нинди булганлыгы хакында мәгълүмат эзлиләр. Шул ук вакытта заманча шәһәр инфраструктурасы – социаль һәм мәдәни объектлар белән дә кызыксыналар, – ди вакытлы матбугат бүлеге мөдире Асия Махнина.

Китапханә структурасында тәүге тапкыр булдырылган балалар әдәбияты бүлеге шундук бик популярлашып та киткән. Анда балаларга тәгаенләнгән бөтен яңа китаплар, хәтта суперпопуляр комикслар да бар. Ачылган көннән бирле китап укучы балалар клублары эшли. Кыскасы, китап уку гадәте бала белән бергә үссен өчен, идеаль шартлар тудырылган.

ЯҢАДАН АЧЫЛГАН ТАРИХ

Бүген китапханә – интеллектуаль ял итү урыны. Биредә төрле клублар эшли, китап презентацияләре һәм фәнни лабораторияләр, фестивальләр, форумнар уздырыла, күргәзмәләр залы һәм MON театры ачылган. Болар барысы да мультигаләмне хәтерләтә – бер үк вакытта күп төрле вакыйга бара, аларда бик төрле кешеләр катнаша. Әмма аларның барысын да китап берләштерә.

– Китапларга заманча караш үзенә күрә бер катализаторга әйләнде: консерватив учреждение бик динамик оешмага әверелде. Бу – тарихи материалларның арткы планга китүе түгел, нәкъ киресенчә. Без биредә элеккеге Россия территориясендәге мөселманнарның үткәнен һәм хәзергесен өйрәнә торган мәктәп чараларын үткәрәбез. Тикшеренү өчен материал – бик сирәк очрый торган җирле фондлар, – ди Татарстан Фәннәр академиясенең Тарих институты директоры урынбасары Альфрид Бустанов. – Тәҗрибәле библиографлар алар белән эшләүдә булыша, тикшеренүчеләр уникаль әдәбият дөньясы белән таныштырырга һәрвакыт әзер.

ЕЛГА ФОНЫНДА ЛЕКЦИЯЛӘР

– Китаптан белем дә, ләззәт тә алыр өчен биредә идеаль шартлар тудырылган. Минемчә, биредә үткәрелгән бөтен чара һичшиксез китап дөньясы белән кисешергә тиеш, – ди тикшеренүче, локаль мәдәният һәм тарихны популярлаштыручы Рәдиф Кашапов. – «Jadidfest: Казан – судагы шәһәр» фестивалендә төрле чорларда татарстанлылар тормышында суның роле турында теге яки бу дәрәҗәдә сөйли торган басмаларны безнең өчен махсус тупладылар. Без «Татар халык җырлары», Мирсәй Әмирнең «Агыйдел», Гариф Ахуновның «Идел кызы», Гариф Гобәйнең «Маякчы кызы» һәм башка күп китапларга мөрәҗәгать иттек. Шул рәвешле без тарихны төрле яктан, төрле караштан күзаллый алабыз.

– БЕЗ ЭЛЕГРӘК БӨТЕНЛӘЙ ДИЯРЛЕК ИХТЫЯҖ БУЛМАГАН БАСМАЛАРГА КЫЗЫКСЫНУ АРТУНЫ КҮЗӘТӘБЕЗ. Төбәкне өйрәнү, Казан тарихы (бигрәк тә Казан губернасы чорындагы) турында китапларны еш сорыйлар, моннан йөз ел элек парк һәм скверлар нинди булганлыгы хакында мәгълүмат эзлиләр. Шул ук вакытта заманча шәһәр инфраструктурасы – социаль һәм мәдәни объектлар белән дә кызыксыналар, – ди вакытлы матбугат бүлеге мөдире Асия Махнина.

«Гыйлемдә – көч» гыйбарәсен XVII гасырда яшәгән инглиз фәлсәфәчесе Фрэнсис Бэконныкы дип саныйлар. Милли китапханә хезмәткәрләре, көченең китапта булуын кабат-кабат дәлилләп, җентекләп һәм профессиональ дәрәҗәдә белемгә кызыксыну тудыру белән мәшгуль.

КИТАПХАНӘ САННАРДА:

Ачылу вакыты: **2020 елның 30 августы**

Кабат китап бирә башлау вакыты: **2021 елның 20 марты**

Кабат китап бирә башлаганнан бирле килүчеләр саны: **280 мең кеше**

Бер көндә иң күп кеше саны: **4849 кеше**

Көн саен өйгә **1,2 меңләп китап бирелә**

Китапларның гомуми саны: **3,5 миллионнан артык**

Китапханәгә килүчеләрнең 70 процентка якыны – мәктәп укучылары, студентлар һәм яшь балалы гаиләләр

МӨСЛИМДӘГЕ ТАРТУ ҮЗӘГЕ

Милли татар өслүбендәге мичле кафе, балаларны рухи яктан үстерү зонасы, Интернетка тоташтырылган компьютер зонасы, әдәби кунакханә – Мөслим муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханәсе белем бирү, мәдәни-агарту, күңел ачу миссияләрен үти торган ял итү үзәгенә әйләнгән.

КӨТЕЛМӘГӘН БОРЫЛЫШ

– Глобальләшү һәм модернизацияләү китапханәләрне дә урап үтә алмый, – ди Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы «Үзәкләштерелгән китапханә» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе мөдире Айсылу Мадьярова. – Шуңлыктан безне үзгәрүчән, яңа формат бер дә куркытмый. Китапханә бүген китаплар саклана торган бина гына була алмый, аңа зуррак бурычлар да йөкләнә.

Без үз эшебезне даими камилләштерүдән башка алга бара алмыйбыз, аны исә проект-инновация эшчәнлегеннән башка күз алдына китерүе дә кыен. «Мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге проектларга ярдәм итү» номинациясендә Россия Федерациясе Президенты проектлары конкурсында катнаштык та, китапханәбездә әдәби кафе пәйда булды.

Кәнәфи-диваннар, савыт-саба шкафы, каһвә пешерү машинасы, чәй һәм каһвә сервизлары сатып алдык. Китапханә хезмәткәрләре кафе өчен үз куллары белән мич чыгарды. Янәшәгә

Фото: Александр Ефремов

махсус җайланмалар – табагач һәм агач көрәк куйдык, мич кырыена бәз тукымадан чаршау элдек, идәнгә чуклы мамык келәмнәр җәйдек. Биредә бик уңайлы, мөслимлеләр китап укырга гына түгел, дуслары белән аралашырга да ярата. Бүген районның күп предприятиесе хезмәткәрләре ял итү өчен китапханәгә килә. Ә язучылар, шагыйрьләр, рәссамнар, педагоглар, төбәкне өйрәнүчеләр, мәктәп балалары һәм студентлар өчен әдәби кичәләр, дискуссияләр, семинарлар биредә чәй яки каһвә эчеп, яңа әдәби китаплар һәм көндәлек матбугат яңалыклары белән танышып тәгәлләнә.

ЯҢА КИТАПЛАР, САФ ҺАВА...

«Хәзерге заман китапханә-мәгълүмат мәйданы» проекты кысаларында исә Мөслим китапханәсе саф һавага, Габдулла Тукай исемендәге урта белем бирү мәктәбенә таба күченгән. Шагыйрь исемендәге урамда эскәмияләр һәм китап киштәләре куйганнар. Биредә китап алмашырга, әдәби чараларда катнашырга яки рәхәтләнеп укып утырырга була – урамдагы киштәләр өчен байтак китап сатып алынган.

УКЫ ҺӘМ УЙНА

Мөслимдәге кебек китапханәләр күп түгел. Ул бик зур, бик якты, үзәкләштерелгән электрон китапханә сервисларына тоташтырылган, үз фондында да китаплар күп. Бирегә пенсионерлар да, өлкәннәр дә, балалар да килә. Һәркем үзенә мавыктыргыч шөгыль таба: шахмат, уеннар, компьютер, китап уку. Шул рәвешле китапханә төрле кешеләрнең бергә җыелып уку, уйнау, иҗат итү, ихлас аралашу урынына әйләнә...

МӨСЛИМ КИТАПХАНӘСЕНДӘ СОҢГЫ ВАКЫТТА ТӨРЛЕ ПРОЕКТЛАР БУЕНЧА КИТАП УКУНЫҢ ҺӘМ КИТАПХАНӘНЕҢ АБРУЕН АРТТЫРУГА ЮНӘЛТЕЛГӘН БИК КҮП ЧАРА ҮТКӘРЕЛГӘН. Район китапханәсенең иң актив укучылары катнашында «Ел укучысы» конкурсы, «Китап корты» әдәби фестивале, аграр көллият студентлары белән «Иң яхшы китап укучы гаилә» фотоконкурсы, «Могҗизалар кыры» һәм «Мин кулыма китап алам» интеллектуаль уеннары, «Мин китап укырга яратам» викторинасы, «Моабит дәфтәрләре» квест-уены һәм башкалар. «Әти, әни һәм мин – китап укучы гаилә» фотоконкурсында гына да районнардагы 50 гаилә катнашкан.



Айсылу Мадьярова

БАЛАЧАК+КИТАПХАНӘ

Бу – яшь укучылар өчен чын оҗмах: Республика балалар китапханәсе фондында бөтен дөньядан 119 мең данәдән артык китап тупланган. Ел саен бирегә 80 меңләп бала була.

Автор: Алсу Троицкая

КЫЗЫМ+

Синең чын дустың бар икән, аны ташларга ярамый.
Астрид Линдгрен. Баләкәч һәм Карлсон»

Республика балалар китапханәсенә бәләкәй кызымны иң беренче тапкыр мин алып бардым. Кулыннан тотып. Бер сәгатьтән исә аны матур рәсемле әлифба китабы яныннан алып китеп булмый иде. Ул үзенең кечкенә бармагын китап юлларыннан йөртә һәм минем артымнан кабатлый:

– Ибис заинтересован, что за зверь тут нарисован... «И» хәрефе...

Кинәт укуга кызыксыну уянган ике яшь ярымлык балага кызыклы җанварлар – жираф, умарта кортлары, мөгезборыннар ярдәмгә ашыкты... Әмма нигәдер безнең икебезнең дә хәтеренә нәкъ менә ибис уелып калган. Бу хәл моннан чирек гасырга якын элек булган иде.

Аннары кызым белән минем уку гомерендә әлеге китапханәдән алынган китаплардан таулар өярлек булды. Нинди генә китаплар бит әле! Том Сойер да, Алиса да, Винни-Пух та, капитан Грант та, Нәни Принц та, Белмәмеш тә бар иде анда... Кызым үсте, китаплар да үзгәрде. Бүген инде ул бөтенләй башка әдәбият белән кызыксына, әмма тәүге китабыбызны без Ямашев проспекты, 81 нче йортта урнашкан нәкъ менә шул китапханәдә укыдык. Кайчан да булса, бик тиздән, ул инде үзе дә бирегә сабыйларын алып килер, дип ышанам...

0+

Бәләкәй балалар өчен тормышның билгеле бер тәртиптә баруы зарур, ә иң мөһиме, ул тәртипне алар үзләре урнаштырырга тиеш!
Астрид Линдгрен. «Пеппи Озынойок»

– Китап уку фанатлары булган, бар һәм мәңге булачак, – дип ышана **Республика балалар китапханәсе директоры Ирина Мөхәммәтгәрәева.** – Күп гаиләләрдәге традиция буенча бирегә балаларын нәкъ менә әти-әниләре алып килә. Мин һәрвакыт, бала китап укуга юлны үзе генә таба алмый, дим. Әлеге юлга аны өлкәннәр җитәкләп кертергә тиеш.

Бик бәләкәй, әле беренче сүзләрен генә әйтергә өйрәнгән сабыйларны алып киләләр. Без үзебезне 0+ яшендәгеләр китапханәсе, дип тәкъдим итәбез бит. Хәтта йөкле хатыннарның да килгәне бар. Алар карыннарындагы сабыйларына нәфис әдәбият укый. Кәгазьгә басылган китапның Интернет һәм ридерлар гасырында да актуальлеген югалтмавы минем үземне бик сөендерә. Тәмле ис аңкып торган кәгазь китапны кулга алу аңлатып булмаслык рәхәтлек бирә бит ул.

Республика балалар китапханәсе күптән инде китап саклау урыны гына түгел ул. Бирегә гаилә белән килергә һәм озаклап утырырга мөмкин. Вакытны файдалы үткәрә, китап укырга ярата торган гаиләләр, бәхеткә, әле дә күп әле. Шунлыктан китапханәдә һәр җомга саен гаилә клубы эшли. 7 яшьтән өлкәнрәк укучылар өчен дә махсус җыелышлар уздырыла. Шуңа күрә әти һәм әни белән генә түгел, дуслар белән бергәләп килеп тә китап укырга була. Соңыннан исә укылганнарга нигезләнеп үз тарихларын уйлап таба һәм уйный алалар. Төрле яшьтәге балалар, бергә уйнаганда, өлкәннәр ярдәмендә булса да, үзләре образлар уйлап таба, әкиятләр иҗат итә һәм хәтта мультфильмнар да төшерә ала.

– Балаларны китап укуга җәлеп итү өчен, без бик күп төрле конкурслар уздырабыз, яшь укчыларыбыз аларны һәрвакыт түземсезләнеп көтеп ала, – ди инновацияләр кертү, үстерү һәм гаммәви мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек итү бүлеге мөдире Эльвина Фәррахова. – Күптән түгел генә «Китаплы җәй» проекты тәгаммәлләнде. Аның шартлары буенча бала җәй буе китапханәдән укырга китаплар ала һәм укылган һәркайсы өчен аңа ябыштыргыч бирелә. Иң яхшыларга без бүләкләр, дипломнар бирәбез. Күз алдыгызга китерә аласызмы, җәй буена 130 ар китап укучы балалар да бар! Табигый ки, бу җәйге каникулда мәҗбүри укылырга тиешле әдәбият исемлегеннән күпкә артыграк. Хәзер әле тагын яңа китаплар кайтуын көтәбез...

УКУ+

Үзе үзгәрмәгән кеше өчен
бернәрсә дә үзгәрә алмый.
Михаил Энде. «Очсыз-кырыйсыз тарих»

Республика балалар китапханәсе – сабыйларның язучылар, шагыйрьләр, театр әһелләре белән аралашу урыны да әле ул. Театрлаштырылган сәхнәләр, әкият геройлары белән экскурсияләр, квестлар биредә һәрвакыт бик мавыктыргыч уза. Китапханәдә үткәрелә торган чараларга Казан мәктәпләре чиратка языла.

Җәйге каникул вакытында инде икенче ел рәттән РБКнең креатив хезмәткәрләре «Байтик» белем бирү-савыктыру лагеренда күчмә китапханә оештыра. Анда балалар китапханәсенең һәр сменага 350–400 баланы китап укучылар «отрядына» җәлеп итү мөмкинлеге бар.

ТАТАРСТАНДА РЕСПУБЛИКА БАЛАЛАР КИТАПХАНӘСЕ ҺӘМ 88 МАХСУСЛАШКАН МУНИЦИПАЛЬ КИТАПХАНӘ БАР. Республикабыз китапханәләрендә балалар иркен мәйданда аралашу һәм сәләтләрне үстерү мөмкинлеген ала.

Безнең бер-беребезгә кирәк
булуыбыз ничек шәп бит, ә!
Сергей Козлов. «Томандагы Керпе»

Балалар китапханәсе – китаплар һәм аларны уку гына түгел әле ул. Бу балалар, аларның әти-әниләре һәм хезмәткәрләрнең аралашу урыны да. Аларның барысының да бәхете тулы булсын өчен бинаны дизайн ягыннан үзгәртү таләп ителә. Балалар китапханәсен һәр кунак өчен зоналарга бүлгәндә, ул тагын да якынрак, «үзеңнекерәк» булыр иде. Кемдер уйный һәм бераз тавышлана, кемдер баласын көткәндә тыныч кына каһвә эчә, кемдер исә тынычта китап укырга дип махсус килә. Чөнки, ни генә дисәң дә, кәгазьгә басылган китап – һәрвакыт хыял һәм ассоциатив хисләр дәртләндергече ул. Һәм безнең кулыбызга галиҗәнап китапны тотып ләззәтләнә алуыбыз ничек шәп...

Балалар китапханәләренең социаль челтәрләрдәге вәкиллекләре тиз үсә. Барлык китапханәләрнең дә диярлек «ВКонтакте», «Инстаграм» социаль челтәрләрендә үз сәхифәсе, Youtube киңлекләрендә үз сайты һәм каналы бар, анда китапханәләр эшчәнлеге, яңа китаплар актив рекламалана; конкурслар, акцияләр, яшь укучылар өчен әдәби экскурсияләр үткәрелә; социологик сораштырулар һәм китапханә бәйгеләрендә җиңүчеләр өчен тавыш бирүләр оештырыла.

БАРМАК ОЧЛАРЫ АША КҮРҮ

Автор: Алсу Троицкая

Күрмәүчеләрнең күпчелеге эхолокация ярдәмендә дөрес юнәлешне таба белә, күрмәгән килеш тә төсләрне таный, үзләренең феноменаль хәтеренә таянып, шәһәр буенча үз маршрутын төзи... Бу вакытта аларның баш миендә күрүчеләр берәр нәрсәгә караганда активлаша торган өлеш җанлана, дип саный галимнәр. Әмма... «алтынчы» тойгы әлеге сиземләүне үстерергә теләгән, белемле һәм күп укыган күрмәүчеләрдә генә пәйда була.

ТӨС ТОЕМЛАУ

– Әйе, нәкъ менә китап укучыларда. Сезнең белән без китапны алабыз да укыйбыз – безгә бу бик гади эш. Ә начар күрүчеләр, бигрәк тә бөтенләй күрмәүчеләр өчен исә – тулы бер вакыйга, – дип аңлата Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсенең төп белгече Айсылу Вәлиева. – Бу хәл Мәскәүдә булды. Китапханәбезнең Рус география җәмгыяте белән уртак проектын тәкъдим итү кичәсенә тома сукырлар да килде. Без аларга үзебезнең рельефлы графикалы китапларыбызны күрсәттек. Фикер алышу башланды. Китаплар исә төсле. Мин сорашам, шулай төсле итеп калдыру кирәкме, дим. Күрмәүче китап битенә тотынганда җылылык яки салкынлыкны, ниндидер күңелгә ятышсыз яки, киресенчә, игелекле, яхшы нәрсәне бөтен тиресе белән тоя икән. Мәсәлән, ниндидер җетелек сизсә, бу кәгазьдәге сары, кызгылт-сары, кызыл төстәге рәсемнәр булачак. Әйе, алар ялгышырга да мөмкин. Әмма, кагыйдә буларак, төсләрне алар дөрес атый...

КИТАПХАНӘ ГЕНӘ ТҮГЕЛ

Быел сентябрьдә 85 еллыгын билгеләп үтә торган Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсе торак йортның беренче катында урнашкан. Китапханә хезмәткәрләрен борчыган ике зур проблема – аның мәйданының кечкенәлеге һәм, китаплар су басудан зыян күрер, дип курку.

– Без башка китапханәләрдән үзебездә махсуслашкан фондлар булу белән аерылып торабыз, аларга зыян килсә, коточкыч булачак, – ди Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсенең оештыру-методика һәм библиография эшчәнлеге бүлеге мөдире Гөлүсә Закирова. – Әйе, китап уку – безнең төп бурычыбыз. Әмма моннан тыш без әле кунакларыбызның реабилитациясе һәм ялын оештыру белән дә шөгыльләнәбез. Асылда без – һәртөрле чаралар үткәрелә торган тулы кыйммәтле мәдәни-социаль үзәк тә. Нәкъ менә шуңа күрә безнең проектларыбыз укучыларыбызны төрле мәдәни кыйммәтләр, әдәби, визуаль сәнгатьләр белән таныштыруга, аларны көнкүрешкә адаптацияләүгә, иҗтимагый тормышта катнаштыруга юнәлтелгән. Хәер, хәзер инде башка китапханәләр дә нәкъ менә мәдәни-ял итү һәм хәтта гаилә үзәкләренә дә әйләнеп бара.

ТАМАШАЧЫ КҮЗЕ

«...И вот наконец одним прекрасным майским утром Эдвард с Абилин и мистер и миссис Тюлейн оказались на борту корабля. Пелегрина стояла на пристани. На голове у неё красовалась широкополая, украшенная цветами шляпа. Пелегрина не сводила с Эдварда тёмных сверкающих глаз.

– До свидания, – закричала Абилин бабушке. – Я люблю тебя!

Корабль отчалил. Пелегрина помахала Абилин.

– До свидания, юная леди, – закричала она, – до свидания!..»

Габдулла Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачы театрының тамаша залында «Удивительные приключения кролика Эдварда» спектаклен гади балалар гына түгел, күрмәүче һәм начар күрүче сабыйлар һәм аларның әти-әниләре дә мавыгып карый. «Үзгә» тамашачыларга спектакль башланыр алдыннан колакчыннар һәм шәхси FM-радиоалгычлары таратылган, алар ләззәтләнеп тамаша тыңлый. Сәхнәдәге хәлләрне алар без китапханәдә танышкан тифлокомментатор Гөлүсә Закирова күзләре аша «күрә».

Театр спектакльләрен сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен адаптацияләү белән дә республика махсус китапханәсе шөгыльләнә, бу эш Алишер Усмановның «Сәнгать, фән һәм спорт» хәйрия фондының «Үзгә караш» программасы кысаларында 2018 елдан бирле башкарыла. Бүген инде тифлокомментарийлы спектакльләрне Казанның берничә театрында карап була.

КУЛДАН ЭШЛӘНГӘН

Бирелә сукырларның дөньяны кабул итү офыкларын китап чикләреннән күпкә еракларак киңәйтергә тырышалар. Брайль шрифты буенча укырга өйрәтү элеккечә үк төп метод булып калса да, бүген аңа ярдәмгә өр-яңалары да пәйда була тора.

Тактиль, капшап сизелә торган китаплар – аерым бер тема. Бүген китапханә фондларында шундый 200 дән артыграк китап бар. Аларның барысын да Айсылу Вәлиева үзе кулдан теккән. Китаплар җете, йомшак, схематик, бер үк вакытта купшы да, уңайлы да. Алар күрә торган балаларның сукыр әти-әниләренә дә, яки, киресенчә, начар күрүче сабыйларга яки ата-аналарга да тәгаенләнә – бар очракта да мондый китап алыштыргысыз ярдәмче булып тора. Ул уен ярдәмендә педагогка яки ата-анага баланы Брайль шрифтын өйрәнүгә җәлеп итүгә булыша, укуга кызыксыну уята, баланы тормышка адаптацияләүгә үз өлешен кертә, аның сәләтләрен үстерә.

Китапханә фондларында Брайль шрифтлы басмалар күбрәк. Аудиокитаплар (бирелә аларны, сөйләшә торган, дип йөртәләр), рельефлы графикалы басмалар һәм Интернет пәйда булганчы, алар күрмәүчеләр өчен дистәләрчә ел буе бердәнбер белем чыганагы булып торган.

ҮСЕШКӘ ЭТӘРГЕЧ БУЛАРАК УКУ

Күрмәүчеләр күп укый. Әмма технологияләр алга киткән саен, уку процессы да үзгәрә бара. Әгәр элегрәк укучы китапханәгә аена 3-4 тапкыр килсә, хәзер флешкасына берьюлы 100–150 китапны тутырып китеп, ел буена «укый» ала.

– Без, әлбәттә, әдәбият сайларга булышабыз, үз китапларыбызны да бирәбез. Моның өчен ел саен үз студиябездә 50 ләп аудиокитап яздырабыз. Әмма күрмәүче мәгълүматны төрле юллар белән алырга тиеш, – дип саный Айсылу Вәлиева. – Бала чакларыннан ук Брайль шрифты буенча укырга өйрәнүчеләр белемлерәк, әлбәттә. Аларның сүз байлыгы да күбрәк, мантыйк, хәтер, тоемлау, вак моторикалары да яхшырак үсештә. Нәтиҗәдә, алар тормышка да яхшырак җайлаша. Бу исә сукыр кеше өчен иң мөһимедер, мөгаен.

Нәкъ менә шуңа күрә китапханәнең барлык проектлары да махсус белем бирү учреждениеләре, экспертлар белән дә, күзе күрә торган гади кешеләр белән дә хезмәттәшлеккә юнәлтелгән.

Китапханәләрдә ел саен апрель төнендә үтә торган чарада бирелә кунакларга күзләрен бәйләп берничә гади эш башкарырга тәкъдим итәләр. Кайбер предметларны капшап тану, суны шешәдән чынаякка һәм аннары кире салу, кулдагы таяк ярдәмендә төрле каршылыкларны әйләнеп үтеп, китапханә буйлап йөрү...

БӘЛЛҮР ТРОФЕЙ

Кеше барлык белеменең якынча 80%ын күз аша ала. Сукырлар исә күз күрмәгән мәгълүматны ишетү, ис тою, капшап карау аша алырга мәҗбүр.

Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен китапханә проектларыннан берсе шуңа «Татарстан бармак очларында» дип атала да. Ул 2014 елда Рус география җәмгыяте белән берлектә башланган да, республика географиясен, Казан Кремле, Изге Болгар, Зөя утрау-шәһәре буенча юл күрсәткечләрен үз эченә алган. Аннары анда парклар, скверлар, республиканың су саклау зоналары, аның табигый туристлык объектлары кертелгән. Әлеге проект өчен китапханә илкүләм «Бәллүр компас» һәм Рус география җәмгыяте премиясенә лаек булган. Казан китапханәсе – география, экология, Россиянең табигый һәм тарихи-мәдәни мирасын саклау һәм популярлаштыру өлкәсендәге мондый бүләкләргә лаек булган илдәге бердәнбер китапханә.

ДҮРТ МЕҢ УКУЧЫ ХОЗУРЫНА КИТАПХАНӘ ФОНДЫ 350 МЕҢНӘН АРТЫК БАСМА ТӘКЪДИМ ИТӘ, алар арасында яссы басылганнары да бар. Китапларның күпчелеге китапханәнең үз нәшриятында дөнья күргән.

КИТАП АУЛАРГА ЧЫГАМ

Ни кызганыч, шәп кенә китаплар киштәмдә үз урынын таба алмады. Бенуа һәм Хаггардның маҗаралы романнары, Желязны һәм Фостерның фантастик әсәрләре, Гюгоның тарихи драмасы һәм Мопассан новеллалары... Аларны берәр юньлерәк нәрсәгә алыштырырга өмет итеп, мин буккроссинг зоналарына юл тотам.

Автор:
Катерина Котова

ИРЕККӘ ЧЫГАРАМ!

Китаплар алмашу өчен беренче шкафны мин үзем яшәгән йорт янында диярлек таптым. Фостер, Гюго һәм Мопассан китапларын рюкзагыма салып, үзебезнең торак комплексының идарәче компаниясе офисына юл тотам. Китап киштәләре – ишек төбендә генә, янәшәдә – кәнәфи. Коммуналь хезмәтләр өчен түләүләр турында сөйләшүне тыңлый-тыңлый, классика белән беллетристика арасында бөтерләнәм. Монда ни генә юк! Вальтер Скотт янәшәсендә – Ленин һәм Сталин премияләре лауреаты Николай Тихонов. 2007 елгы фэн-шуй календаре Нейл Соломонның «Феномен нони» (белмәгәннәр өчен: нони – Таитиның җәннәткә тиң утрауларындагы тропик җиләк-җимеш) китабы белән бергә ята. 1965 елда «Политическая литература» нәшриятында чыккан «Забавное Евангелие» – совет язучысы, фантастикадагы теләсә нинди яңа идеяләр белән көрәшүче буларак танылган Владимир Немцовның повестьлар җыентыгы белән күрше. Әнә шул Немцов китабын ачам, ә анда: «Маргарита Никитичнага! Йөрәгегез комсомол уты белән янган өчен сезгә рәхмәт», дип сырлап куелган. Ошбу әдәби хәзинәнең (әллә инде чүплекнең) кайсысы йөрәгемдә кызыксыну уты кабыза ала? Гафу итегез, күршеләр, берсе дә кабыза алмас кебек.

Хаггард, Бенуалар, Карл Майя вестерннары җылы рюкзагымнан чыкмады. Башымда – җәмәгать китапханәсенә урап кайту уе. Анда инде сайлау мөмкинлеге яхшырак булырга тиеш! Әмма Лядской бакчасында китаплар өчен тәгаенләнгән кечкенә тартмада җилләр уйный. Аксенов скверындагысында да – шул ук манзара...

– Әйе, буккроссинг өчен кечкенә шкаф бар иде бирәдә, әмма озак тормады, – ди «Республика» сәүдә үзәге сатучылары. Кыскасы, монда килүем дә бушка булды.

Казан түрендә – Кремль яр буенда язмышымны сынап карыйм. Башка җирдәге кебек кеше көлкесе түгел инде монда, төрле төстәге алты зур шкаф тора! Тик алардагы «байлык»ны җентекләп өйрәнгәннән соң, шатлыгым өметсезлеккә әйләнә. Сер тулы Мураками романнарын эзләгән идем, ә нәрсә таптым? «Мең дә бер ризык», «Монтиньякның туклану серләре», «Социаль яклау учреждениеләре белгечләренең фәнни-гамәли эше»нең берничә кисәге, «БДИ өчен 3300 мәсьәлә»... Хәтта Хезмәт кодексы да бар монда... Мине көйсез кияү дип атасагыз атагыз, тик кичемне «Дарулар энциклопедиясе» укып та уздыру теләге тумады. 1988 елгы «Төзелеш-ремонт эшләре өчен җирле бәяләр» китабын әйтеп тә тормыйм. Шундый хис туа: боларны киштәдә калдырган кешеләр чүплеккә барып җитә алмаган ахрысы...

Кремль яр буенда тапканнарым арасында берничә үзгәреге дә бар. Альвареснның атаклы «Кыргый Розаның кайтуы» (шул, шул – теге Мексика сериалының дәвамы) һәм Островскийның «Корыч ничек чыныкты» романы – эпохаль китаплар. Ә менә «Монархларның интим тормышы» һәм Эдуард Топольнең шәрран ачык эчтәлекле «У.е.» романы – әче-төче яратучыларга. Югары сәнгать тә бар: Европада «яңа драма»га нигез салучы Генрик Ибсен турында китап һәм Мольер томлыгы... Ә мин әле монда үземнең Бенуадан оялып йөргән булам!

КӘГАЗЬ КИТАПЛАР ӘЙЛӘНЕШЕНЕҢ ИНТЕРНЕТ-ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕ

Татарстанда мондый ничә шкаф куелганлыгы турында сезгә беркем дә мәгълүмат бирмәячәк – андый статистика беркайда да алып барылмый. Сәбәбе гади – әлеге хәрәкәт күп очракта үзеннән-үзе барлыкка килә. Мондый шкафларны республикабызның төзекләндерелгән парк һәм скверларында гына түгел, вокзалларда һәм аэропортта, сәүдә үзәкләрендә һәм кафеларда, уку йортларында, китапханәләрдә һәм хәтта, инде белгәнегезчә, аерым торак комплексларда

да табарга була. Казанда гына да андый урыннар – дистәләгән. Шунлыктан, нинди генә маршрут белән юл тотсагыз да, якын-тирәдә китаплы шкафны табарга була.

Сүз уңаеннан, җәмәгать китап шкафы һәм буккроссинг, бер-берсен тулыландырса да, икесе ике нәрсә. Кайбер мәгълүматларга караганда, китаплар алмашу өчен беренче шкафлар Европада 1990 елларда барлыкка килгән, ә «китап әйләнеше» дип тәрҗемә итәргә мөмкин булган BookCrossing хәрәкәте нибары егерме ел элек килеп чыга. Моңдый идеяне Рон Хорнбекер исемле бер веб-дизайнер тәкъдим итә, китаплар алмашу хәрәкәтенең төп үзәге – Bookcrossing.com сайтына нигез салучы ул.

Бүген дөньяда буккроссинг тарафдарлары саны 2 миллион кешегә якынлаша. Әлеге статистикага, әлбәттә, аерым интернет-сервиста теркәлгән һәм үз китапларына махсус тамга ябыштырып, аның «сәяхәт»ен күзәтүчеләр генә керә. «Нинди сәер шөгыль?» – дип сорарсыз. Тик моны бер, ике, өч, биш елдан соң үз китабының табылуы һәм аның Ярославль, Астана яки бөтенләй ерак Копенгагеннан Мураками яки Фаулзны укырга яратучы берәү кулында икәнлеге турында электрон хат алып шатлык кичергән кеше генә аңлый ала. Әгәр кулына сезнең китап эләккән буккроссер аның шушы мизгелдәге урынын сайтта күрсәтсә, басманың кулдан-кулга күчеп йөргән интернет челтәрендә күзәтергә мөмкин. Асылда, буккроссинг идеясе шуннан гыйбарәт тә. Алга китеп булса да әйтәм, әлеге хәрәкәтнең рус телендәге тармагында Казан буйлап «сәяхәт итүче» бик күп китап бар.

КЫЗЫКСЫНУЛАР ЯКЫНАЙТКАН КЛУБ

Ау, буккроссерлар, сез кайда? Шкафлар янында һичкем юк.

«ВКонтакте»дагы «Буккроссинг Казан» тематик төркемендәге (анда катнашучылар нигездер китапларны бер-берсенә сатып бирергә маташа): «Хәерле көн! Сезнең берәрегез чыннан да буккроссингтан файдаланамы?» – дигән белдерүем җавапсыз инде берничә көн эленеп тора.

– Безнең клуб әгъзалары китапларның текст версияләреннән яки электрон вариантларыннан файдалана, дип уйлыйм. Бәлки, бу бездә буккроссинг хәрәкәте бик үсмәгәнгә бәйледер, – дип җавап бирә минем соравыма «ВКонтакте»дагы «КФУ китап клубы» сәхифәсе администраторы Олеся Тимофеева.

– Бәлки, син китаплар алмашу шкафларыннан файдаланасыңдыр? – дип төпченәм китап сөюче танышымнан.

– Юк. Әмма дуслар, туганнар, хезмәттәшләр белән китаплар алмашам. Минем тирә-юнемдә китап яратучы кешеләр күп. Шуңа күрә берәребезгә ошаган китапны еш кына «сәяхәтче бака» язмышы көтә. Менә шул инде безнең «буккроссинг».

Шулай да тырышлыгым бушка китмәде.

– Әйе, мин якын-тирәдәге барлык шкафлардан актив файдаланам, – дип сөйли Яшел Үзәннән экоактивист Анастасия Благовещенская. – Теге яки бу китапны эзләп йөрергә вакытым юк. Шул тирәдән йөгерә-чаба үткәндә, күз ташлыйм.

Яхшы китап табу өчен тырышлык куярга туры килә, дип тынычландыра мине Анастасия, чөнки, чыннан да, киштәләрдәге ассортимент үзенчәлеклерәк шул.

– Тик кайчагында мин укыган чордагы дәреслекләр очраштыргалый, балаларга яңа темалар аңлатканда, миңа шулардан файдалану уңайлы, – дип сөйли ул. – Казанда иң яхшы, әмма кечкенә буккроссинг Профсоюз урамында урнашкан «Второе дыхание» кибетендә эшләде. Миңа анда уку әсбаплары, дәреслекләр кызыклы иде, кызганыч, ул урын ябылды. Яшел Үзәндә мин белгән иң зур һәм актив буккроссинг 9 нчы мәктәптә урнашкан. «Мирный» сәүдә үзәгендә, автовокзалда бар. Анда хәзер сирәк басыла торган фантастиканы – Ефремов, Стругацкийларны очратырга була... Кешеләр буккроссингка классика да алып килә, андый китапларны кабат укып чыгу да күңелле. Аннары безнең китапханәләребез дә бик бай – мин Степная урамындагысына һәм «Алые паруса» мәдәният йортындагысына йөрим.

Күптән хыялланган китабымны табу өметен югалтмыйча, Bookcrossing.ru сайтында теркәләм. Һәм менә ул! Харуки Муракаминың «Бесцветный Цкуру Тадзаки и годы его странствий» дигән китабы 2017 елның августында Бауман урамында kimyl06 никлы берәү тарафыннан 768 нче номер белән калдырылган булган. «Бу китапны укырга телим» төймәсенә басам, аны почта аша алырга каршы түгеллегемне белдереп тамга куям. Ярар, Мураками, хәзер мин сине көтеп барачакмын!

СОҢГЫ СҮЗ УРЫНЫНА

Берничә көннән Аксенов скверына сугылгач, үземнең Бенуа китабын тапмадым. Аның каравы киштәләрдә йолдызнамә һәм фаразлар язылган журнал, яшь бакчачылар өчен кулланма, дини әдәбият ята иде... Ә янәшәдә – Горький хикәяләре, Сухомлинский хезмәтләре һәм Даниэла Стилның кайчандыр бестселлер булган романы. Бәлки, бу китаплар сезне көтәдер?

СҮЗ УҢАЕННАН

Экоактивистлар чаң суга: кәгазь җитештерү сәнәгате ел саен 100 млн гектардан артык урманны юк итә. Өстәвенә, сәнәгатьнең бу тармагына дөньядагы гомуми углерод эзенең 2 проценты туры килә. Әйе, китап индустриясе табигать өчен бер дә файдалы түгел. Хәер, электрон «басмалар» җитештерү дә зыянсыз дип әйтеп булмый. Гаджет сатып алуны экологик сәбәп белән аклау өчен, бу җайланмадан ким дигәндә 23 китап укырга кирәк. Аннан соң бер-бер артлы яңа модель алудан тыелу шарт. Ә типография буявы исе килеп, битләре кыштырдап торган кәгазь басмадан укымасаң, теләсә кайсы мавыктыргыч роман да күңелсез, кызыксыз тоела икән, үзегез өчен буккроссинг дөньяларын ачыгыз – кәгазь китапларның кулланылыш ресурсы мәңгелек диярлек.

ТОП 5

Соңгы елларда туристлар – Россиянең үзеннән килгәннәре дә, чит илләрдән юл тотканнары да – Татарстанны гүзәллеге, кунакчыллыгы, тәмле милли ашлары һәм истәлеккә алып китәрлек үзенчәлекле сувенирлары өчен үз итә. Күчтәнәч бүләкләр арасында китаплар аерым урын алып тора. Төрле шәһәр һәм төбәкләрдән килгән кунаклар белән еш аралашучан «Татарстан» безнең республика буйлап сәяхәт иткәндә очрый торган иң үзенчәлекле китаплар исемлеген төзеде. Кайберләре турында белә идек инде, ә менә кайберләре турында, оят булса да, үзебез дә беренче ишетәбез! Әмма хәзер инде һичшиксез укыячакбыз!

1 ИҢ ЗУР КОРЪӘН КИТАБЫ

Эльмир Солтанбәков, Уфа шәһәре:

– Мин һәрвакытта да иң-иңнәрне генә күреп була торган экскурсияләрне сайлыйм. Шундый иң-иңне мин Болгарда таптым. Ул – дөньядагы иң зур басма Корьән китабы! Китап – үзе бер зиннәт! Туры мәгънәсендә дә, күчерелмә мәгънәдә дә. Кыйммәтле асылташлары ялт-йолт килә, 1,5 га 2 метр зурлыкта булуы белән дә һәм, әлбәттә инде, 800 килограммнан артык авырлыгы белән дә таң калдыра!

Болгардагы китап мөселманнарның иң зур басма Корьәне буларак Гиннесның рекордлар китабына кертелгән.

2 ГОБЕЛЕНДАГЫДАЙ ТАТАР ӘКИЯТЛӘРЕ

Марина Набокова, Самара шәһәре:

– Сәяхәтләрдән һәрвакытта да китаплар алып кайтам, алар, гадәттә, барган урыным турында була. Күтәрергә җиңелләрен сайларга тырышам. Соңгы принципны «Татар халык әкиятләре» хакына беренче тапкыр боздым. Беренчедән, һәрбер әкият өч телдә – татарча, русча, инглизчә бирелгән. Икенчедән, бик зәвыклы битләре гүя гобеленнан эшләнгән... Өченчедән, әкиятләре күп, рәсемнәре искиткеч матур. Татар халык әкият геройлары – Шүрәле, Юха, Су анасы, Камыр батыр турындагы мирас... «Гади генә итеп башланып китә, җиңел генә сөйләнә, матур итеп тәмамлана», – дип яза әлеге әкиятләр турында нәшире Марат Моратов. Әлеге күркәм басманы кызыма Казаннан туй бүләге итеп алдым.

Яшьләргә гобелендагыдай 700 бит әкият бүләк итәм – булачак оныкларыма укырлар!



5 AKHSAN FATKHUTDIN ҺӘМ АНЫҢ ЗИРАТ ТЕМАСЫ

Игорь Махонов, Тверь өлкәсе:

– Хәзер ташландык урыннарга сәяхәт итү модага керде. Миңа иске зиратларда сәйран кылып йөрү ошый. Һәр кабер кызыклы тарих сөйләргә сәләтле. Казанда Арча зиратына экскурсия мине бик тәэсирләндергән иде: төрбәләр, һәйкәлләр, кабер ташлары, сыннар, кәшәнәләр, төрле вакытта куелган хачлар. Ә иң мөһиме, мин Казанда шул темага китап таптым – ул рәссам Әхсән Фәтхетдинов турында. Авторның агач сыннары фотосурәтләренә, аларга салынган мәгънәне аңларга тырышып, сәгатьләр буе карап торырга була. Кайчагында ул мәгънә рәссам көндәлегеннән китерелгән юллардан табыла. Кайчагында исә – шагыйрь Равил Фәйзуллин шигырьләреннән. Анда да кабер ташларына багышланган бүлек бар!

«Зират – фикерләр тупланган изге урын, гыйбадәт кылу урыны, кеше анда үзенең күңелен чистартырга йөри... Аның өстендә һәрвакытта да кылынмый калган гамәлләрдән һәм чынга ашмаган хыяллардан, әйтелмәгән фикерләрдән, бармый калган сәяхәтләрдән кайнар һава эленеп тора... Зиратта адәм баласы буыннар алдында үзен җаваплы итеп тоя...»

Рәссам язмаларыннан

Мөгаен, бу мин күргән иң шәп китаптыр.

ТАТАРСТАНДАГЫ ИҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ КИТАПЛАРНЫҢ БЕРЕНЧЕ БИШЛЕГЕ

3 ИСКЕ ҖӘДВӘЛЛӘР РОМАНТИКАСЫ. КАЗАННАН БЕР КАРАШ

Елена Силеверстова, Ленинград өлкәсе:

– Иске җәдвәлләрдән романтик эчтәлекле китап чыга ала дип кем уйлаган! «Беренче бүлек – тимер юллар», «Икенче бүлек – авиация», «Өченче бүлек – елга порты»... Монда вокзаллар турында да, «баганалар, рельслар, күперләр...» турында да, билетлар да, онытылып барган үткәннәр дә һәм бөтенләй таныш түгел яңалары турында да бар. Китап «Иске җәдвәлләр романтикасы» дип атала. Авторы Лев Жаржевский аны «Казаннан бер караш» дип тәкъдим итә. «Балачакта паровозлар белән мавыгуым үзем дә сизмәстән җәдвәлләр белән кызыксынуга китерде. Башта заманчалары белән, аннан соң элеккеләре һәм иң әүвәлгеләре белән: алар үзенә күрә үткәннәргә тәрәзә кебек... Аннан гомуми вагоннарның өченче киштәләрендә баручылар, Ли-2 самолетларында очучылар һәм елга буйлап йөргән пассажир транспортлары күренә.
Һәм мин әлеге «Казаннан бер караш»ны биш данә сатып алдым – сәяхәтче-романтик дусларыма бүләк итәчәкмен.



4 ТӘТЕШ «МОНТЕ-КРИСТО»СЫНЫҢ «ТӘЭСИРЛӘНДЕРГӘНХЕЗМӘТЕ»

Инга Золотникова, Владивосток шәһәре:

– Александр Дюманың «Граф Монте-Кристо»сы балачактан ук иң яраткан китабым иде. Казанда Вера Фигнерның «Тәэсирләндергән хезмәт»ен очратканчыга кадәр. Мин аны Милли музейда күрдем. Бер битен генә укыдым: «Цитадельнең такта капкалары киң итеп ачылып китте, һәм шунда ук курку хисе соклану белән алышынды. Биш ел минем төнге күкне, йолдызларны күргәнем юк иде. Хәзер ул күк минем өстә, һәм йолдызлар минем өчен балкый. Мәйдан өстенә куе булып үлән үскән; ул йомшак кына итеп аякларга сыдырылып кала, салкынча рәхәтлек бирә... иркен кырның чыклы аланы үзенә дәшә иде...» Казан губернасының Тәтеш өязендә туып-үскән революционер кызны 22 ел буена ялгыз тоткынлык сындыра алмаган, ә менә дигән китап язарга этәргән. **Шул рәвешле уйлап чыгарылган Монте-Кристоның минем йөрәгемдәге урынын чынбарлыктагы тоткын Вера Фигнер ялады.**

МАХСУС ПРОЕКТ

МИНЕМ ӨЙДӘГЕ КИТАПХАНӘМ

Фото: Александр Ефремов
Иллюстрация: Чарльз Высоцкийның «Коты на книжной полке» рәсеме

Ирада Әюпова: «МИНЕМ ӨЧЕН КИТАПЛАР – ГАИЛӘ ӘГЪЗАЛАРЫ КЕБЕК»

Эдуард Вафин: «КИТАПЛАР БУЛМАСА, БҮГЕН КЕМ БУЛЫР ИДЕМ ИКӘН МИН...»

Гүзәл Хисмәтуллина: «СӘБӘБЕ – МӘХӘББӘТ. КИТАП УКУГА МӘХӘББӘТ»

Динә Юнысова: «БАЛАЧАКТАН КУЕНДА ГЕЛ КИТАП БЕЛӘН»

Софья Петрова: «КИТАП – АШЫКМЫЙЧА УКУ СИМВОЛЫ»

Совет чорында китапханә өй күрке була торган иде, дип искә ала СССРда туганнар. Ә хәзер, янәсе, уфтанырга гына кала.

...Элек китапларны танышлык аша гына табалар, шкафның иң күренә торган киштәсенә куялар да әлеге дефицит товар белән винил пластинкаларга караганда да ныграк горурланалар иде!

...Элек кемнең китапханәсендә күпме китап бар, кем күпме укыганлыгы белән ярышалар иде.

...Элек өйдәге китапханә авырган чакта коткара иде... Иң яхшы бүләк иде...

Элек... Элек... Элек...

«Татарстан», безнең заманча патшалыктагы хәлләр ничегрәк тора микән дигән максаттан, республикабызда яшәүчеләрнең өйләрендәге китапханәләре белән танышырга булды. Сезнең игътибарга татарстанлыларның беренче бишлеккә кергән өй китапханәләрен тәкъдим итәбез – аларның күбесе китап сөючеләр ярата торган совет чорыннан ук башланган, бүген дә яңа басмалар белән тулылана, үрчи-яши һәм хуҗаларын кызыклы эчтәлеге белән, битләренең рәхәт кыштырдавы белән сөендереп тора.

VALENTIN YUDASHKIN

Фото: Ната Смирнова.

ИРАДА ӘЮПОВА,

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЫ:

«МИНЕМ ӨЧЕН КИТАПЛАР – ГАИЛӘ ӘГЪЗАЛАРЫ КЕБЕК»

– Мин китап корты. Буш вакытым булса да, еш кына төнлә дә укыйм, кайчагында берничәсен берьюлы укыйм... Миндә китаплар бик күп. Безгә гаиләбез белән еш күченеп йөрергә туры килде, һәм минем өчен яңа йортта китапханә булу төп шарт иде. Хәзер менә тагын күченәбез... Өйдәгеләр миңа: «Без сине китапларың белән бергә чыгарып җибәрәбез!» – диләр. Чөнки күченгән саен китапларны киштәләрдән бушатып, тартмаларга тутыру, яңадан урнаштыру бик мәшәкатьле эш... Мин барысын да аңлыйм, әмма бер генә китабымны да калдырасым килми. Без элек яшәгән Бакудан да бик күп китап төяп кайттык. Алар инде дистәдән артык тапкыр күченеп йөрде, гаилә әгъзалары кебек булып беттеләр.

ИРАДА ӘЮПОВАНЫҢ ИҢ ЯРАТКАН 10 КИТАБЫ:

1. Антуан де Сент-Экзюпери. **«Нәни принц».**
– Кайта-кайта укырга киңәш итәм. Бу китап көч, энергия бирә.

2. Григорий Медынский. **«Намус».**
– Аны укырга миңа әни киңәш иткән иде. Ихтыяр көче, нинди генә мохиттә дә исән кала алу турындагы искиткеч китап.

3. Агалы-энеле Стругацкийлар. **«Юл читендә пикник».**
– Стругацкийларның бар иҗатын яратам. Уйландыра торган менә дигән авторлар.

4. Иван Ефремов. **«Таис Афинская».**
– Әкиятнең ничек итеп тарих өйрәнергә этәргеч булуы турында.

5. Александр Куприн. **«Суламифь».**
– Бик дулкынландыргыч китап. Һәм ул да тарихны өйрәнергә этәргеч бирә.

6. Иван Бунин. **«Караңгы аллеяләр».**
– Бу китапны бөтен үсмерләр дә укысын иде. Ул уй һәм хисләрнең «караңгы аллеяләреннән» чыгарга өйрәтә...

7. Халит Хоссейни. **«Балкып торган мең кояш».**
– Кем үзен начар хис итә – шушы китапны укыгыз. Үзегез яшәгән дөньяны бөтенләй башкача кабул итә башлаячаксыз.

8. Умберто Эко. **«Роза исеме».**
– Бу китапны уйланырга ярата торган кешеләр фәлсәфи караштан торып укырга тиеш.

9. Гаяз Исхакый. **«Теләнче кыз»** һәм **«Мулла бабай».**
– Ирекле һәм гүзәл татар хатын-кызы идеалына узган гасыр башыннан ир-ат карашы. Миңа Исхакыйның кыюлыгы һәм алдынгы карашлы булуы ошый.

10. Аяз Гыйләҗев. **«Өч аршын җир».**
– Халкыбызның милли яшәеш фәлсәфәсен, язмышын аңларга теләгән кеше шушы китапны укырга тиеш.

Гарри Поттер
и тайная комната
СВИФТ
РЕМАРК

Фото: Ната Смирнова

ЭДУАРД ВАФИН,

РОССИЯ ПЕНСИЯ ФОНДЫНЫҢ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДАГЫ БҮЛЕГЕ ИДАРӘЧЕСЕ:

«КИТАПЛАР БУЛМАСА, БҮГЕН КЕМ БУЛЫР ИДЕМ ИКӘН...»

– Рус һәм чит ил классиклары әсәрләренең тулы җыелмаларын минем әбием җыя башлаган. Ул үскән гаиләдә сәнгать әһелләре еш кунак булган – композиторлар Сәйдәшев, Җиһанов, Яруллин. Әбием Муса Җәлилне яхшы белгән. Соңыннан инде әти-әни китапханәне тулыландырган. Соңгы елларда мин дә үз өлешемне кертәм. Китаплар булмаса, бүген кем булыр идем икән мин?.. Алар минем тормышыма фаҗигале шартларда килеп керде – икенче сыйныфта укыганда, умыртка баганасын сындырып, бер ел караватта ятарга мәҗбүр булдым. Һәм көннәр буе укыдым да укыдым. Бер елдан соң исә мин урамда трай тибеп йөрүче хулиганнан күп укыган малайга әйләндем, мәктәп олимпиадаларында җиңә башладым. Шуңа күрә язмышымдагы ул имгәнүгә мин хәтта рәхмәтле дә.

ЭДУАРД ВАФИННЫҢ ИҢ ЯРАТКАН 10 КИТАБЫ:

1. Марк Твен. **«Том Сойер маҗаралары» һәм «Гекльберри Финн маҗаралары».**
2. Финимор Купер. **«Аучы».**
3. Даниэль Дефо. **«Робинзон Крузо».**
4. Чарльз Диккенс. **«Оливер Твист маҗаралары».**
– Болар инде балачактан укыганнар. Һәрберсе – иң яратканы! Ул чакта бөтен малайлар да укый иде аларны.

5. Джоан Роулинг. **«Гарри Поттер».**
– Миңа Гарри Поттер һәрвакыт булган кебек, гәрчә мин аны улым белән бергә укыдым. Балалар өчен китап, әмма өлкәннәрне дә сокландыра! Мөгаен, укыганда күңелдә әллә нинди гаҗәеп сурәтләр тугангадыр, аларны бернинди кино да кабатлый алмый...

6. Александр Дюма. **«Граф Монте-Кристо».**
– 11 яшьтә йотлыгып укыдым. Һава сулаган кебек укылды ул, шуңа да аны иң яраткан китапларның берсе итеп билгелим.

7. Джером Клапка Джером. **«Этне санамаганда, көймәдә алар өчәү иде».**
– Балаларча самими кебек, әмма чып-чын инглиз юморы. Бер кайгысыз чакта укып, рәхәтләнеп көлгәнемне хәтерлим. Андагы тарихларны бүген дә хәтердән сөйли алам.

8. Теодор Драйзер. **«Финансист».**
– Монысы инде студент вакыттагы хатирәләр. Ул вакытта без: «Финансист»ны укыган – читтән торып белем алган, дип шаярта идек.

9. Харуки Мураками. **«1Q84».**
– Бер тында укыла. Канатлы сүзләре истә кала.

10. Евгений Водолазкин. **«Лавр»** һәм **«Авиатор».**
– Җәй көне шушы язучы белән мавыктым. Үз эченә бөтереп алды, вакыт һәм дәвер тойгысы югалды. Гаҗәеп тойгы. Тагын укыячакмын әле.

СТИГ ЛАРССОН
ДЭН БРАУН
РЕМАРК
Щегол
БЕЗ ГРЕ ШНО СТЬ
ЭЛИЗАБЕТ ХЕЙНС
Тайная история
Sapiens
ЭЛЕЙ
ЮЗНЕСБЕ
СЫН
Соседская девочка
РУБИНА
ГОРЕВ
МАЙЕР
СТЕФАНИ
ХУДАКОВ
Моррисон
CODENAMES
PICTURES
Каркассон
MUNCHKIN QUEST

Фото: Ната Смирнова

ГҮЗӘЛ ХИСМӘТУЛЛИНА,

«ТИМСОФТ» ТРЕНИНГ КОМПАНИЯСЕ ДИРЕКТОРЫ, БЛОГЕР:

«СӘБӘБЕ – МӘХӘББӘТ. КИТАП УКУГА МӘХӘББӘТ»

– Мин нигә китаплар җыям?
Китап яратам.
Балачактан бөтен мәктәп китапханәләре минеке иде.
Төнлә юрган астында фонарь яктысында да укыдым.
Кая гына кунакка барсам да, шундук китап киштәсе янына ашыгам.
«Үз» кешемне укылган китаплары буенча таныйм.
Фатир алганда, иң әүвәл китаплар өчен урын әзерләдем.
Питерга барып, «Подписные издания» кибетенә керсәм – «югалам».
Һәр шәһәрдәге иң яхшы китап кибетләрен беләм.
Сәбәбе – мәхәббәт. Китап укуга мәхәббәт.

ГҮЗӘЛ ХИСМӘТУЛЛИНАНЫҢ ЯРАТКАН 10 КИТАБЫ:

1. Виктор Франкл. **«Тормышка «Әйе!» дияргә».**
– Миңа бары тик бер генә китап сайларга кушсалар, шуны сайлар идем. Авторы – иң куркыныч үлем лагерьларында булган бөек психотерапевт. Нәрсә турындамы? Яшәү мәгънәсе һәм аның һәрвакыт булуы турында.

2. Мария Грипе. **«Эрик Карлсон».**
– Әгәр син бала, тик башкалардан үзгә икәнсең, нишләргә? Ничек үзең булып калырга һәм үзеңнең хәлең яхшы булуда инанырга?

3. Сэм Макбратни. **«Минем сине ничек яратуымны беләсеңме».**
Бу китап һәр өйдә булырга тиеш. Ул ата-ана һәм балалар мәхәббәте хакында. Ата һәм улныңярату тулы сөйләшүе искиткеч иллюстрацияләр белән баетылган.

4. Ромен Гари. **«Бөтен гомер алда әле».**
– Аушвиц лагеренда исән калган карт яһүдә Роза өендәге приютта тәрбияләнүче ятим гарәп малае турында. Мәхәббәт хакында! Тормышны ярату хакында.

5. Даниил Гранин. **«Тормышны үзгәртеп булмый».**
– «Тормышны үзгәртеп булмый, әмма аның турында кат-кат уйланып була» дип раслаган «Блокада китабы». Аңларга тырышу кыюлыгы хакында.

6. Марина Цветаева. **Шигырьләр җыентыгы.**
– Марина Цветаева – 15 яшьтән бирле яраткан әдибем. Бөек шагыйрь. Тирән, ихлас, тиңдәшсез.
«Нәзакәтле, затлы шәрабларның
Үз чираты җиткән шикелле
Чират җитәр минем шигырьләргә! –
Һәм аларның килер үз көне».
Шулай булып чыкты да.

7. Ицхак Адизес. **«Шәхси үсеш хакында уйланулар».**
– Шәхси үсеш хакында уйланулар – тукталырга һәм үз күңелеңә күз салып, кем өчен, нәрсә өчен яшәвең һәм эшләвеңне аңлау өчен сәбәп ул.

8. Антон Чехов. **Хикәяләр.**
– Нинди илдә яшәсәң дә, теләсә кайсы китапханәдә бу китап булу мәҗбүри.Аны әллә ничә тапкыр укып та туйдырмый.

9. Гүзәл Яхина. **«Зөләйха күзләрен ача».**
– Әбием дә Зөләйха исемле иде, һәм минем аңардан ишеткәннәрем китапның беренче бүлекләрендә сурәтләнгән вакыйгаларга тәңгәл килә. Автор безгә тарихи хәтерне кире кайтара.

10. Оливия Лэнг. **«Ялгыз шәһәр».**
– Ялгызлык сәнгатендә күнекмәләр. Ялгызлык, сәнгать һәм шәһәр арасындагы катлаулы үзара мөнәсәбәтләр хакында.

Фото: Рамил Гали

ДИНӘ ЮНЫСОВА,

«ТАТАРСТАН ГҮЗӘЛЕ – 2021»:

«БАЛАЧАКТАН КУЕНДА ГЕЛ КИТАП БЕЛӘН»

– Һәрбер кешенең бер мавыгуы була – ул аңа буш вакытын багышлый, шуннан үзе өчен рәхәтлек ала. Мин китап уку белән мавыгам. Бәләкәй чактан ук куенымда китап йөртә идем...
Миңа һәрбер геройның маҗаралары белән яшәү, шул вакытка, шул урынга күчү ошый. Фикерләреңне авторныкы белән чагыштырып, үзеңне әсәр герое урынына куеп карау кызык.
Һәрбер укыган китабым минем үсешемә үз өлешен кертте. Һәркем белән шулай буладыр дип уйлыйм – китаплар безне яхшырак итә.

ДИНӘ ЮНЫСОВАНЫҢ ИҢ ЯРАТКАН 10 КИТАБЫ:

1. Лев Толстой. **«Сугыш һәм солых».**
– Мәңгелек классика, мин аны теләсә кайчан укый алам.

2. Шарлотта Бронте. **«Джейн Эйр».**
– Чын хисләр турында китап. Үз мәхәббәтенә тугры калган нык ихтыярлы кыз хакында.

3. Грегори Дэвид Робертс. **«Шантарам».**
– Миңа бу китапта бөтен нәрсә ошый: сюжетның динамикалы булуы да, геройларның рухи үзгәрешләре дә, һәрвакытта да актуаль булган тормыш хикмәтләре дә.

4. Джейн Остин. **«Горурлык һәм Хорафат».**
– Горурлыкны да, алдан ук начар фикердә булу вәсвәсәсен дә, теләсә кайсы кешенең холкын да үзгәртә алырдай мәхәббәт турында.

5. Пауло Коэльо. **«Алхимик».**
– Бу китап хыялланырга һәм теләкләреңнән курыкмаска өйрәтә.

6. Вадим Зеланд. **«Чынбарлык трансерфингы».**
– Минем тормышымны үзгәрткән китап, шуны укыганнан соң, мин үземнең чынбарлыгымны үзем кора башладым.

7. Джоан Роулинг. **«Гарри Поттер».**
– Минем балачакта иң яратып укыган китапларым! Һәрбер кисәген яратам, кабат-кабат укыйм.

8. Дэниел Киз. **«Элджернонга чәчәкләр».**
– Бу китапның төп мәгънәсе шунда: нинди генә интеллектуаль дәрәҗәдә булмасын, һәрбер кеше тиңдәшсез, уникаль.

9. Аллан һәм Барбара Пиз. **«Җавап».**
– Яшәргә этәргеч бирә торган искиткеч китап! Максатларны дөрес куеп, шуларга омтылып яшәргә өйрәтә.

10. Джоджо Мойес. **«Синең белән очрашканга кадәр».**
– Көзге кичләрдә укыр өчен рәхәт китап...

PRESSA

МИР КНИГИ
Е.Л. Немировский
MODÈLES
DES CARACTÈRES
DE L'IMPRIMERIE
МАРКЕТИНГ
МАРКЕТИНГ
МАРКЕТИНГ
БИЗНЕС-ПЛАНИРОВАНИЕ
УСПЕШНЫЙ БИЗНЕС-ПЛАН
БИЗНЕС-ПЛАН
Секьюрити
СОВЕТ ДИРЕКТОРОВ
ОРГАНИЗАЦИОННОЕ ПОВЕДЕНИЕ
ОРГАНИЗАЦИОННАЯ КУЛЬТУРА
СЕРВИС
СЕРВИС
ПРАКТИКУМ ПО МАРКЕТИНГУ
ПРАКТИКУМ ПО МАРКЕТИНГУ
МАРКЕТИНГ
МАРКЕТИНГОВЫЕ ИССЛЕДОВАНИЯ
МАРКЕТИНГ ОТ А ДО Я
МАРКЕТИНГ МЕНЕДЖМЕНТ
Секьюрити
MBA

СОФЬЯ ПЕТРОВА,

18 ЯШЬ, БДИ БУЕНЧА 200 БАЛЛ ҖЫЮЧЫ:

«МИНЕМ ӨЧЕН КИТАП – АШЫК-МЫЙЧА ГЫНА УКУ СИМВОЛЫ ҺӘМ ТЕКСТТАН ЛӘЗЗӘТ КИЧЕРҮ»

– Минем әти-әнием спорт белән мавыга, аларның эше дә, тормышы да шуңа бәйле, шунлыктан безнең өйдәге китапханәдә һәрвакытта да җиңел атлетика буенча журналлар, спорт турында китаплар була иде. Мөгаен, алар төп урынны алып торадыр да. Минем иң беренче яратып укыган китабым – «Сказочник» журналлары булды. Анда бөтен дөньяга билгеле әкиятләрне бастыралар, мин аларны йотлыгып укый идем. Әти-әнием миңа Disneyның ул вакытта популяр булган «Рататуй», «Галәветдиннең тылсымлы лампасы», «Арыслан король» мультфильмнары буенча «Иң яраткан әкиятләр» дигән китапларын ала иде. Мин үскән саен китапханәдә яңа китаплар барлыкка килә торды. Хәзер исә анда классик әсәрләр күп, мин аларны мәктәп программасы буенча укыдым. Мин китапларны дустым дип кабул итәм. Әдәбият безгә олы, тирән тормыш тәҗрибәсе бирә. Ул безне зыялы итә, гүзәллекне күрергә, тормышны аңларга өйрәтә, башка дәверләр турында сөйли. Хәзерге мәгълүмати технологияләр заманында төрле чыганаклардан укырга мөмкин. Әмма минем өчен нәкъ менә кәгазьгә басылган китап – ашыкмыйча уку символы, укыганда, син эчтәлек белән мавыгып китәсең, тексттан ләззәт кичерәсең.

СОФЬЯ ПЕТРОВАНЫҢ ИҢ ЯРАТКАН 10 КИТАБЫ:

1. Дмитрий Лихачев. **«Игелек һәм гүзәллек турында хатлар».**
– Элгәреге буыннар тәҗрибәсе аша үзеңне табу һәм аңлау турындагы китап.

2. Борис Екимов. **«Сөйлә, әни, сөйлә».**
– Әти-әниләргә балалар игътибарының ни дәрәҗәдә мөһим булуы бәянләнә.

3. Александр Грин. **«Яшел лампа».**
– Язмышның кинәт кенә безнең файдага барысын да ничек үзгәртүе хакында.

4. Андрей Геласимов. **«Алдау елы».**
– Баланың үсеп буйга җитүе турында мавыктыргыч китап.

5. Татьяна Тэсс. **«Вакыт сакчысы».**
– Адәм баласының вакытны буйсындыру юлын табуы хакында сөйләнә.

6. Александр Куприн. **«Гаҗәеп доктор».**
– Кешеләр үзләренә һәм бер-берсенә ышанганда нинди могҗизалар тууын күрсәткән китап.

7. О. Генри. **«Рус кешләре».**
– Яраткан кешеләребезгә, мөгаен, ныграк ышанырга кирәктер. Бу китап шуңа өйрәтә.

8. Ричард Матесон. **«Төймә, төймә».**
– Катлаулы әхлакый-этик хәлдә калганда нәрсә булуы мөмкин?

9. Александр Куприн. **«Изге ялган».**

10. Борис Екимов. **«Савыгу төне».**

– Бу авторларның хикәяләре икесе дә бер нәрсә турында: кайчак безне бары тик шәфкатьлелек кенә коткара ала.

РЕДАКЦИОННАЯ КУХНЯ

ГАДЕЛ ХӘЕРОВ ЛЕВ ТОЛСТОЙНЫ СЫЙЛЫЙ

Автор: Татьяна Вафина

Еш кына рухи азык физик тәгамгә әйләнергә мөмкин. Иң туры мәгънәсендә. Кайвакыт нәфис әдәбиятта тәмле ризык әзерләү шундый мавыктыргыч итеп сурәтләнә ки, һичшиксез аны үзеңнең дә авыз итәсең килә башлый. Безнең очракта китап та, герой да, ризык та, урын да бер ноктада тупланган булып чыкты. Әлеге тәгам белән яшь һәм әле сакалсыз Лев Толстойны сәүдәгәр хатын Анфиса Бородулинаның Казан (хәзерге Миславский) урамындагы йортында сыйлаганнар, ул аның кызы Настасьяга илтифат күрсәтеп йөргән икән.
Хәзер биредә кафе-музей урнашкан. Шунда ук кечкенә генә кунакханә дә эшли, анда «Морзалар», «Сәүдәгәрләр», «Ханнар» номерлары гына түгел, «Язучылар» номеры да бар. Безнең язучыбыз Гадел Хәеров иртүк нәкъ шул бүлмәдән чыкты да, җиңнәрен сызганып, «Татарстан» журналын графларча сыйларга вәгъдә бирде!

АЛМАДАН... ТАВЫК ГӨМБӘСЕ

– Гадел, нәкъ менә биредә, нәкъ менә Лев Толстойны һәм нәкъ менә шул ризык белән сыйлаганны сез кайдан беләсез? Әллә, бөтен язучылар кебек үк, сез дә үзегезнең һәр «тәгамегезгә» бер чеметем уйдырма кушасызмы?

– Бернинди уйдырма да юк монда! Бу турыда сәүдәгәр хатынның оныгының улы, 69 яшьлек Зосима Михайлович хатыннан мәгълүм булды, анда ул үзенең әбисе Акулинадан ишеткәннәрне бәян итә. Әлеге хатирәләр гаиләдә кадерләп саклана. Анфиса Бородулина гаиләсе революциядән соң Канадага күчеп китә, узган гасырның 70 нче елларында карт шунда яши. Лев Толстойның тууына 150 ел тулуны билгеләп үтәргә җыенган Рус теле җәмгыяте әгъзаларына тәгаенләнә әлеге хат, алар язучының Варшава, Париж, Рим, Берлин, Баден-Баден, Лондон, Мәскәү һәм Казандагы тормышы турындагы хатирәләр җыентыгына материаллар һәм акча җыя.

Зосима Ермолаев сәүдәгәр Бородулина йортындагы мәҗлесне менә шулай тасвир-

Фото: Ната Смирнова

БЕЗГӘ КИРӘК БУЛАЧАК:
- тавыкның түш ите – 400 г;
- каты сортлы алма – 4 данә;
- «Украинский» сортлы бер бөтен кара икмәк;
- укроп – берничә сабак;
- мүк җиләге – бер уч;
- тоз, борыч – тәменчә.

1
«Язучылар» номеры. Безнең язучыбыз Гадел Хәеров иртән нәкъ шуннан килеп чыкты да...

2
Әлеге җанны җылыта торган эчемлекнең рецепты сакланган. Кунаклар килер алдыннан аңа ике шешә кызыл шәраб (яки «Кодрянка» сортлы йөзем согы) салганнар. Болгатмыйча гына өч аш кашыгы бал, өч-дүрт дәфнә яфрагы, берәр чеметем хуш исле борыч, канәфер һәм кипкән барбарис җиләге өстәгәннәр. Бәбрия ботагы да кушып җибәргәннәр. Аннары спиртовканы кабызганнар да сүрән утта берәр сәгатьләп тәнәткәннәр...

1

2

лый (аның буталчыграк хатын бераз кыскартып һәм тәртипкә китереп тәкъдим итәбез – ред. иск.): «Это был званый обед. Лев Николаевич явился в назначенный час с коробкой миндального печенья. За столом, кроме Анфисы Михеевны и её дочери Настасьи, за которой собственно и ухаживал граф, был ещё управляющий по имени Дорофей. Он тоже питал симпатию к Настасье и даже имел по этому поводу разговор с графом. Вроде бы собирались стреляться на «Чёрном озере», но обошлось. Она, судя по единственному сохранившемуся фотопортрету, была недурна. На стол в тот день подавали кролика, фаршированного яблоками. Имелось своё подворье, где разводили кроликов и индюшек с курами. Поросят держали. Были и козы для молока. Не раз городовой их за рога приволакивал с улицы Воскресенской и грозил штрафом. Всё это большое хозяйство располагалось под стенами Кремля. Тут же огород с картофелем, луком, репой и стеклянная теплица с огурцами. Капуста тоже была. Без солений жизни не представляли. После кролика принесли уток, настрелянных на Казанке, и карасей в сметане. А перед сладким пирогом с яблоками и засахаренными грушами внесли тарелку с «Куриными грибочками». По рассказам бабушки, готовили их следующим образом. На сковороде жарили до хруста сухарики из ситного хлеба, посыпанные солью. На это уходило два больших круглых хлеба по фунту каждый, что получается почти килограмм. Одновременно с этим на другой сковороде в сливочном масле жарили медальоны из курицы, предварительно замоченные в винном маринаде. Медальоны нарезали размером с николаевский рубль. Срезали с красных яблок щёчки. Дальше высыпали в тарелку сухарики – это «земля» для грибочков. Белые ножки делали из медальонов, складывая их друг на друга. Сверху надевали нарезанные яблоки и снова ставили в разогретую печь минут на пять, но огонь сбивали. Перед тем, как подать на стол, в «землю» втыкали веточки укропа, рассыпали клюкву. Ели руками. Лев Николаевич остался доволен. Очень хвалил».

БИШ КЕШЕЛЕК ПУНШ

«Тавык гөмбәсе» композициясен тиз арада ясап куеп һәм сохари, тавык ите, алма «эшләпәләреннән» гыйбарәт «аппликацияне» мичкә тыгып, язучы-пешекчебез Анфиса Бородулинаның элекке йортында урнашкан кафе-музей буйлап безнең өчен мавыктыргыч сәяхәт оештыра. Безгә сәүдәгәрләр көнкүрешендә кулланылган чын предметларны күрсәтә. Алар арасында Парижданкайтартылган спиртовкалы нәфис савыт та бар, бульотка (французча bouillir – «кайнату» сүзеннән) дип аталган әлеге савытта хатын-кызлар өчен пунш әзерләгәннәр.

– Әлеге җанны җылыта торган эчемлекнең рецепты сакланган, – дип аңлата безгә Гадел

Рево улы. – Кунаклар килер алдыннан аңа ике шешә кызыл шәраб (яки «Кодрянка» сортлы йөзем согы) салганнар. Болгатмыйча гына өч аш кашыгы бал, өч-дүрт дәфнә яфрагы, берәр чеметем хуш исле борыч, канәфер һәм кипкән барбарис җиләге өстәгәннәр. Бәбрия ботагы да кушып җибәргәннәр. Аннары спиртовканы кабызганнар да сүрән утта берәр сәгатьләп төнәткәннәр...

...Кунак бүлмәсендәге хатын-кызларның, пасьянс салганда, гайбәт сатулары һәм әлеге хуш исле эчемлекне йотып куюлары шундук күз алдына килеп басты. Бармакларын пешермәс өчен, җиз аяклы махсус рюмкадан эчкәннәр – менә алар. Пыяла белән җиз арасындагы һава катламы рюмканы җылынудан саклаган.

– Әгәр өегездә нинди дә булса сәбәп белән XX гасыр башы бульоткасы юк икән, пуншны гади кәстрүлдә әзерләргә туры киләчәк. Әмма бу инде чын пунш булмаячак! – дип хафалана пешекчебез.

Ә биредә спиртовкада Париждан кайтартылган чын бульоткада пунш кайнап маташа. Без бик вакытлы кергәнбез булып чыга!

БЕЗгә КИРӘК БУЛАЧАК:

- кызыл шәраб (яки карасу төстәге йөзем согы) – 2 литр;
- чәчәк балы – 3 аш кашыгы;
- дәфнә яфрагы – 3–4 данә;
- хуш исле борыч, канәфер һәм кипкән барбарис җиләге – берәр чеметем;
- бәбрия – 1–2 ботак.

КЫРЫМ ЛАВАНДАСЫ БЕЛӘН СӘҮДӘГӘРЛӘР ЧӘЕ

Җиз аяклы рюмкадан йөзем пуншын эчә-эчә, экскурсия үткәрүчебезнең Казан сәүдәгәрләренең йомычка белән кайнатыла торган Тула самоварын модалы бульоткалардан һәм каһвә туркаларыннан барыбер артыграк күрүе хакында сөйләвен тыңлыйбыз. Таза гәүдәле Анфиса Бородулина фотосурәтенә карап торгач, ирексездән Гончаровка ышана башлыйсың – ул бер сәүдәгәр хатынының 40 чынаяк чәй эчүен, аннары әле баздан нарат җиләге куасы китертүен үзе уйлап чыгармаган икән бит. Ул чакта шундый зур һәм таза кешеләр яшәгән шул!

– Ул заманда эчмәгәннәр, ә чөмергәннәр; ашамаганнар, ә тукланганнар, – ди Гадел. – Беркая да ашыкмаганнар, өчәр сәгать чәй эчкәннәр. Иртәнге ашка икесенә бер зур балык бәлеше, аннары егерме дүртешәр кура җиләге бөккәне белән сыйланганнар. Мәкле клиндерләрне санап та тормаганнар, алар самоварда матурлык өчен түгел, бәлки кайнар булсын өчен эленеп торган.

Яшел чәйне үз итмәгәннәр, аны өлгермәгән дип санаганнар. Фаянс чәйнектә бары тик һинд яки цейлон чәе генә пешергәннәр. Шуңа берәр чеметем мәтрүшкә, сары мәтрүшкә, чабыр кушканнар. Бераз бөтнек һәм Кырым лаван-

3
Бармакларын пешермәс өчен, хатын-кызлар пуншны җиз аяклы махсус рюмкадан эчкән – менә алар!

4
Казан сәүдәгәрләре йомычка белән кайнатыла торган Тула самоварын модалы бульоткалардан һәм каһвә туркаларыннан барыбер артыграк күргән. Менә сезгә рецепт:
– эре яфраклы кара чәй – 2–3 аш кашыгы;
– киптерелгән мәтрүшкә, сары мәтрүшкә, чабыр, бөтнек – берәр чеметем;
– лаванда – өч чеметем;
– шикәр яки бал – татлы булсын өчен.



5

Чәй пешерү чын ирләр эше саналган. Хатын-кызлар ыгы-зыгылы, ә биредә ашыгырга ярамый. Чәй моны яратмый. Ә менә бу чәйнектән бәләкәй чагында безнең опера сәхнәсе йолдызы Аида Гарифуллина эчкән. Кафе-музейга чәйнекне аның әнисе бүләк иткән.

6

Бүгенге «Редакция кухнясы» сәбәпчесе – яшь һәм әлегә сакалсыз граф Лев Толстой һәм аның Казандагы мәгъшукасы Настасья Бородулина.

дасы өстәгәннәр. Үләннәрне авылдан алып килгәннәр, анда аларны эш рәтен белүче әби җитәкчелегендә кызлар җыеп киптергән.

Чәйнеккә суны яртылаш кына агызганнар һәм, «суласын» өчен борынын ачык калдырып, тастымал белән каплап куйганнар. Өч минуттан соң кайнар су өстәп, чирек чынаяк агызып алганнар да, кире чәйнеккә салганнар. Шулай өч тапкыр кабатлаганнар.

Боларның барысын да Гадел Хәеров безгә тәмләп сөйләп кенә калмады, Миславский урамы тротуарында туристларны кызыктырып самовар кайнатып, эшләп тә күрсәтте. Әлеге чәй церемониясен дистәләрчә телефон камерасы төшереп алды һәм шул мизгелдә үк төрле социаль челтәрләрдә бөтен дөньяга таратты. Менә сиңа мә!.. Татарстан язучыларының китапларыннан башка да гаҗәпләндерер әйберләре күп икән бит ләбаса!

– Рус сәүдәгәрләре көмеш савытлы стаканнан, татарлар исә фаянс касәдән эчкән, – дип икесен дә туристларга күрсәтә Гадел. – Куе чәй яратканнар. Майлы сөт салганнар (саран инглизләр кебек өч тамчы гына түгел, чирек стакан). Кышын лимон белән эчкәннәр. Язын тәүге кура җиләге яфраклары һәм карлыган җиләге җимешләннәре белән пешергәннәр.

Һичшиксез татлы булырга тиеш булган. Шикәр чәйнең тәмен ача, дип саналган. Ул бакалея кибетләрендә башы белән сатылган, аны ваткыч белән ватып, кечкенә кисәкне чынаяк тәлинкәсенә куйганнар һәм өстенә кайнар чәй агызганнар. Шикәр эрегән һәм чәйне балландырган. Кайберәүләр шикәрне тешләп эчкән. Татарлар балны атланмай белән тигез микъдарда кушып, бал-май белән эчәргә яраткан.

ЧЫН ИРЛӘР ЭШЕ

Чәй пешерү чын ирләр эше саналган. Хатын-кызлар ыгы-зыгылы, ә биредә ашыгырга ярамый. Чәй моны яратмый. Һәр чәйханәченең үз рецепты, үз сере булган. Менә, мәсәлән, «Яма» повестенда Александр Куприн чәй церемониясен болайрак тасвирлый:

«Искусство заваривать чай – великое искусство. Ему надо учиться в Москве. Сначала слегка прогревается сухой чайник. Потом в него всыпается чай и быстро ошпаривается кипятком. Первую жидкость надо сейчас же слить в полоскательную чашку, – от этого чай становится чище и ароматнее... Затем надо вновь налить чайник до четверти его объема, оставить на подносе, прикрыть сверху полотенцем и так продержать три с половиной минуты. После долить почти доверху кипятком, опять прикрыть, дать чуточку настояться и у вас... готов божественный напиток, благовонный, освежающий и укрепляющий».

– Ягъни дөрес әзерләнгән чәйдән авыз итү өчен Мәскәүгә барырга кирәкмени?

– Куприн бит Казанда булмаган, әгәр бирегә килсә, чәйне дөрес итеп пешерергә бары тик татарлардан гына өйрәнергә кирәк, дип язар иде. Ә бит язучы үзен татар, Аксак Тимер нәселеннән, дип санаган! Мәскәү трактирларында чәй тәмле булмаган, анда хәйләләгәннәр – эчелгән чәйне киптереп, яңадан пешергәннәр. Безнең Иске Татар бистәсендә мондый алдакчы чәйханәче бер көн дә эшли алмас иде. Ялганлавын белгәч, аннары аны хәтта мунчачы итеп тә куймаслар иде!

АЛМАЧУАРЫМ ДӨНЬЯ ГИЗӘ

Хәеров пешергән чәйне эчкәндә нәкъ менә әдәбият турында сөйләшү мантыйкка ярашлы да инде. Чөнки безнең пешекчебез шул казанда кайнаган кеше. Күптән түгел интернетның төрле китап сату кибетләрендә аның «Подкова Тамерлана» дигән яңа китабына тап булдык, язучы талантына мөкиббәннәр «сурәтләү өслүбе өчен, хикмәтле челтәргә үрелеп, тойгылар – исләр, авазлар, тәмнәр дөньясына, тирән һәм салмак эчке дөньяга чумдырган сүзләр өчен...» аны «чын библиотерапиягә» тиңли.

– Теләсә кайсы язучы тормышындагы шундый әһәмиятле вакыйганы сез ничек матбугаттан ишетерә алдыгыз?

– Германиядән миңа моңа кадәр бөтенләй таныш булмаган шагыйрь (һәм шул ук вакытта Киевтагы «Крещатик» әдәби журналының баш мөхәррире) Борис Марковский язып, проза китабымны бастырырга тәкъдим иткәч, мин үзем дә гаҗәпкә калдым.

Килешү шартлары буенча мин нәшрияттан авторга тәгаенләнгән бер төргәк китабымны, алар исә китапны бөтен дөнья буйлап тарату хокукын алды. «Подкова Тамерлана» дигән хикәяләр җыентыгы Харьковтагы «Каяла» нәшриятында басылды, ике айдан соң Санкт-Петербургтагы «Алетейя» нәшрияты аны кабат бастырды.

Интернетта күрәм: ул Мәскәүдә Тверь урамындагы, Санкт-Петербургта Нева урамындагы китап кибетләрендә, тагын әле Украинада, Белоруссия, Казахстан, Австралия, Швеция, Норвегия, Бөекбритания, Италия, Канада һәм АКШта сатыла. Тик нигәдер Казанда гына юк.

– Бәлки, безгә әле кайтып җитмәгәндер?

– Бәлки шулайдыр.

– Украиннар китапны бик шәп тарата. Сезнең «Підкова» андагы «Көзнең гадәти булмаган биш китабы» рейтингында, беренче урындагы Пауло Коэльодан гына калышып, икенче урынга куелган. Гадел Хәеров өчен, үзебезнекеләр өчен горурлык хисе тудыра бу!

– Туган телләр елында миңа украин тәнкыйтьчесенең саф украин телендә минем турында язганнарын уку бик кызыклы булды: «Незвично у ційкнижці те, як за текстами її автора, у чиему прізвищів'ється розкішний «хайр» бунтівника, ниніпишутьсянауковіпраці про міф Казані. Здається, ми давно вжезрозуміли, що на «великих віхах» та іншій «колективнійпам'яті» у розмові про наше минуле далеко не зайдеш, і цінністьмаєлише так звана мікроісторія. З осколківякої і складається калейдоскоп життя...»

Аларның минем китабымны ни өчен бастыруларын һаман аңламыйм әле. Ул бит хәтта Кырым татарлары турында да түгел. Ул борынгы Казан һәм Идел буе татарлары хакында. Хәер, болар берсе дә мөһим түгел. Иң мөһиме, бәхетле очрак нәтиҗәсендә, мин җирле әдипләрнең кысан аранынан иркенгә, һөрлеккә чыга алдым – хәзер минем аргамагым илләр гизә һәм дөньяның төрле почмакларында кибет киштәләреннән сатып алучыларны көзли.

ХӘЗЕРГЕ ӘДӘБИЯТ ТУРЫНДА ФИКЕР КЫЙПЫЛЧЫКЛАРЫ

– Сез үзегез күбрәк язучымы, әллә укучымы?

– Мин үземне язучыга санамыйм. Шунлыктан үземне иҗатчы дип атыйм. Безнең



7

Менә ул – «Подкова Тамерлана»!



ЗАЯВЛЕНИЕ

Прошу принять меня в члены Союза писателей СССР

1. Фамилия Хаиров имя Адель отчество Ревович
2. Литературный псевдоним Монрес
3. Начало литературной работы с 1980 г.
4. Литературный жанр поэзия и проза
5. На каком языке пишет русский
6. Домашний адрес и телефон г. Казань, Лахудровский пер. дом 2

ПРИЛОЖЕНИЕ: а) Личный листок по учету кадров.
б) Автобиография.
в) Справка об опубликованных произведениях.
г) Фотокарточка 6 х 9 см.
д) Две фотокарточки 3 х 4 см.

21 сент. 1989 г.
подпись

8

Мине СССР Язучылар берлегенә әгъза итеп алуыгызны үтенәм... 1989 ел.

заман язучыларында ниндидер прагматизм бар. Алар ниндидер йөкләмә үти кебек тоела, нәрсәдәндер шикләнәләр... Ачылырга, күңелдәгесен күрсәтергә куркалар. Тәнкыйть белән каләмдәшләрен үпкәләтүдән куркалар. Хакимияткә якынрак булырга тырышалар. Ялагайланалар. Дипломнарга, мактаулы исемнәргә күмеләләр. Алар канат очлары киселгән казлар кебек ирексез. Каңгылдашып, көньякка китеп баручы кардәшләре артыннан йөгерәләр, әмма якындагы җылы сазлыкка кадәр генә барып җитәләр. Юк, бу инде хөр кыр казлары түгел. Бу – бәлеш өчен ит кенә хәзер!

Бервакыт моңсу көзге шәһәр буйлап йөрергә чыктым. Агачлар узган-барганның башына алтын тәңкәләрен коя. Әчкелтем төтен исе килә. Толстой бакчасындагы эскәмиядә модасы чыккан эшләпә кигән бер язучы шакмаклы кепка кигән пижон кыяфәтле иекнчесеннән сораша:

– Йә, Язучылар берлегендә нинди яңалыклар бар анда?

– Барысы да искечә лә, – дип көрсенә икенчесе. – Язучылар яза, укучылар исә укымый.

– Ә мәңгелек классика ни хәлдә?

– Бүген Довлатов анекдотлары да классикага санала бит. Губерман яки Гришковецка гына мөкиббәннәр дә очрый. Аларны башка беркем дә кызыксындырмый. Тагын, Кара һәм Урта диңгездәге бөтен комлыкларда Донцова белән Марининаны укыйлар инде! Хатын-кызлар, билгеле. Яшьләр исә бары тик бизнес һәм психология буенча махсус әдәбиятны гына өйрәнә.

Ял итүче эшкуарлар компаниясе Пушкинны мактады. Колагымны шомрайтып тыңлый башлаган идем, аларның Мәскәүдәге шагыйрь исеме белән аталган ресторан турында сөйләшүләре ачыкланды. «Мещанча чуртан башы» һәм «А-ля Пушкин бәрәңгесе белән каймаклы беф-строгановъны» мактыйлар. Алар шагыйрьне ашказаннары белән ярата икән!

Китап кибетенә кергән идем, кичәге бестселлерның (кулакларны эзәрлекләү хакында татар әбисе сөйләгән экиятләрнең оныгы бәянләвендәге тарихның) бәясе төшерелгән товар кебек ишек төбендә өелеп ятуын күрдем. Аны хәзер инде алмыйлар, туйганнар, гарык булганнар...

– Бигрәк тә хафаланырлык икән бит хәлләр болай булгач... Ә сез үзегез нинди китаплар укыйсыз соң?

– Әлбәттә, минем өйдә аның ише әдәбият юк. Хәзерге заман язучыларына шикләнебрәк карыйм. Чынлап әйткәндә, хәтта җирәнәм дә. Мин өслүбне бәяли белүчене эзлим, ул укып кына калмый, бәлки әсәрнең аерым урыннарын тәмләп кабат-кабат укып хозурлана: «Двор был тесный; всюду, наваливаясь друг на друга, торчали вкривь и вкось ветхие службы, на дверях висели – как собачьи головы большие замки».

Үзен, Казанда рухи яктан тудым, дип саныган классиктан менә дигән образ бит бу! Әлеге өземтәне исә мин аның реалистик повестеннан алдым – анда ул Балык рәтләрендәге үзе камыр баскан пычрак икмәк пешерү йортын һәм аның хуҗасын сурәтли.

Гадел кулына тагын бер калын китап ала, аннан астына карандаш белән сызылган юлларны укый.

– Язучыны да, аның җәүһәрен дә танырга тиешсез:

«...думал Гриша неясные думки, пытался и не мог поймать увиливавшие от сознания скользкие шматочки мыслей»; «Курчавый обыневший чуб его висел из-под надетой набекрень папахи белой виноградной кистью».

1 Турыйбыз

2 Кыздырабыз

3 Буләбез

4 Кыздырабыз

5 Кисәбез

6 Җыябыз

7 Теләк телибез

Яки менә тагын: «Мимо проковылял, плямкая губами, бледный Сергей Платонович».

«Плямкать» сүзенең нәрсә икәнен белмәсәк тә, биредә аны хәтта аңлату да таләп ителми. Белмәсәк соң? Әлеге сүзне без тоябыз, ул безнең күзгә бәрелеп, абзыйның иреннәрендә биеп тора.

ӘДӘБИ ФАРШ

– Бүгенге әдәби-кулинария гамәлебез телендә сөйләшүне дәвам итсәк, сез безнең укучыларыбызга нинди «ризыкларны» татып карарга киңәш итәр (яки киңәш итмәс) идегез?

– Әлбәттә, Михаил Шолоховның «Тын Дон» яки Максим Горькийның «Хуҗа» әсәрләрендәге сүз җәүһәрләре белән хозурланырга сәләтле укучыбызга заманча әдәбиятның сыткы һәм бетчәләре; авторлары текст, дип атаган ниндидер хикәясыман әкәмәтләр бер дә кызык түгел инде. Бу шеф-пешекченең залга чыгып: «Сезнең, билгеле, ниндидер яңа ризык татып карыйсыгыз киләдер, шунлыктан мин үземнең данлыклы «Сөякле хан кәтлитен» әзерләмәскә, ә сезне чи фарш белән сыйларга булдым!» – дип игълан итүенә тиң. Һәм менә официантлар көмеш подносларда баш хәрефләрсез һәм өтерләрсез «әдәби фарш» алып чыга:

«света любит аперитив с яичницей – и в выходные дни часто этим завтракает. пить аперитив и заедать яичницей очень здорово. так вкусно что хочется плакать. аперитив – это горечь на травах. крепко, но легко. а потом Света едет на северную окраину и там гуляет...

сли койка – светина сестра, то брат у светы – с балкона велосипед. она на нем не ездит – потому что может упасть. света коротко стрижется. выпал снег. наступила зима. анемоны рядом».

...Кулыма чәнечкемне тоткан килеш, мин әлеге бина һәм әлеге ризык турындагы бәяләмәләрне укып карарга булдым. Һәм чак кына урындыктан егылып төшмәдем! «Гурманнардан» берсе яза: «Это тот самый случай, когда ты не хочешь дочитывать книгу. Цедишь её по капле, со страхом заглядывая вперёд, не закончится ли? Настолько проникновенно, глубоко... Каждый герой оживает в воображении. Каждая буква, каждое слово. Однозначно, теперь это любимая из книг».

Безнең кайсыбыздыр акылдан язган ахрысы. Һәм мин кайсыбыз икәнен дә беләм...



Редакция тематик «Казанское» кафе-музее кухнясын тәкъдим иткәне өчен «Казан күчтәнәче»нә һәм шәхсән хуҗабикәсе Мәдинә Сабирҗанга рәхмәтен җиткерә.

Узган гасыр башындагы архив язмаларында кафе бинасы «А.Е.Бородулинаның академизм стилендәге гади фасадлы ике катлы торак йорты, XIX гасырда төзелгән, 1872 елда зурайтылган» дип тасвирланган. Бородулиннар гаиләсе икенче катта яшәгән, беренчесендә исә Анфиса Михеевна колониаль товарлар: чәй, каһвә, шоколад, какао, тәмләткечләр, шикәр, тәмәке сатылган кибет тоткан. Күрше Горталов урамында яшәгән яшь Лев Толстой биредән тәмәке ала торган булган, сәүдәгәр хатынның кызы белән дә шул кибеттә танышкан. Кызның туган көненә граф тау баллүреннән ясалган брошка белән морж сөягеннән ясалган шкатулка бүләк иткән, алар Бородулиннар гаиләсендә буыннан-буынга тапшырылып сакланган.

СЫЙФАТЛЫ КИТАП ЯШӘЯЧӘК!



Журналист һәм язучы, ике тапкыр «Большая книга» премиясе лауреаты Шамил Идиятуллин ни өчен «бөтен чүп-чарның кәгазь басмалардан тулысынча диярлек электрон вариантка күчкәнлеге» һәм ни өчен «халыкның маргинал булмаган катлауларында кәгазь китапның гасырларга сакланып калачагы» турында фикер йөртә.

– 15 ел чамасы элек безгә кәгазь китап инде бөтенләй үлеп бетәр кебек тоелган иде, сакланса да, шул берничә сегментта гына – балалар әдәбияты, рәсемле басмалар, комикслар һәм башкалар рәвешендә генә калыр дип күзалладык. Алай булып чыкмады – кәгазь булган өчен генә түгел, ә сыйфатлы итеп басылган өчен, кесәдәге акчасын сарыф итәргә әзерлеге белән үз фикерен белдергән укучылар катламы хәтта ныгый гына шикелле. Шул ук вакытта китап укучылар даирәсе – бу очракта кәгазь басмалар гына түгел, ә теләсә нинди китаплар күздә тотыла – объектив сәбәпләр аркасында тарая бара. Узган гасырда китап хис-тойгы ачлыгын баса торган бердәнбер диярлек чара булса, бүген андый «туендыручылар» бихисап: сериаллар, уеннар, ә иң мөһиме – социаль челтәрләр, һәм аларның һәркайсы өстәмә катламнар һәм мәгънәләр яшеренгән озын-озын иске текстларга караганда күпкә җиңелрәк үзләштерелә.

Шуңа бәйле рәвештә, уку даирәсе дә, дөресрәге, төрле чүп-чардан алып зур әдәбиятка кадәр – бөтен даирәләр дә, тарая, кысыла бара. Бер үк вакытта әлеге даирәләрдән һәрберсе күңел ачу индустриясенең яңа платформаларына таянырга тырышып караячак. Күп кенә профессиональ язучылар инде ТВ һәм уен компанияләре өчен сценаристларга әйләнеп китте, һәм бу – әле үзгәрешнең башы гына. Шул ук вакытта юнәлешләрнең берсе дә ахыргача үлеп бетмәячәк, бары очсыз чүп-чар кәгазь басмалардан тулысынча диярлек электрон вариантларга гына күчте, ә маргинал булмаган сегментларда кәгазь китап, әлбәттә, калачак, бары тик бәясе (сыйфаты да яхшырыр дип ышанам) генә үсәр.

Электрон һәм аудиокитаплар тормышыбызга бик озакка килде, кесә телефоннары һәм планшетлар чоры тәмамланганчы, алар безнең белән булачак, моңысына шик юк. Сыек чиплар эпохасы һәм дулкыннар аша гына мәгълүмат тапшыру заманын күрәбез икән – ул чакта барысы да үзгәрер, әмма әлегә хәлләр менә шулай.

Моңардан тыш, кәгазь китап типография-нәшрият эшенең төп нигезе булып кала бирә. Нәшриятлар билгеле бер эчтә-

лек, мәгълүматка ия битләрнең тупланып-тегелеп басылып чыгуын да, ошбу эчтәлек белән мәгълүматның сатып алынырга һәм игътибарга лаеклыгын да үзенчә гарантияли. Традицион нәширләр өчен кәгазь китапны киностудияләр өчен телевидение һәм кинотеатрларның роле белән тиңләргә мөмкин. Хәтта соңгы кинотеатрның ябылуы һәм Җирдәге соңгы кешенең гадәти телевизор караудан баш тартуы да «башка кино булмаячак» һәм хәзер һәркем YouTube белән TikTok ишеләрдән роликлар һәм социаль челтәрләрдән мемнар гына караячак дигәнне аңлатмый. Бу бары тик киноның тулысынча интернетка күчүен генә белдерә, ул барыбер шул ук тулы метражлы яки күп серияле кино, әмма соңгы йөз елдагыча, һәрвакыт диярлек кыйммәтле һәм сәнгатьый яктан колачлы эшләнгән кино булып калачак.

Китаплар белән дә шуңа охшаш хәл: төрле бәйсез, идән асты нәширлек платформалары һәм пабликлары әллә нинди казанышлары белән ничек кенә мактанмасын, аларның сыйфат дигән нәрсәләре юк. Чын сыйфатны исә сайлап алу, әзерләү һәм китапны зур басмаханәләрдә җиренә җиткереп чыгару белән шөгыльләнә торган профессиональ нәширләр генә бирә. Һәм ул китапның нинди булуы – кәгазьме ул, электронмы, график яки аудио форматтамы – мөһим түгел.

Барысын да күрәсе килә.

...Бер бөтерелеп без дә яшәп алдык!
Героинялар көтте урамда.
Онытылып сөйдек, сөелдек бер!
Йә, тагын соң
ни бар дөньяда?..
Равил Фәйзуллин

УТЫР ӘЛЕ ЯННАРЫМА, ЯЛ БУЛЫР ҖАННАРЫМА...

Автор: Татьяна Вафина

Башта биредә обком дачалары булган. Бу аңлашыла да – урыны бик күркәм бит – урман, күл, саф һава, шәһәргә якын... Әмма узган гасырның 50 нче елларында язучы Гомәр Бәширов, Мәскәү янындагы Переделкинода каләмдәшләре янында булып кайтканнан соң, татар әдипләре өчен дә Казан янында шундый иҗат итү урыны булдыру идеясе белән яна башлый. Һәм менә 1953 елда «Аккош күле» иҗат йорты төзү турында карар кабул ителә. Өлкә комитеты моның өчен ике гектар җир бүлә, СССР Әдәби фонды биргән 400 мең сум акчага Финляндиядән үк дүрт йорт кайтартылып җыела. Аннары йортлар тагын да ишәя. Иң беренче булып Сибгат Хәким, Хәсән Туфан, Гомәр Бәширов, Габдрахман Әпсәләмов әлеге ведомство дачаларын башта бер сезонга арендалый, аннары тагын бер сезонга, аннан соң янә бер елга... Тиздән арендачылар «Татар Переделкиносы»нда тамыр җибәрә. Бистә тарихында аларның һәркайсы хакында риваятьләр саклана, алар буыннан буынга тапшырылып килә. Бүгенге буын биредә музей булдыру турында хыяллана – анда бистәдәге татар язучыларының һәркайсы хакындагы уникаль тарих үз урынын табар иде. Әлегә андый музей юк, шунлыктан безгә бу кызыклы хәлләрне Татарстан Республикасының халык шагыйре Равил Фәйзуллин сөйли. Ул аларның барысын да әле кичә генә булгандай яхшы хәтерли...

РАФАЭЛЬ МОСТАФИН БАШЫ ТУРЫНДА ТАРИХ...

Мин май аеннан башлап һәр иртәдә күлдә коенам. Бу минем өчен физзарядканы алыштыра. Минем йорттан ерак түгел генә исә танылган язучы, бик акыллы һәм зыялы шәхес, талантлы журналист Рафаэль Мостафин яши. 90 нчы елларда ул «Татарстан» журналының баш мөхәррире дә булган кеше... Ул эчмитартмый, сәламәтлеген кайгырта, һәр иртәне зарядка ясый.

...Менә бервакыт күлдә коенам, карасам – Рафаэль абый башында тора. Шәм кебек төптөз, селкенми дә. Озак тора... Мин дә спорт белән дус, тик мин алай булдыра алмыйм, ә ул рәхәтләнеп басып тора, әйтерсең лә, башта тору кешенең нормаль физик халәте ул. Якынрак килдем дә сорыйм: «Рафаэль абый, нигә башыңда торасың?» – дим.

«Нигә соң әле без җиргә гел аяк белән басарга тиеш? Баш та җирнең нәрсә икәнен тойсын әле бер!» – дип җавап бирде ул.

МОСТАЙ КӘРИМ АТЫ ТУРЫНДА ТАРИХ...

Мостай Кәрим – башкорт һәм татар язучысы, шагыйре, күпкырлы талантка ия шәхес! Ул Татарстан һәм Башкортостан арасын якынайтучы булгандыр. Казанга килгәч, беркайчан да безнең Аккош күленә кагылмый китми. Биредә дуслары күп булса да, гел Хәсән Туфанда туктала. Бервакыт иртән иртүк, сәгать алтыларда ук килеп җиткән. Туфан йоклый икән әле, ә ишеге ачык – теләгән һәркем керә ала! Ул чакта беркем дә ишек бикләми иде бит. Мостай шыпырт кына кергән дә утырып тора икән. Хәсән күзен ачса – кунак бар! Сикереп торган: «Болай иртүк нәрсә белән килеп җиттең?» – ди икән. «Мин, – дигән Мостай Кәрим, – атта килдем».

Хуҗа, атны эчертергә кирәк дип, шундук чиләккә су агызып җылытырга куя.

Чиләген күтәреп чыкса – анда тимер ат тора! Мостай Кәрим Горькийдан (хәзерге Түбән Новгород ул чакта шулай атала иде)

Шагыйрь Сибгат Хәким һәм язучы Рафаэль Мостафин. 1979 ел.

«Волга» машинасын алып кайтып бара икән, юлы Казан аша үткәнгә, дусты янына кереп, үзенең яңа «аты» белән мактанып чыгарга ниятләгән.

ӘХСӘН ФӘТХЕТДИНОВ ШЕШӘСЕ ТУРЫНДА ТАРИХ...

Кайвакыт мин үзебезнең Аккош күлендә санитар булып та эшлим. Урманда, күлдә кайбер ял итүчеләр калдырган чүп-чарны җыям. Шешәләр, консерв банкалары... Мин үзем әллә ничә тапкыр шуларга киселгәнем бар һәм, башкалар да җәрәхәтләнмәсен өчен, аларны җыеп алырга гадәтләндем.

Бервакыт минем яныма шагыйрь Мөдәррис Әгъләм белән рәссам Әхсән Фәтхетдинов кунакка килде. Бергәләп күл буена киттек. Мин, күл төбеннән төрле шешәләрне алып, ярга ыргытам, шагыйрь белән рәссам исә аларны капчыкка тутырып бара. Бер шешә башкаларына бер дә охшамаган иде. Ярдагылар да игътибар итте моңа. Әхсән әйтә, әтинең дә шундый шешәсе бар иде, ди. Ул аны кырыгынчы елларда сугыштан алып кайткан булган. Шешәне әйбәтләп юдык та, Әхсән алып китте. Анназы хатларында шешәнең һаман да киштәдә торуын, аңа бик кадерле булуын гел яза иде. Ул аңа балачагын, әтисен хәтерләтә, безнең дуслык хатирәсе дә булып тора.

Кайчак чүп җыйганда да кызыклы тарихка юлыгырга мөмкин шул.

РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН МӨГЕЗЕ ТУРЫНДА ТАРИХ...

Утыз еллап элек, Аккош күлебез әле урман уртасында утырганда, биредә хайваннар кешегә караганда күбрәк һәм якын килергә курыкмый иде. Тиеннәр янәшәдәге агачларда ук сикереп йөри, аю-бүре дә күренгәли, пошилар бакчага кереп агач кайрысы белән сыйланырга ярата... Бервакыт миңа кунакка килгән дустым аларны куркыту өчен чиләк ыргытты. Һәм чиләк берсенең мөгезенә эләгеп калды бит! Поши, куркып, шул килеш урманга качты һәм ай буе чиләкне шалтыратып йөрде. Үзе дә бәреп төшерә алмады, без дә булыша алмадык. Әмма пошилар язын мөгезен сала. Безнеке дә салган – бервакыт урманда йөргәндә, мин аны янәшәсендә яткан чиләгеннән таныдым. Мөгезне өй кыегына кадаклап куйдым. Ул һаман шунда тора әле.





Журналистлар язучыларда кунакта.

ИҢ ДӨРЕС АРАЛАШУ ЧАРАСЫ БУЛАРАК КИТАП

«Татарстан китап нәшрияты» ДУП генераль директоры Илдар Сәгъдәтшин нинди китапларга ихтыяҗның һәрвакыт зур булуы хакында фикер йөртә.

НИГӘ ВЕЛОСИПЕД УЙЛАП ТАБАРГА?

– Бүгенге укучы ихтыяҗына җавап бирү катлаулымы ул? Катлаулы булса да, мөмкин хәл. Моның өчен без берьюлы берничә ысул кулланабыз: укучыларыбызның ихтыяҗын өйрәнүдән башлап, дөнья, Россия һәм республика статистикасын җентекләп өйрәнүгә кадәр. Басмаларыбыз тиражының күбрәк өлешен республикабыз китапханәләренә җибәрүебез бәрәүгә дә сер түгел – бу безнең хөкүмәтнең социаль проекты, шуның нәтиҗәсендә татарстанлылар бөтен яңа китаплар белән бушка танышып бара ала. Сүз уңаеннан, әлеге тәҗрибә республикабызның берничә төбәгендә кулланыла. Шул исәптән бүгенге мобиль укучыларыбызның зәвыгына туры китереп бушлай аудиокитаплар тәкъдим итәбез. Татар әдәбиятын бөтен кеше укый алырлык итү, аны Россиядә һәм чит илләрдә таныту – һәрвакыт нәшрият өчен иң мөһим бурычларның берсе булды һәм шулай булып кала да.

БЕРСЕН УКЫЙЛАР, ИКЕНЧЕСЕН АЛАЛАР

Россиядә сатыла торган китапларның дүрттән өчесе – балалар китабы. Икенче урында – сыйфатлы проза. Өченче урында – тарихи һәм төбәкне өйрәнүгә багышланган китаплар. Бүгенге китап кәсәбәсе асылда менә шуларга таяна.

Укучылар ихтыяҗын өйрәнү өчен без ел саен Татарстан Республикасы милли китапханәсе белән берлектә «Ел китабы» конкурсын үткәрәбез. Безнең фирма кибетләреннән китап сатып алучылардан исә аларның нинди басмаларга өстенлек бирүен сораштырабыз. Менә шунысы кызыклы: китапханәдә бер төрле китапларга сорау зур булса, сатып алучылар бөтенләй башка басмаларны сайлый. Шуңа карамастан, тегеләрен дә, боларын да бер үк нәрсә – нәкъ менә китап укырга ярату берләштерә, бу исә безнең мәдәниятебезнең мөһим өлеше булып тора.

ЮЛЛАРЫ АЗ – ФИКЕРЕ КҮП

Иң популяр әдәби жанрлардан берсе – поэзиянең бүгенге хәле мине бераз хафаландыра. Безгә сәләтле шагыйрьләр үзләренең яңа шигырь кульязмаларын китерә, тик мин аларны бастырачакбыз дип өметләндерә алмыйм. Кызганычка каршы, бүген шигърияткә ихтыяҗ зур түгел. Гәрчә һәртөрле презентацияләр үткәргәндә кайчак укучыларыбызның шагыйрьләрнең чыгышларын ничек йотлыгып тыңлауларын күрсәк тә. Берничә юлга шулкадәр күп фикер сыйдыру, укучыларда көчле хисләр уяту өчен нинди осталыкка, нинди тел байлыгына ия булырга кирәк!

Хәер, бүген кешегә китап эзләп кибет яки китапханәгә барасы да юк – аны интернеттан да бик җиңел табып була. Тик аннан укулары да бик яхшы әле. Ә күпләр фильм карауны китап укудан артыграк күрә.

ЯҢА ПРОЕКТЛАРЫБЫЗДАН БЕРСЕ

Яшь шагыйрьләргә булышу йөзеннән без бик уңайлы кечкенә форматта биш авторның биш китабыннан торган шәлкем бастырдык. Нәшер ителгән китап, бигрәк тә яшь шагыйрь өчен – бала туу кебек сөенеч, өметләндерә-канатландыра торган куаныч ул. Әлеге проектны тагын дәвам итәргә карар кылдык. Бу җәһәттән нәшрият эшен футбол клубының селекция эше белән чагыштырып була...

УКУЧЫГА ТАБА ЭЛЕКТРОН АДЫМ

Тенденция шундый ки, бөтен дөньяда электрон китаплар уку кимесә дә, Россиядә моның киресе күзәтелә. Ихтыяҗ булуга карап эш итәргә – укучыга якынаю өчен, үзебезгә аңа каршы барырга туры килә. Әгәр укучыбыз Казаннан еракта яши икән, кайчак аңа китап китерү шактый кыйммәткә төшә. Шунлыктан үзебездә бастырылган әдәбиятны электрон формада сатып алу мөмкинлеген дә тудырабыз. Шул ук вакытта китап сатып алу өчен ерак араларны киртә санамаган укучыларыбыз да бар, мисалга, күптән түгел

Фото: Александр Ефремов

гена АКШка китаплар җибәрдек, укучыбыз нәкъ менә кәгазьгә басылган китапка өстенлек бирде.

АУДИОКИТАПЛАР ТЕЛНЕҢ НИЧЕК ҮЗГӘРҮЕН КҮРСӘТӘ

Бүген аудиокитап укучылар саны электрон китап сатып алучылардан күбрәк. Пандемия үзизоляция айларында барлык бүлекләрдәге китапларга, бигрәк тә интерактив дәреслекләргә ихтыяҗның өч тапкыр артуын күрсәтте.

Татарстанда аудиокитаплар яздыру проектына моннан бер 60 ел элек кенә булса да керешсәләр, мин бик бәхетле булыр идем. Беренче аудиокитап 1933 елда яздырылган, дип санала. Бу очракта без ул чактагы татар теленең ничек яңгырашын белер идек. Габдулла Тукай, Һади Такташ, Муса Җәлилне һәм ул заманнардагы башка авторларны укыганда, телнең вакыт үтү белән барыбер үзгәрүенә төшенәсең. Ул хәзер дә үзгәрүен дәвам итә. Бу бик кызыклы процесс.

КЛАССИКА ҺӘРВАКЫТ ТРЕНДТА

Безнең нәшрияткә 100 елдан артык. Һәм шул 100 ел дәвамында без бастырган язучы һәм шагыйрьләрнең рейтингы төзелеп бара. Һичшиксез, һәрвакыт иң алда – Габдулла Тукай. Гәрчә 30 яшенә дә җитмичә бакыйлыкка күчсә дә, ул татар әдәбиятына гаять зур мирас калдырган.

Әйтик, соңгы алты ел эчендә Муса Җәлилнең легендар «Моабит дәфтәрләрен» без дүрт тапкыр бастырдык.

ПАРАДОКС

Бүген, китапның киләчәге юк, ул Z буынында юкка чыгачак, дигән инану бар. Тик нигә менә Ирандагы китап күргәзмәсенең беренче көнендә генә дә аны ике миллионга якын кеше караган да, Германиядәге күргәзмәләр 6500әр катнашучы туплый соң? Әлбәттә, Россия әлегә мондый зур саннар белән мактана алмый, кызганычка, безне хәзер иң күп китап укучы ил дип тә атап булмый. Әмма бөтен дөньяда нәкъ менә китапның иң дөрес аралашу чарасы булуын аңлаучылар һаман арта бара. Миндә дә бу зур өмет уята.

СЫҢАР КУЛ БЕЛӘН АЛКЫШЛАП БУЛМЫЙ

Әгәр чыннан да мавыктыргыч икән, китап укырга бик яратам. Хәзер Евгений Березиковның «Великий Тимур» роман-хроникасын укыйм – урта гасырларда дөньяның астын-өскә әйләндергән Аксак Тимер, җиңүче кеше турында ул. Бүген өстәлемдә Галишир (Алишер) Нәваи шигырьләре җыентыгы да ята. Сүз уңаенда, менә шуннан бер цитата. Минемчә, нәкъ безнең темага: «Сыңар кул белән алкышлап булмый».

КЕШЕЛЕК КЛИПЛЫ ФИКЕРЛӘҮДӘН КОТЫЛАЧАК

Биофизик, физика-математика фәннәре докторы Константин Усачев китап укуның акылга ия булган кешене гакыллы кешегә әйләндерүе турында фикер йөртә.

КИТАПЛАР – ДӨНЬЯГА КАРАШ КИҢЛЕГЕ ҺӘМ АНЫК ТӘҖРИБӘ УЛ

– Син галим икән, әлегә җавабы юк мәсьәләләрне чишәргә туры килә. Һәр тапкырында син нинди дә булса идеягә таянырга, төрле вариантларны күрә, алымнарны үзгәртә, киң күзаллый белергә тиеш... Әлбәттә, бу шартлар фән өчен генә түгел, әйтик, бизнес өчен дә хас. Эшкуар бер бизнес-модельне кулланып карый, ди, ә анысы эшләми. Ул кулын селтәргә, шул рәвешле бөлгенлеккә төшәргә мөмкин, ләкин икенчесен уйлап таба. Нәрсә дә булса булдырыр, тормышка ашырыр өчен, дөньяга караш киң булырга тиеш. Безгә төрле ситуацияләрне, проблемаларны, аларны хәл итү юлларын ачык күрсәтеп, китаплар әнә шул киң карашны тәэмин итә. Ә билгеле бер каршылыкка очраганда, теләсә нинди тәҗрибә дә эшкә ярап куя. Хәтта ул тәҗрибә тормыштан түгел, ә китаптан алынса да.

КИТАП СӨЮЧЕЛӘР ВАК-ТӨЯККӘ ИГЪТИБАР ИТМИ

Замана студентларының клиплы фикерләве – укытучылар өчен яңа чынбарлык ул. Егетләр һәм кызлар игътибарны туплый алмый интегә, сәгать ярым дәвамында дәрестә утыру яки бертөрле эш башкару аларга бик кыен бирелә. Кызганыч, технологияләр үсеше яшьләрнең китапларны азрак укый башлавына китерде. Элек бездә җиңел рухтагы мәгълүмат алу өчен юллар ябык иде, ә бүген исә андый мәгълүмат – муеннан! Очсыз-кырыйсыз кыска хәбәрләр тасмасы, социаль челтәрләрдәге постлар һәм роликлар игътибар туплау күнекмәсен югалта баруыбызга булыша. Халык бүген озын текстлар укырга яратмый. Әйе, без смартфон экраны белән чикләнгән кечкенә генә мәгълүмат кисәкчеген «йотып» җибәрә алабыз, ә тагын биш-алты битне карап чыгу инде бик авыр эш булып тоела. Менә ни өчен бала вакытта гына түгел, гомер буе уку мөһим. Нинди дер фантастик фикер тоелса да, шунысы хак: берәр озын роман укый-укый ял итәргә яраткан китап сөючеләрнең өстенлеге киң эрудиция һәм грамоталылыкта гына түгел, ә бәлки, вак-төякләргә бүленмичә, анык мәсьәләгә озак игътибар бирә белүдә дә. Бу сыйфатның эштә бик ярдәме тиюен әйтеп торырга да кирәкмидер.

КЛАССИКА ҺӘР ЗАМАНГА ТУРЫ КИЛӘ!

Мәктәп программасыннан катлаулы классиканы алып ташларга кирәк, дигән фикер бар. Юк, мин моның белән килешмим. Әлбәттә, хәтта «Денискины рассказы» кебек китапта да бүгенге балаларга аңлаешсыз нәрсәләр, әйтик, «тәрәзә өчен замазка» күренеп китә ала. Ә «өлкәннәр» китабы турында инде әйтеп тә торасы юк! Инде әллә кайчан кулланыштан чыккан сүзләр андыйларда бик еш очрый. Ләкин бу сүзләр, алар белдергән предметлар безнең балачак өчен ят түгел бит! Һәм бу сүзләр, атамалар күзаллау сәләтебезне киңәйтә генә. Әгәр бала баш миен мәктәптә эшләтергә тырышмый икән, нигә әле ул аны соңыннан эшкә җигәчәк, ди? Баланы сабый чактан ук актив үстерү яклы японнарны карагыз әле, аларда уку-укыту еш кына дүрт яшьтән башлана. Балага старт биреп җибәрәләр, ә алга таба ул үсешен инерция буенча гомер буе дәвам итә. Миңа мондый караш ошый. Бер искәрмә белән: процесс башыннан ук кызык булырга тиеш.

КЕШЕ КИТАП БЕЛӘН ДУСМЫТҮГЕЛМЕ – БУ ШУНДУК КҮРЕНӘ

Китап укырга яратучы кеше белән озакка сузылган интеллектуаль әңгәмәләр алып бару һәрвакыт күңелле, әле аның белән озак вакытлы һөнәри мөнәсәбәтләр урнаштыру да җиңел. Моның сәбәпләре күп. Беренчедән, китап уку фикерләүнең креативлыгына турыдан-туры йогынты ясый. Чөнки безгә китапларның сюжетларын үз аңыбызда визуальләштерергә, геройларны күзалларга туры килә, һәм еш кына безнең һәркайсыбыз яраткан китапларыбыз нигезендә фильмнар төшерүче режиссерларга караганда моны күпкә уңышлырак башкарып чыга. Шул рәвешле фантазия үсә. Өстәвенә, китаплар хәтерне яхшырта. Зур романнар укыганда, телибезме-юкмы, безгә шактый күләмдәге мәгълүматны истә тотарга туры килә. Китапта сурәтләнгән хәлләрне тулаем күзаллау өчен, безгә бу мәгълүматны берләштереп җыярга, анализларга кирәк. Шул рәвешле баш миенең төп күнекмәләреннән берсе – фикерләү сәләтебез формалаша.

МИН ПЕССИМИСТИК ФАРАЗЛАРГА БИРЕЛМӘҮ ЯКЛЫ!

Илле елдан соң кешенең баш мие һәм фикерләү рәвеше заманча тенденцияләр йогынтысында ничек үзгәрәчәк? Дөресен генә әйткәндә, пессимистик фаразларга бирелмим! Миңа калса, нинди генә очракта да кешелек җаен табачак. Бәлки, фикерләү рәвешебез тамырдан үзгәрер, ләкин нигәдер мин шуңа инанган: китап уку безнең өчен никадәр мөһим булса, бездән соң киләчәк буыннар өчен дә шулкадәр үк әһәмиятле булып калачак. Өстәвенә, әдәбият үзе дә бер урында гына тормый – ул вакуумда үсми бит! Җәмгыять үзгәрә – авторлар да алышына. Ә классика? Аны илле ел элек тә укыйлар иде, ярты гасырдан соң да укыячаклар.

РАРИТЕТЛАР КИТАПХАНӘСЕ

Бер адым атлыйм да әкияткә эләгәм. Каршымда Хогвартс китапханәсе ачыла – шуннан бер дә ким түгел! Бөгелеп килгән гөмбәзле түшәмнәр, берсеннән-берсе иске китаплар тезелгән борынгы биек киштәләр... Биредә, Лобачевский исемендәге фәнни китапханәнең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә, Бөек Тарих галиҗәнапләре яши.

Автор: Ольга Туманская

XIX ГАСЫР ФАНТАСТИКАСЫ

Без әллә нинди озын-озын, бормалы-сырмалы коридорлар аша узабыз, бер бүлемнән икенчесенә күчәбез...

– Илебездә иң зур китапханәләрнең берсе бу, – ди кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире Эльмира Исхак кызы Әмирханова, фикерләремне укыгандай. – Күз алдыгызга китерегез әле, бу бинада гына да 2 миллионга якын китап саклана. Ә гомумән безнең китапханәдә – алты миллион том!

Сүз уңаеннан, бина турында. Бу искиткеч корылма – Россиядә шушы максатны махсус күздә тотып төзелгән иң беренче китапханә биналарының берсе. Әлеге проектны бөек галим Николай Лобачевский әзерли һәм 1838 елда тормышка да ашыра. Тик 1902 елда төп уку залы үзгәртеп корыла. Эльмира ханым, бераз хыял диңгезенә чумып, күз алдына китереп карарга тәкъдим итә: әйтик, без басып торган катларны аерып торган идән-түшәмнәр юк, ди. Бу очракта түшәмнәр искиткеч биек булачак, ә аста чын мәгърифәт учагы кайный: һәр тараф мәрмәр һәм яшма белән бизәлгән, колонналар арасына күренекле фикер ияләренең бюстлары куелган, диварларга төрле фәннәрнең эмблемалары төшерелгән. Әмма иң мөһиме – 24 нечкә колоннага таянган галәмәт зур гөмбәз. Болай итеп төзү – шактый катлаулы эш, аның үз сере бар: гөмбәзнең өске өлеше җиңеләйтелгән конструкциядән гыйбарәт һәм эче куыш керамик каплардан тора.

Үз идеясенең тормышка яраклы икәненә һәм бинаның җимерелми торачагына архитектура комиссиясен ышандырыр өчен, Лобачевскийга ике ел кирәк була. Һәм менә нәтиҗәсе – иркен һавалы һәм бик якты бина. Соңгы үзенчәлек аеруча мөһим, чөнки «Ильич лампочкасы» кабынганчы әле бер гасырга якын вакыт бар, ә китапханәдә янгын чыгару куркынычы булган шәмнәр кабызырга ярамый. Шул ук сәбәп белән әлеге бина өчен уникаль җылыту һәм вентиляция системасы булдырыла.

Фото: Александр Ефремов

1890 нчы елларда китапханәнең янкормасы барлыкка килә. «Казанда утта янмый торган тәүге бина», – дип язган ул чакта китапханә турында журналистлар. Калын диварлар, калориферлы җылыту системасы, дымлылыкны көйләү сәләтенә ия известьташ идән бәрабәренә биредә бүген дә үзенчәлекле микроклимат саклана, бу исә мондагы кыйммәтле кулъязмалар һәм борынгы китаплар өчен гаять мөһим.

НӘШИРЛЕК ЭШЕ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

– Бу китап 1667 елгы, – ди Эльмира Әмирханова, киштәдән борынгы бер басманы алып.

Тик мин дата урынына латин хәрефләреннән һәм Рим саннарыннан гыйбарәт ниндидер шифр гына күрәм. Хәер, барысы да дөрес, алдымдагы кодта М хәрефе мең санын белдерә, D – меңнең яртысын, С хәрефе йөз дигән сүз, ә L – илле. Барысын бергә кушабыз да, Рим саннары белән язылган 17 не өстибез, һәм басманың төгәл датасы килеп тә чыга!

– Бу китапның тышлыгы кәгазьдән, – дип дәвам итә китапханә өлкәсендә агарту эшен Эльмира Әмирханова. – Ул вакытта кыйммәтле тышлыклы китаплар чыгару өчен нәшриятларның мөмкинлеге җитмәгән. Еш кына бу максатта элек чыгарылган басмалардан калган кәгазьне кулланган. Шәхси китапханәләре стиленә туры китерү өчен, китапларга кыйбатлы тышлыкларны аларның хуҗалары заказ буенча эшләткән.

Сүз уңаеннан, кулымдагы китапта латинча дини текстлар язылган, Казанга ул Санкт-Петербург Император халык китапханәсеннән килгән. Хәер, биредәге һәр китапның язмышы үзенчәлекле.

– Мондагы фонд XVIII гасыр азагыннан бирле туплана килә. Әйе, шулай килеп чыккан ки, университет китапханәсе уку йортының үзенә караганда иртәрәк барлыкка килгән, – дип сөйли Эльмира ханым.

Фонд ике китап тупланмасы нигезендә җыела башлый. Аның берсе – кенәз Григорий Потемкинның 1799 елда Казанга унсигез арбада китерелгән китапханәсе, икенчесе – Россия Сәнгать академиясе секретаре Василий Полянский тупланмасы. Өстәвенә, Лобачевский үзе дә китап белән тәэмин итүнең өзлексез системасын булдыра. Университетның барлык профессорлары ел саен дөнья күргән әсәрләрнең исемлеген төзергә кушыла. Мөһим яңа китапларның барысы да мәҗбүри рәвештә сатып алына. Күп кенә басмалар бүләк сыйфатында килә, уникаль коллекцияләрне «аулау» да дәвам итә.

Нәтиҗә: бүген Лобачевский исемендәге китапханәнең биниһая зур фондында рус телендә, Көнбатыш Европа һәм Шәрык телләрендә фән һәм сәнгатьнең барлык тармакларына караган 150 мең ядкәр исәпләнә. Биредә саклангaн кулъязмаларны, китапларны санап бетерерлек түгел. Алар арасында Россиядә иң зур – 13 мең бер әмлектән артык! – гарәп кулъязмалары коллекциясе, Россия императорларының Казан губернаторларына исемле указлары, Себер воеводаларына патша грамоталары, хронографлар, тарихи җыентыклар, исәп кенәгәләре, шәҗәрәләр, әдәби җыентыклар, күренекле галимнәрнең кулъязмалары бар...

ИҢ БОРЫНГЫСЫ

XI гасыр азагына караган китаптагы VII гасырда язылган гарәпчә сүзлек – китапханәнең иң борынгы ядкәре. Әлбәттә, мондый реликвия билгеле бер яктылык һәм температура режимы шартлары саклануны таләп итә. Бу ядкәр китапханәгә килүчеләргә күрсәтелми, алай гына да түгел – аңа бөтенләй кагылмаска тырышалар.



Эльмира Әмирханова безнең өчен исә башка китапны тартып чыгара. XIV гасырга караган «Гаҗәибәл-Мәхлүкат» рисаләсе үзенең матурлыгы һәм төсләренең җетелеге белән таң калдыра. Борынгы кульязманың авторы әл-Казвини XIII гасырда яшәгән һәм Багдад хәлифәтенең зур түрәсе булган. Чыңгыз хан явы аның язмышын үзгәртә. Казвининең туган шәһәре яндырыла һәм, бөтен яраткан нәрсәсен югалткач, калган гомерен ул галәм, дөньяның төзелеше турында шул чорда билгеле булган белемнәрне саклауга багышлый. Аның кульязма китабы әнә шул хакта була да инде, аны әкият сюжетлары һәм риваятьләр белән тулыландырылган космография дип атарга мөмкин. Без караган рисаләне соңрак кемдер рәсемнәр белән бизи. Менә бу тарафта атлар-кәҗәләр арасында кешеләр ясалган, ә икенче якта – әкияти кошны койрыгыннан эләктергән нинди дер риваять герое... Фотоаппаратының утын кабызмыйча гына, фотографыбыз яртылаш кына ачылган битләрне берничә тапкыр сурәткә төшереп ала. Китапны киң итеп ачып тотарга ярамый.

Сүз уңаеннан, ата-бабаларыбыз китап тышлыгын ясауга аеруча игътибар күрсәткән. Мәсәлән, мөселман дөньясы өчен тартма рәвешендә тиредән ясалган тышлыклар хас, белгәнебезчә, тире кәгазьгә караганда күпкә начаррак яна. Эльмира Әмирханова безгә алтынланган күн белән тышланган клапанлы гарәпчә-французча сүзлек күрсәтә. Аның клапаны әле кыстыргыч вазыйфасын да башкарган.

ТИҢЕ БУЛМАГАНЫ

Эльмира Әмирханова алдыбызда Коръән ачып җибәрә.

– Соң бу бит яңа китап! – дип аптырап калам.

– Китапханәбездәге иң уникаль китапларның берсе – дөньяда Коръәннең беренче мөселман басмасыннан эшләнгән репринт бу. Каршыгыздагы бүләк басма 2004 елда, Кол Шәриф мәчете ачылуга һәм Казанның 1000 еллыгын бәйрәм итүгә багышлап чыгарылган иде. Кадерле ядкәр үзе исә махсус шартларда саклана.

Бу китапның тарихын 1787 елдан башларга мөмкин. Ул вакытта Петербург типографиясендә Коръән дөнья күрә. Беренче басма Коръән дип атала алыр да иде ул. Аңарчы мөселманнарның изге китабы мөселман булмаган илләрдә, төп текстка шәрехләр белән генә бастырыла. Төньяк башкалада да ул шундыйрак шәкелдә нәшер ителә. Изге текстны халыкка җиткерү рәвеше бозылган була – нәтиҗәдә, мөселманнар бу тиражны дини максатларда файдаланмый. 1803 елда Коръәнне басма рәвештә чыгаруда тагын бер омтылыш ясала, монысы – Казанда. Изге Китапның икенче тапкыр басылып чыгуына карамастан, Казан басмасы чынлыкта дөньяда Коръәннең беренче басмасы була. Моннан ул Каһирәгә, Истанбулга җибәрелә һәм аннан соң бар дөнья буйлап тарала. «Коръән Мәккәдә язып алынган, Каһирәдә укылган, Казанда басылган», – дигән гыйбарә әнә шулай барлыкка килә.

АЯНЫЧ ЯЗМЫШЛЫСЫ

Ә биредәге китаплар арасында кешелек тарихын гына түгел, ә кемнеңдер шәхси язмышын да күрсәткәннәре күпме әле?!

Менә, мәсәлән, борынгы октоих – өч уч кадәр калынлыктагы җыентыкка көн саен укыла торган догалар тупланган! Гадәти тышлык урынына – тире белән тарттырылган агач капкачлар. Каптырма да – конструкциянең мөһим элементы. Капкачларны бер-берсенә яхшы итеп тарттырып, ул китап битләре арасына һава керүгә юл куймый. Ә кислород булмаганда яну туктала.

Әлеге кульязма XVII гасыр уртасына карый. Аның күләме безне шаккатырды инде. Китап битләрендәге буш читләр дә галәмәт зур!

– Аларны ярлар дип атау бер дә юкка түгел, – дип аңлата гидыбыз. – Бу китап утка эләксә дә,

кәгазь кырыендагы буш урын гына ябачак, ә кульъязма текст ябмаячак. Барысы да уйлап эшләнгән!

Аерым урыннарда текст ас-өс тамгалар белән тулыландырылган. Тик менә монда текст өзелгән, китапны язып бетермәгәннәр...

– XVII гасыр урталарында чиркәү реформасы башлана, – дип аңлатып уза Эльмира Әмирханова. – Шуңа күрә писарь, яңалыкларны кабул итеп, бәлки, бу китап эшен туктаткандыр, йә инде, аларны кире какканга күрә, эзәрлекләүгә дучар ителгәндер.

ИҢ ГАҖӘБЕ

Каршымда яткан басманы һава белән тышланган дияргә дә була. Тар һәм озын агач такта кисәкләре арасында берни белән дә беркетелмәгән, тегелмәгән кәгазь битләре ята.

– Бу – Ерак Көнчыгыш китабының бер үрнәге, – дип сөйли Эльмира Әмирханова. – Үз формасы белән Көньяк-Көнчыгыш Азиядә китаплар барлыкка гына килгән чорда кулланылган китап материалы формасын кабатлый. Гадәттә пальма яфрагын яки агач кайрысыннан файдаланганнар. Эшкәртелгән материалның файдалы өслеген мөмкин кадәр күбрәк куллану өчен, китапларны менә шундый озын итеп ясый башлаганнар.

Бу китап – ламаист буддачыларның «Бөек котылу сутрасы» дигән трактаты – XIX гасыр башында Россия империясендә Байкал арьягы төбәге өчен нәшер ителә. Сутра басма графика ысулы белән чыгарылган, әлеге алымны кулланганда, әүвәл агачтан гравюраның көзгедәге кебек чагылышын уеп-кисеп алалар, шуңа кара буяп, күчермәсен ясыйлар.

– Бик авыр, күп көч таләп иткән ысул түгелме соң ул? – дип сорыйм.

– Киресенчә. Китап басылган телдә иероглифларның галәмәт күплеген исәпкә алсак, әлеге метод кулайрак. Бихисап хәрефтән торган касса тотканчы, китапның бер битен агачтан кисеп чыгу җиңелрәк.

Сүз уңаеннан, Казан университеты иң әүвәл илнең көнчыгыш өлешендәге халыкларны агарту максатыннан ачыла, димәк, беренче чиратта, биредә Көнчыгышны өйрәнү юнәлеше үсә башлый. Күпчелеге Германиядән чакырылган профессорлар европалашкан шәһәрдә яшәргә һәм укытырга бик теләп риза булган, өстәвенә Казан Шәрык дөньясына турыдан-туры кереп өйрәнү өчен бик шәп мөмкинлекләр ачкан. Азия буйлап махсус экспедицияләргә чыгып, галимнәр аннан китаплар төяп кайткан. Шул рәвешле университет китапханәсендә төрле телләрдәге һәм кызыклы формада эшләнгән басмалар һәм кульъязмалар барлыкка килә башлаган.

ИҢ КЫЙММӘТЛЕСЕ

«Калугадан. Казан университетына – автордан. 1895 ел». Һәм имза – «Циолковский».

Мин бу язуны күргәч, катып калдым. Каршымдагы юка гына соры китап бөтен Галәмне колачлый лабаса! Бөек галим һәм фикер иясе



аны университетка үзе бүләк иткән, чөнки Казанда күк һәм космос белән җитди кызыксынганнар. «Гади тәҗрибәләргә һәм фикерләргә нигезләнеп, канатлар ярдәмендә очу» дигән ошбу ядкәрнең соңгы бите кулдан язылган. Автор үзе ясаган очкычның каләм белән сурәтен төшергән, бөгәрләнмәсен өчен, рәсемне бик пөхтәләп бөкләп куйган. Нинди кыйммәтле китап!

Яки менә, мәсәлән, ниндидер Аловның «Ганц Кюхельгартен» поэмасы кергән бер басма. Университет китапханәсенә ул Казан университеты ректоры, профессор, рус әдәбияты тарихы белгече Николай Булич коллекциясе составында эләгә. Бик сирәк ядкәр – дөньяда сакланып калган ун нөсхәнең берсе. Бу – Николай Гогольнең беренче басылып чыккан әсәре. Алов аның тәхәллүсе. Тәнкыйть утына тотылгач, яшь язучы бөтен тиражны диярлек сатып ала һәм юкка чыгара.

– Бездә «иң кыйммәтлесе» дигән төшенчә юк, әлбәттә, – ди Эльмира Әмирханова. – Барысы да нинди шартларга таянып фикер йөртүгә бәйле – китапның хронологик борынгылыгыны, сан ягыннан сирәклегеме, билгеле бер социаль төркемнәр өчен зур әһәмияткә ия булуымы...

Лобачевский исемендәге китапханәдә беренчесе дә, икенчесе дә, өченчесе дә күп. Әйтик, Көнбатыш Европа һәм славян телләрендәге тәүге борынгы басма китаплар: 1470–1499 елларга караган 17 инкунабула, Франциск Скоринаның 1518 елгы «Патшалыклар кенәгәләре», Иван Федоровның 1564 елгы дип билгеләнгән «Апостол» китабы. Яки Потемкин коллекциясеннән уникаль альбом, аңа «Түгәрәктәге сәгать» – XVII гасырда Мәскәү китап басу йортының гравюрлап төшерелгән беренче басма бите кертелгән – бу исә графика буенча белгечләр өчен искиткеч раритет! Яки менә тагын бер ядкәр – татар мәгърифәтчесе Шиһабетдин Мәрҗани тарафыннан гарәпчә төзелгән җиде томлык Шәрык язучылары сүзлеге...

Ә сез болардан кайсын күрергә теләр идегез? Сирәк очрый торган әдәби ядкәрләрне бүген үк карарга мөмкинлек бар. Тик электрон рәвештә генә! Борынгы кульъязмаларның һәм китапларның күбесе инде цифрлы форматка күчерелгән. Алар «Казан университеты. Тарихи-мәдәни ландшафт» сайтында тәкъдим ителә.

«ТАТМЕДИА» БАСМАЛАРЫН УКЫРГА ЯРАТУЧЫЛАР КЛУБЫ

Башкаладагы китап кибетләрендә газета-журналлар сатып алырга мөмкин. Тиздән республиканың башка шәһәр-районында яшәүчеләр өчен дә шундый уңайлылык тудырылачак. «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте әнә шундый яңа тәҗрибә кертергә җыена. Дөрес, әлегә бу эш берничә шәһәр һәм район үзәгендә генә оештырылачак. Әгәр инде халыкта кызыксыну уянса, авыл китап кибетендә вакытлы матбугат сатып алу да гадәти хәлгә әйләнәчәк.

Фото: Рамил Гали

БЕЗГӘ УҢЫШ ЮЛДАШ БУЛСЫН!

Алсу РӘХМӘТУЛЛИНА, Яр Чаллы шәһәре, «Рәхмәт» татар китабы кибете җитәкчесе:

– Китап сату өлкәсендә безнең тәҗрибә зур – егерме елдан артык эшлибез. Бүген сатуда 4 мең төрле китап бар. Исеменнән үк күренгәнчә, нигездә татар китаплары сатабыз. Шулай ук үзебез дә татар классик язучыларының китап һәм җыентыкларын яңартып нәшер итәбез. Берничә ел элек Чаллыда чыга торган «Мәйдан» журналын, «Көмеш кыңгырау» газетасын да сатып караган идек. Тик ни кызганыч, ихтыяҗ булмады. Менә тагын бер тапкыр вакытлы матбугатны сатуга алынып карыйбыз. «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте белән уртак проект бу. Хәерле сәгатьтә булсын!

ЭШЛӘП КАРЫЙК!

Рамилә Дәүләтова, Мөслим авылы, китап кибете хуҗасы:

– Районда китап кибете ябылгач, чын-чынлап борчылдым. Минемчә, бу зур ялгышлык булды. Күп еллар дәреслекләр буенча методист булып эшләдем. Китап – минем өчен җанга рәхәтлек бирә торган мөһим әйбер. Менә шуңа да китаплар белән сәүдә итә башладым. Башта заказ буенча эшләдем, аннан соң инде кибет ачтым. Һәр яңа чыккан татар китабын бер-ике данә булса да алып кайта идем. Ихтыяҗ туса, тагын алып кайттым. Хәзер дә шулай эшлим. Төрле юк-барны сатмас өчен, яңа китапны башта үзем укып чыгам, аннан соң гына кешегә тәкъдим итәм.

Газета-журналлар сатуга килгәндә, әлегә кадәр андый тәҗрибәм юк. Кибеткә бер килгәч, халык вакытлы матбугатны да алыр, дип уйлыйм, чөнки даими сатып алучыларыбыз байтак. Ничек кенә дисәк тә, китапка ихтыяҗ бар. Ә вакытлы матбугатка мөнәсәбәтне вакыт күрсәтер, эшләп карыйк!

БАЛТАЧ ХАЛКЫ УКЫРГА ЯРАТА!

Дамирә Гыйльмуллина, Балтач бистәсе, китап кибете хуҗасы:

– Дөресен генә әйткәндә, китап сату белән шөгыльләнермен димәгән идем. Очраклы килеп чыкты. Күп еллар нотариус булып эшләдем. Ритуаль хезмәтләр күрсәтү бюросына вакытлыча эшкә чакырганнар иде. Шунда догалыклар алып кайта башладым. Пандемия вакытында бюро хуҗалары тәкъдим иткәч, дога китаплары сату эшен үз кулыма алдым. Менә шуннан кереп киттем инде. Догалык кына түгел, халык гади китаплар да сорый башлады. Бүген инде сатуда шактый татар китабы бар. Халык популяр авторларның яңа китаплары чыкканны көтеп кенә тора. Ихтыяҗ бар.

«ТАТМЕДИА» вакытлы матбугатны да сатуга куеп карарга тәкъдим иткәч, шундук ризалаштым. Балтач халкы укырга ярата, гомер-гомергә күп газета-журнал алдырды. Сатып алучылар табылыр, дип өметләнәм!

ИҢ ЮГАРЫ ДӘРӘҖӘДӘГЕ ЯЛ

Идел буенда балык тоту, матур урманда йөрү, саф һава һәм заманча архитектурадагы уңайлы корпуслар. Биредә медицина өлкәсендәге инновацияләр югары дәрәҗәдәге сервис белән үрелеп бара. Без «Газовик» шифаханә-профилакториенда!

16 гектар мәйдан биләгән гаҗәеп матур ландшафтта күңелегез теләгән һәрнәрсәне таба аласыз. Кызыклы урман маршрутлары һәм яр буенда таң каршылау, ачык спорт зоналары һәм релакс мәйданчыклары... Мәдәни-спорт комплексында 25 метрлы шәп бассейн һәм берничә спорт залы урнашкан. Ә инде бу да аз икән, ял итүчеләр өчен һәрвакыт Казан, Зөя һәм Раифага экскурсияләр оештырыла.

САВЫК, ДӘВАЛАН

Медицина технологияләренең соңгы казанышлары – менә нәрсә белән дан тота «Газовик»! Сүз иллегә якын инновацияле аппарат турында гына түгел, ә мондагы дәвалау-савыктыру ысуллары турында да бара. Бу исә югары класслы белгечләргә һәр пациент өчен шәхсән дәвалау ысулын сайларга мөмкинлек бирә.

Массаж төрләре генә дә дистәгә якын! Кул белән ясала торган классик массаждан тыш, умыртка баганасын әкренләп тарттыру һәм җылыту функцияләренә ия Нуга Бест заманча аппарат массажы өчен җиһазлар бик күп. Шуңа өстәп, аяк өчен бөтеркәле ванналар, Шарко душы, «акыллы» «Каракалла» ваннасы ясый торган су асты массажы...

Зур ванна залында коры углекислый газлы, минераль һәм минераль-энҗеле, шулай ук контрастлы ванналар кабул итәргә мөмкин. Хәер, һәр кабинетның мөмкинлекләре шаккатыра – төрле токлар белән дәвалау да, күпфункцияле магнит дәвасы да, лазер җайланмалары да, умыртка баганасын сузу аппараты да, лимфодренаж костюмы да бар биредә...

Шифаханә ашказаны-эчәк тракты авыруларын дәвалауда уңышлы куллана торган эчәргә яраклы минераль су белән аеруча горурлана. Биредә аларның үзләренең тозлы эремәсе дә бар, андагы шифалы тозларның куелык дәрәҗәсе Соль-Илецк күлләрендәге су белән тиңләшерлек. Әлеге тозлы эремә ваннага туп-туры җир асты скважинасыннан килә.

ЯЛ ИТ

Шифаханә җитәкчесе Рәис Хәсәнов, «Газовик»та тәкъдим ителә торган кайбер процедураларның илдә тиңдәше юк, дип сөйли. Мәсәлән, чып-чын гәрәбә бүлмәсендәге саф һава ванналары!.. Аның диварлары табигый гәрәбә кисәкләре белән капланган. Бу таш тирегә, калкансыман бизгә яхшы тәэсир итә, иммунитетны ныгыта. Гомумән, бу бүлмәгә кереп чыгу сәламәтлекне генә яхшыртып калмый, кәефне дә күтәрә. Сүз уңаеннан, «Газовик» шифаханәсендә савыктыргыч релакс өчен урыннар күп. Биредә ароматерапия залы да, спелеоклиматик камера да, кышкы бакча да, фитобар да бар...

РӘХӘТЕН КҮР

«Газовик»та ирешелгәннәрдә туктап калырга күнекмәгәннәр. Шифаханә «Газпром трансгаз Казан» предприятиесе системасына керә, аның җитәкчелегенең карашлары исә «Газовик» стратегиясе белән туры килә. Якындагы планнарда – балалар өчен бассейн төзү һәм алар өчен программалар булдыру. Мәктәп укучылары һәм мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен ял тәҗрибәле табиблар күзәтүе һәм сәламәтләндерү процедураларын гына түгел, ә танып-белүгә, белемнәрне арттыруга булышлык итә торган уеннар, туристлык квестлары, флешмоблар һәм дискотекаларны да үз эченә алачак.

Шулай ук биредә колачлы төзелеш – яңа корпус төзү планлаштырыла. Тагын әле минераль су һәм теге шифалы эремә белән яңа бассейннар да булачак! Тегесе дә, монысы да санаторийның башка тиңе юк тәкъдимнәре исемлегенә керәчәк. Боларның барысы бергә инде бүген үк «хыялдагы шифаханә» дип йөртелгән «Газовик»та ялны тагын да уңайлырак, ә дәвалауны тагын да нәтиҗәлерәк итәчәк.

«Газпром трансгаз Казан» ЖЧҖ
«Газовик» шифаханә-профилакторие
Татарстан, Югары Ослан районы,
Пустые Моркваши бистәсе
+7 (843) 524-55-15, 524-55-19
sp-gazovik@tattg.gazprom.ru

Фото «Газовик» шифаханә-профилакторие матбугат хезмәтеннән алынды. Реклама.

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

АЛДЫНГЫЛАР ӨЧЕН ТАШЛАМАЛЫ ЛИЗИНГ

Шәхси хуҗалыклар, фермер хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы кооперативлары һәм хуҗалык итүнең башка кече формасындагы оешмалар Татарстан авыл хуҗалыгы продукциясенең яртысын җитештерә. Дәүләт мондый предприятиеләргә үз тармакларында алдынгылар рәтендә калырга ярдәм итә.

«Татагролизинг» АҖ республиканың авыл хуҗалыгы техникасы белән тәэмин итүче иң эре оешмаларыннан санала һәм дәүләт лизинг компанияләре белән хезмәттәшлек итә. Акционерлык җәмгыяте бу тармактагы «Гомсельмаш», «Брянсксельмаш», «Алмаз» кебек зур-зур заводларының дилеры булып тора. Шуның бәрабәренә «Татагролизинг» АҖ үз клиентларына оптималь шартлар тәкъдим итә һәм техниканы ташламалы ставка белән лизингка бирә.

«Безнең максат – авыл хуҗалыгы техникасының нәтиҗәле тәэминатчысы булу. Без авыл халкын яңа технологияләр, яңа җиһазлар һәм эш кораллары белән тәэмин итәргә омтылабыз. Чөнки нәкъ менә ышанычлы матди-техник база авыл хуҗалыгында җитештерүченең икътисадый иминлек нигезен тәшкил итә», – ди «Татагролизинг» АҖ генераль директоры Азат Илдус улы Җиһаншин.

ЛИЗИНГ ШАРТЛАРЫ:

Лизинг срогы – 5 елга кадәр.
Еллык кыйммәтләнү күләме – 5%
Беренчел кертем 20%тан башлана
Барлык техника 70×30 программасы буенча субсидияләнә.

АКЦИОНЕРНОЕ ОБЩЕСТВО
ТАТАГРОЛИЗИНГ

Тулырак мәгълүматны +7 (927) 487-17-25; +7 (987) 291-97-93 телефоннары аша алырга яки компаниянең рәсми сайтында табарга була: https://tatagrolizing.ru/

Фото «Татагролизинг» АҖ тарафыннан бирелде. Реклама.

КОРЫЛЫК ЭЗЕ...

Автор: Руфия Фазылова

Быелгы аномаль эссе җәй бернича рекорд куйды. Һичшиксез, ул тарихта калачак. Авыл хуҗалыгы тармагында эшләүчеләр, авыл кешеләре дә быелгы җәйне ким дигәндә бер ел – киләсе урып-җыюга кадәр онытмаячак. Иген уңышы белән хәлләр мөшкел бит...

ЧИТТӘН АЛЫП КАЙТЫРГА?

Аяныч, әмма узган елгы уңышның яртысы гына җыелган. Республикада булган мөгезле эре терлек, кош-кортны асрап чыгу өчен ким дигәндә 800 мең тонна иген җитми. Моның өчен 3,3 миллион тонна кирәк булса, амбарларга 2,3 миллион тонна гына ашлык кайткан. Дөрес, әле кукуруз уңышын җыеп аласы бар. Тик ул да хәлне әллә ни үзгәртмәячәк, ди авыл хуҗалыгы тармагы өчен җаваплы җитәкчеләр. Шулай да алар төшенкелеккә бирелмәскә киңәш итә – 2010 елгы корылык вакытында 600 мең тонна гына иген җыеп алынган, тик республикада мөгезле эре терлек саны әллә ни кимемәгән. Быел хәл алай ук куркыныч түгел кебек.

– Игенне Россиянең башка төбәкләреннән алып кайтачакбыз, проблема булырга тиеш түгел, – дип ышандырдылар республика Авыл хуҗалыгы министрлыгында.

Инде саннарга тукталыйк. Республиканы иген белән тәэмин итүдә Алексеевск районы беренчелектә – 103 мең тонна. Икенче-өченче урыннарны Чистай (102,6 мең тонна) һәм Арча (102,5 мең тонна) районнары бүлешә. Ә менә гектардан чыккан уңыш буенча беренчелектә Тукай районы – 21,7 центнер, тәтешлеләр икенче – 22,2 центнер һәм янә чистайлылар – алар 20 центнер уңыш җыйган. Аңлашыла ки, бу уртача күрсәткеч. Кайбер җирләрдә узган елгы кебек уңыш алучылар да булган.

– Мисал өчен, Нурлат районының бер хуҗалыгында кырык центнердан артык уңыш җыйдылар, – ди республика Авыл хуҗалыгы министрлыгының игенчелек тармакларын үстерү бүлеге җитәкчесе урынбасары Фәргать Зиннәтов. – Бүтән районнарда да шундый күрсәткечләр бар. Шул ук вакытта бер үк районда гектарыннан 10 центнер гына иген алучы хуҗалыклар да бар.

– Моның сәбәбе нәрсәгә бәйле? Бер үк районда ни өчен күрсәткечләр шундый төрле? – дим.

– Беренче чиратта бу явым-төшемгә бәйле. Анализ ясап карадык – уңыш әйбәт булган хуҗалыкларда вакытында яңгыр яуган. Кызык, әмма шулай – яңгыр бер авылда коеп яуса, күрше авылда тамчы да төшмәгән. Менә шуңа да иген уңышы төрлечә.

– Димәк, иген уңышы фәкать явым-төшемгә карый?

– Әйе, карый. Әлбәттә, без бүген яңа технологияләр белән эшлибез, җирне файдалы ашламалар белән тукландырабыз. Тик тәҗрибә күрсәткәнчә, яңгыр яумаса, болар гына булышмый.

– Авыл хуҗалыгы өчен быелгы ел авырмы?

– Җиңел димәс идем. Узган көз игеннең бәясе 8–10 сум иде. Дөрес, язга ул 13 сумга күтәрелде. Быел исә көзен игеннең уртача бәясе 17 сумнан башлана. Язга тагын артачак, дип уйлыйм.

Фотолар ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгы сайтыннан алынды

– Игеннең бәясе бермә-бер күтәрелгәч, ипинең, итнең, сөтнең дә бәясе артырмы? Ничек дип уйлыйсыз?

– Күпкә артыр дип уйламыйм, чөнки алар барысы да дәүләт контролендә. Мисал өчен, фермерның бүген сөтен 30 сумнан бирәсе килә, ди. Ләкин республика буенча куелган уртача бәя бар. Яки ул аны бүген билгеләнгән бәядән – 23–24 сумнан сата яки бөтенләй сатмый. Ә сөтне озак саклап булмый. Димәк, фермер отамы, оттырамы, барыбер сөтен хөкүмәткә тапшыра. Ит белән дә шул ук хәл. Куелган бер бәя бар, аннан арттыра алмыйсың.

УҢЫШ ҺӘМ УҢЫШСЫЗЛЫК СЕРЕ НИДӘ?

Инде аерым районнарга тукталыйк. Тулаем иген җыеме, гектардан чыккан уңыш буенча да Чистай лидерлар рәтендә. Тик чистайлылар быелгы уңыш белән барыбер бик канәгать түгел, чөнки узган елгы уңышның нәкъ яртысын гына җыйганнар.

Чистай районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитәкчесе Александр Ромадановский әйтүенчә, районның яхшы иген алуга бөтен мөмкинлекләре булган. Тик планны һава торышы бозган.

– Без игеннәрне урып-җыюга бик иртә – 8 июльдә керештек, – ди җитәкче. – Авыл хуҗалыгы тармагында күптәннән хезмәт куям, тик болай иртә эш башлаганны хәтерләмим. Читтән карап торганда иген кыры матур гына кебек, ә башакны ачып җибәрсәң, бөртек буш, терлеккә ашатырга гына яраклы. Дөрес, кайбер хуҗалыкларда сыйфатлы ашлык та чыкты.

Бер начарның бер яхшысы дигәндәй, быел урып-җыю эшләре югалтуларсыз булды, чөнки һава торышы коры торды. Ә бит кайбер елларда кырдагы игенне җыя алмыйча тилмерәләр. Александр Ромадановский да әлеге фикерне куәтләде.

– Башка районнар белән чагыштырганда, сездә иген уңышы яхшы. Моның сере нәрсәдә? – дидем җитәкчегә.

– Ул күп нәрсәгә бәйле. Шул ук яңгырның вакытында явуы, җирнең уңдырышлылыгы, игеннең кайчан чәчелүе... Район буенча хуҗалыкларны караганда саннарның төрле булуын күрәбез.

– Корылыктан Чистай районы зур зыян күрдеме?

– Зур димәс идем. Игеннең үзкыйммәте белән бүгенге сату бәяләрен караганда, җитештерүче минуска китәргә тиеш түгел. Агрофирмалар исә иминиятләштерү компанияләреннән компенсация алачак. Кыскасы, район аграрийлары өчен агымдагы ел зур проблема тудырмас, дип ышанабыз.

Югары Ослан районы, киресенчә, исемлекләрнең иң азагында. Биредә республика буенча иң түбән күрсәткеч – җәмгысы 11,7 мең тонна иген уңышы алганнар. Гектардан чыккан уңыш күләме – 9,6 центнер.

– Әйе, – дип килсенде районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитәкчесе Рашат Гобәйдуллин. – Быел чынлап та авыр ел булды. Бу әлеге дә баягы корылык белән бәйле. Яздан яңгыр яумаган җирләр булды. Шуны аңлагыз: кеше кесәсенә керергә хокукыбыз юк. Районда өч эре инвестор бар, калганнары вак фермерлар. Җирне ничек тукландырырга, нәрсә чәчәргә икәнен киңәш кенә итә алабыз. Калганын алар үзләре хәл итә. Инвесторның акчасы нәрсәгә җитә, шулай эшли.

Бу очракта җитәкче тагын бер мөһим әйбергә игътибар бирергә киңәш итте – районнардагы җирнең уңдырышлылыгы буенча махсус тикшерү үткәрелгән, нәтиҗәдә аерым бер исемлек булдырылган. Һәм менә шул исемлектә Югары Осланда җирнең уңдырышлылыгы 22 процент күрсәтә. Ә Буа районында бу сан 40 процент икән. Димәк, һава шартлары уңай килгән очракта да, Буа белән Югары Осланның уңыш нәтиҗәләре бер була алмый.

– Монда тагын бер нәрсә бар, – дип сүзен дәвам итте җитәкче, – табыш турында сүз башлагач, бер килограмм игенгә киткән чыгымны исәпләп чыгарырга кирәк. Мисал өчен, хәлле инвестор гектарыннан алтмыш центнер иген алды, ди. Моның өчен ул җирне ким дигәндә өч-дүрт тапкыр тукландыра, ашлама кертә. Ә гади фермер гектарыннан унсигез-егерме центнер уңыш ала. Чөнки ул җирне бер генә тапкыр ашлаган. Нәтиҗәдә уңыш та шуның кадәр. Һәм исәпләп карасаң, күп уңыш алган инвестор оттыра, ә фермер ота.

Менә шуңа күрә дә Рашат Гобәйдуллин уңыш артыннан куының андый юлын бик үк дөрес түгел, дип саный. Беренчедән, бу акчаны җиргә түгү, икенчедән, экологиягә зыян.

САННАР

РЕСПУБЛИКАНЫҢ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ МӘГЪЛҮМАТЛАРЫНА КАРАГАНДА, агымдагы елда 2,3 млн тонна бөртеклеләр җыеп алынган. Бер гектардан уртача уңыш – 15,4 центнер.

БЕЛГЕЧЛӘР ИСӘПЛӘП ЧЫГАРГАНЧА, һава торышының коры килүе аркасында республика авыл хуҗалыгы тармагы якынча 25 миллиард сум акча югалткан.

НИ ХӘЛЕҢ БАР, ФЕРМЕР?

Инде мәгълүм булганча, корылык нәтиҗәсендә республиканың кырык ике районында гадәттән тыш хәл игълан ителде. Нәкъ менә башак ялраган, формалашкан вакытта, ягъни май азагы, июнь айларында явым-төшем

булмады. Күп районнарда норманың яртысы да яумады. Нәтиҗәсе көз алдында.

Белгечләр исәпләп чыгаруынча, һава торышының коры килүе аркасында, республика авыл хуҗалыгы тармагы якынча 25 миллиард сум акча югалткан. Дөрес, Россия хөкүмәте чыгымнарның күпмедер өлешен кире кайтарачак. Тик бу нигездә зур агрооешмаларга караячак. Татарстанда 268 мең җир иминиятләштерелгән, бу барлык чәчүлек җирләренең ун проценты дигән сүз. Күргәнебезчә, саннар әллә ни мактанырлык түгел.

Гади авыл фермеры, җир кешесенең хәле ничек соң? Яңа Чишмә районының Акбүре авылында яшәүче Рузалия һәм Хатыйп Нуруллиннар – фермер. Хуҗалыкларында 13 баш тана, 11 бозау, 5 үгез, 4 ат бар. Ишегалларында трактор тора. Быел сигез гектар пай җирләрендә иген үстереп, малларга җитәрлек азыкны үзләре әзерләргә җыенганнар. Тик корылык Нуруллиннарның бөтен планнарын челпәрәмә китергән.

– Чәчкән ашлыгыбыз тишелмәде, – ди Рузалия апа. – Сигез гектар җирдә алабута үсеп утырды. Инде менә җирне сукалап, яңадан чәчәсе булыр.

Нуруллиннар башта бик борчылган – күпме хезмәт әрәм бит! Тик нишлисең, язмыштан узмыш юк.

– Исәнлек булсын инде, – дип дәвам итте сүзен әңгәмәдәшем. – Хатыйп алтмышны тутыра, миңа илле биш яшь була. Әллә ни күп эшләп тә булмас. Фәлән баш мөгезле эре терлекне асрарга игене, печәне, сәламәтлеге дә кирәк...

РЕСПУБЛИКА КЫРЛАРЫННАН КҮПМЕ ИГЕН ҖЫЕЛГАН?*

Район	Тулаем җыем, мең т
Алексеевск	103,5
Чистай	102,6
Арча	102,5
Тәтеш	96,2
Тукай	91,7
Буа	90,9
Минзәлә	87,7
Балык Бистәсе	84,9
Спас	75,7
Сарман	75,5
Актаныш	71,8
Аксубай	68,9
Мамадыш	65,7
Азнакай	64,9
Чүпрәле	64,5
Зәй	63,6
Мөслим	60,6
Нурлат	60,3
Кукмара	59,7
Балтач	59,4
Питрәч	53,6
Әлки	52,3
Яңа Чишмә	48,8
Чирмешән	47,3
Биектау	45,9
Лениногорск	39,9
Алабуга	39,6
Әгерҗе	39,4
Бөгелмә	37,8
Саба	36,4
Апас	35,9
Әтнә	32,6
Түбән Кама	32,4
Теләче	31,1
Баулы	31,0
Ютазы	30,2
Лаеш	29,4
Әлмәт	28,9
Кайбыч	25,6
Кама Тамагы	24,9
Менделеевск	19,8
Яшел Үзән	16,3
Югары Ослан	11,7
Татарстан буенча	2341,5

* *ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгы мәгълүматлары буенча*

Шулай итеп, Нуруллиннарга игенне сатып алырга туры килгән. 4,5 тонна ашлыкны амбарга алып кайтканнар. Әле сөенгәннәр – килосы 16 сумнан гына булган. Дөрес, ел әйләнәсе ашатырга җитмәячәк ул. Тик кем әйтмешли, юрганыңа карап аягыңны сузасың.

– Печәнне җәй буе үзебез җыйдык, – ди Рузалия апа. – Бер тик тормадык инде. Җыеп киптергәч, аны төргәкләп ясаттык. Алай җайлырак, печән чәчелми дә, ташырга да җиңел. Әнә шундый 35 төргәк булды. Саламны исә «Аксу Агро» җирләреннән алып кайттык. Алдагы елларны алар, башакны ургач, саламны җиргә ваклатып сиптерәләр иде. Быел авыл җирлеге башлыгы әйткәч, саламны халыкка бирделәр. Алланың рәхмәте булсын. Бөтенесен сатып ала башласаң, файдасыннан күбрәк зыяны кала бит.

Нуруллиннар хуҗалыгында таналар Гереформ токымлы. Аларны саварга кирәк түгел икән, чөнки сөтне бозаулар имә. Бер карасаң бу яхшы да, эше җиңелрәк. Тик хуҗабикә моңа бик үк разый түгел:

– Сыер асрап та сөт күрмәгәч, сәер инде, – ди ул. – Гереформ токымлы сыерлар кызык икән – якын да китермиләр. Алты айга кадәр бозауларын имезделәр. Хатыйпка: «Иялэндереп карасак, аз булса да сөтен тапшырып, вак-төяккә акчасы булыр иде», – дигән идем. Кая ул, кыргый хайваннар кебек!

Олыгаеп барган мәлдә ир белән хатын шулай фермер булып куйган. Дәүләттән бер ярдәм алмыйча бит! Хәер, быел язын 3 миллион грант алыр өчен барлык документларны җыйганнар. Соңгы көн килеп җиткәч, кире уйлаганнар.

– Грант акчасына җир эшкәртү өчен бөтен техника, җайланмаларын алырга тиеш идек, – ди Рузалия апа. – Бер документ белән кире бордылар. Шуннан кайткач яңадан уйлаштык та гранттан баш тартырга булдык. Әле ярый алмаганбыз, менә быел утырткан иген тишелмәде дә. Ә бит грант алган очракта биш ел дәвамында хисап тотасы була. Болай исә теләсә кайчан малларны бетерергә була, кем алдындадыр хисап тотасы юк.

...Гади кулланучы буларак, әлбәттә, икмәккә, иткә бәя артуга каршы мин. Югыйсә авыл хуҗалыгы өчен авыр ел килгәнен дә аңлыйм. Тик ашаган белми, тураган белә – иген игүче, мал үстерүче дә эшләгәненә күрә әҗерен алырга тиеш бит. Өстән кушканга, халык дулкынланмасын, бәяләр тотрыклы торсын өчен фермерлар гына җавап бирергә тиеш түгелдер. (Ни дисәң дә, зур инвесторларга дәүләт ярдәме күбрәк). Дөресен әйтим, авыл хуҗалыгы тармагында эшләүче гади кешене кызганып куйдым. Иген, печәнгә бәя артты, ә үзләре үстергән ит, сөткә бәя куя алмыйлар, чөнки ярамый. Монда бер генә теләк – быелгы авыр елны күпләп мал тотучы хуҗалыкларга, фермерларга дәүләт ярдәме күрсәтелсен иде. Т

ГЕКТАРДАН ЧЫККАН УҢЫШ**

Район	ц/га
Тукай	21,7
Тәтеш	21,5
Чистай	20,7
Балтач	19,9
Зәй	19,3
Мамадыш	18,7
Алексеевск	18,2
Арча	18,0
Минзәлә	18,0
Кукмара	17,2
Спас	17,1
Аксубай	17,0
Питрәч	16,6
Балык Бистәсе	16,5
Актаныш	16,2
Әтнә	16,1
Буа	16,1
Сарман	16,1
Чүпрәле	16,1
Алабуга	15,8
Түбән Кама	15,7
Саба	15,0
Биектау	14,7
Менделеевск	14,0
Теләче	14,0
Ютазы	13,7
Нурлат	13,7
Әгерҗе	13,3
Әлки	13,3
Яңа Чишмә	13,2
Азнакай	12,9
Лениногорск	12,7
Лаеш	12,4
Кама Тамагы	12,0
Апас	11,9
Яшел Үзән	11,8
Бөгелмә	11,6
Мөслим	11,6
Баулы	11,0
Чирмешән	10,7
Кайбыч	10,3
Югары Ослан	9,6
Әлмәт	6,9
Республика буенча	15,4

** ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгы мәгълүматлары буенча

PRESSA

НУРЕТДИН НӘҖМИЕВНЕҢ ТОРМЫШ ЛИНИЯСЕ

Автор: Руфия Фазылова

Аллага шөкер, бик яхшы тәрбия алдык. Әтием – Коръән-хафиз. Гап-гади колхозчы гаиләсендә тугыз бала үстек. Дүртесен әни тапмаган, әтинең мәрхүм булган хатыннарыныкы. Ни кызганыч, әтинең хатыннары бер-бер артлы үлеп барган. Әмма гаиләдә әни балаларны бүлмәде, барыбыз да тигез булдык.

Әнием туксан биш яшенә кадәр яшәде. Әти генә иртә китте. Миңа тугыз яшь тулгач, дөнья куйды. Әти сугышта катнашмаган, кулак дигән мөһере булган.

Әти дә, әни дә матур җырлый иде. Мин дә кечкенәдән сәнгатькә тартылганмын. Аннан авылда да шушы юнәлештә зур эш алып барылган. Укытучылар белән концертлар, спектакльләр куеп йөрдек. Менә шулай шомарганбыз, дип уйлыйм. **Мине сәнгатькә этәрүче беренче укытучым Фаягөл апа Сафина булды, бик зур рәхмәт аңа.**

Беренче тапкыр чын артистларны 1957 елда күрдем. Туган авылым Балыклы Чүкәйгә җигүле атлар белән килде алар. Без, бер төркем малай, шул тирәдә уйнап йөрибез. Артистларның клуб эченә әйберләрен ташып бетергәнен карап тордык. Кызыксынуым шундый көчле булган: клубка кереп, сәхнә артына бардым. Карасам, бер абый ап-ак баянында «Чистай» вальсын уйный. Ул вакытта әле мин аның нинди уен коралы икәнен дә белмим. Уйнап бетергәч, теге абый мине күреп алды.

– Кем син? – ди.

– Шушы авыл малае, – мин әйтәм. – Минем чын артист күрәсем килде...

– Нәрсә, артист буласың киләме әллә? – ди.

– Әйе. Театр артисты...

Фото: Александр Ефремов

Шуннан ул миңа бер кечкенә генә кәгазь язып бирде.
– Кич концертка кил. Билет тикшерүче апаңа менә шушы язуны күрсәтерсең, – диде.
Соңыннан мин бу яхшы күңелле артистның якташыбыз, композитор Фәтхерахман Әхмәдиев икәнен белдем. Һәм кош теледәй әлеге язуны бик озак еллар сакладым.

Артист булу теләге каян килгәнен төгәл генә әйтә алмыйм. Без үскәндә телевизорлар юк иде бит. Аның каравы радиодан спектакльләр тыңлый идем. Күрәсең, менә алар миңа этәргеч биргән дә.

Туган авылымда җиде класс тәмамлаганнан соң, Казанга укырга килдем. Мин моны бәхетле очрак дип саныйм. Һич онытмыйм – мине авыл советына чакырдылар. «Яхшы укыган балаларны чакыралар. Барасыңмы?» – диләр. Шунда ук ризалаштым.

Хәзер оныгыма ундүрт яшь. Нәкъ аның яшендә мин Казанга килгәнмен. Әни мине ничек курыкмыйча чыгарып җибәрде икән дим?! Буйга да бәләкәй бит. Хәер, өч абыем, бер апам Казанда иде. Әти белән әни шуңа да ышанып чыгарып җибәргәннәрдер. Казан минем өчен ят түгел иде, җәй саен кунакка барып кайта идем. Аз-маз гына русчасын да өйрәнгәнмендер.

Казанда 80 нче мәктәпкә – татар сыйныфына алдылар. Бер үк вакытта башкаланың Профсоюз урамындагы Мәгариф йортына, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Хәбир ага Хәлилов җитәкләгән театр түгәрәгенә йөри башладым. Шунда җырчы Таһир Якупов белән якыннан танышып, дуслашып киттек. Аның җырчы, минем театр артисты булырга хыялланып йөргән чак. Таһирның да матди хәле начар – гаиләсе фәкыйрь. Бары бер хыял – мәдәнияткә, сәнгатькә тартылу безне алга алып барган.

1965 елны Минзәлә театры гастрольләр белән Казанга килде. Бер спектакльне дә калдырмый карап бардым. Шуннан берсендә, кыюлыгымны җыеп, сәхнә артына кердем. Анда театрның баш режиссеры Сабир Өметбаев белән таныштым. Алланың рәхмәте, уртак телне тиз таптык. «Артист буласым килә», – дидем. Ул минем сәләтемне тикшереп карады. Нәтиҗәдә театрга эшкә чакырды.

Ноябрьнең салкын бер кичендә, шәкерт кебек төенләп, Минзәләгә килеп төштем. Карасам, трамвай да, троллейбус та юк. И, мин әйтәм, кая килеп эләктем мин. Шуннан театр бинасын эзләп табып, артистлар белән танышып киттем. Тулай торактан бүлмә бирделәр. Сабир Өметбаев яңа әсәр куярга әзерләнә иде – «Ана йөрәге» мелодрамасы, шунда мин малай ролен уйнадым. Беренче чыныгу шул булды.

Булачак җәмәгатем Сания белән 1973 елда таныштык. Җәйге ял вакытында бер төркем артист белән авылларга гастрольгә дип чыгып киттек. Максат азрак акча эшләп алу иде. Маршрутны алдан билгеләдек – Чистай, Аксубай, Спас районнары. Авылдан авылга йөри торгач, Спас районының Чәчәкле дигән авылына килдек. Анда бер җыйнак кына йортка торырга кердек. Менә шунда Санияне күрдем. Әнисе белән генә яши иде ул. Өйләренең пөхтәлеге, матурлыгы... Әле дә күз алдымда тора, чөнки йөрәккә кереп калды.

Гастрольләр белән бүтән районга киткәч, Саниягә хат язып салдым. Хисләремне аңлаттым. Озак та узмады, аннан да җавап килде. Менә шулай бер елга якын хат алыштык. Һәм 1974 елның августында рәсми рәвештә язылыштык. Илле елга якын бергә яшибез, Аллага шөкер. Сания да бик күп еллар Тинчурин театрында тегүче булып эшли. Хәзерге көндә дә эшен дәвам итә.

Тормыш безгә сынаулар бирә-бирә икебезне бер фикердә булырга, бер-беребезгә терәк булып яшәргә өйрәтте. Аның белеме юк, синә иҗатны аңлый торган кеше кирәк, дип акыл өйрәтүчеләр дә булмады түгел. Сания кебек театр сәнгатен нечкә тоемлаучы тагын кем бар икән? Менә фәлән өстән генә уйнады, алайга калгач, сәхнәгә чыкмавың хәерле, дип әйтә иде ул. Авыр рольләрдән соң хәлне аңлый иде. Арабызда беркайчан ясалмалык булмады.

Минзәлә театрында эшләгәндә, Казан театр училищесына укырга кердем. Аны тәмамлагач, 1976 елга кадәр шунда эшләдем. Аннан соң исә Казанга кайтып, Кучмә театрда эшли башладым. Минзәләдән китәрбез дип уйламаган да идек, тик торак мәсьәләсе аркасында директор белән сүзгә килдек тә, шул ук көнне эштән китү турында гариза яздым.

Тормышта үкенечләр, фаҗигаләр дә булды. Шуларның иң зурысы – улыбыз Салаватны югалту. Сания белән икебез дә театрда эшләгәч, гастрольләргә гаилә белән йөрдек. Берсендә дүрт яшьлек Салават улыбызны Чиләбе өлкәсенә алып киттек. Ә анда радиация калдыклары булган икән. Югыйсә баргач, ул турыда җирле халык кисәтте дә. «Бездә сыерлар өч кенә ел яши», – диделәр. Хәтта сөт алып эчтек. Безгә зыяны булмады, ә менә улыбыз шуннан авырып кайтты.

Соңрак Салаватыбызга кан рагы дигән диагноз куйдылар. Дүрт ел интекте балакаем. Сигез яшендә дөнья куйды. И, ул вакытта түккән күз яшьләре... Әле бәхетебезгә кызыбыз Рузилә туды. Ул безгә яшәргә көч бирде. Рузиләбез дә иҗат юлын сайлады – «Әкият» курчак театрында эшли. Бер оныгыбыз бар – Камилә исемле. Киявебез Радик сәнгатьтән ерак булса да, бу өлкәне ярата, безне хөрмәт итә, бергә аңлашып яшибез, рәхмәт балаларга.

Үкенеч дигәннән... Минзәләдән Казанга күченеп кайткач та, Галиәсгар Камал театрына Марсель абый Сәлимҗанов янына бардым. Ул документларны берсүзсез алды. Ә безгә бит иң беренче торак кирәк. «Әле генә торак бирә алмыйм, майга кадәр берәр җирдә яшәп торырсыз, аннан күз күрер», – диде. Инде ризалашып чыккан идем. Театр фойесында авылдашым, драматург Сәет Шәкүровны очраттым. Ул Күчмә театрда директор ярдәмчесе булып эшли иде. Сөйләшеп киттек, ул миңа бүлмә тәкъдим итте. Шуннан Марсель Хәкимовичка рәхмәт тә әйтә алмыйча, документларымны Камал театрыннан алып, Күчмә театрга илтеп бирдем. Марсель абый әле бер очрашкач та: «Ай, ялгыштың!» – дип әйтте.

Ләкин Күчмә театрда да җай гына бармады. Баш режиссер Равил Тумашев шактый вакыт роль бирмичә газаплады. Ел ярымнар шулай интектем. Аннан соң юлымда Туфан Миңнуллин очрады. Без аның белән Бауман урамында очраклы рәвештә күрештек. Минзәләдә эшләгәндә Туфан абый спектакль куйды, шуннан калган дуслык иде. Ачыктан-ачык аңа барысын да сөйләп бирдем. «Күчмә театр өчен махсус музыкаль комедия язам. Үзем куям. Шушы атнада эшен бетерәм», – диде. Туфан абый миңа баш рольне бирде. «Алай түгел, болай ул» музыкаль спектакле иде. Без ул спектакльне унбиш ел уйнадык. Тамашачы бик яратып кабул итте аны. Шулай итеп, Күчмә театрда үземне актер итеп күрсәтә алдым.

Бүгенгәчә шаккатам: шулкадәр кыенлыклар күреп тә, актерлык эшенә мәхәббәт сүрелмәгән. Театрга моның кадәр бирелгәнлек кайдан килгән икән? Елның түгыз ае гастрольләрдә үтә иде бит. Кар, буран димисең, чыгып китәсең. Һич онытмыйм, 1984 елны Күчмә театр белән йөргәндә «Хаҗи әфәнде өйләнә»не авыллар буенча алып чыктык. Кыш, салкын. Чистай районы буйлап йөрибез. Спектакль куйганнан соң, администратор безне унсигез чакрым ераклыктагы бүтән авылга алып китте. Автобусыбыз кырда туктап калды, чөнки күз ачкысыз буран иде. Ерак түгел авыл утларын күреп алдык. И, сөенештек! Һәм кыр казлары кебек тезелешеп, бер-беребезгә тотынып, төнлә шул авылга киттек. Чөнки автобуста калсак, туңып үлә идек. Алланың рәхмәте, исән-имин әйләнеп кайттык.

Хәзер инде яңа рольләр алмыйм. Узган ел театр җитәкчелеге белән бу хакта сөйләштек. Дөрес, узган ел яңа әсәр – «Каруман»ны куйдык әле.Бүгенге көндә җиде спектакльдә катнашам. Шул җитә дип саныйм. Яшь барган саен үзен сиздерә. Сәхнә бик зур көч сорый. Йөздән артык роль уйналды, Аллага шөкер, дим.

Егерме сигез режиссер белән эшләдем. Бу әле Минзәләне кертмичә. Режиссер дигәннән, Тинчурин театрының режиссерсыз торган чагын авыр кабул иттем. Һәр театрның режиссеры булырга тиеш дип саныйм. Көтүчесез көтү була алмый бит. Рәшит белән ничә еллар бергә аңлашып эшләдек. Инде театрыбызга яңа режиссер килде, төкле аягы белән булсын!

Юк, мин килүче режиссерлар начар димим. Мисал өчен: Илгиз Зәйни «Өч аршын җир»не куйды. Аңа кадәр бер театрда да бармады. Ә Илгиз орлыгын тапты, чын күңелдән сөендем дә, гаҗәпләндем дә мин аңа. Тагын бер яшь, талантлы режиссер – Резеда Гарипованы әйтәсем килә. Аның белән дә шактый эшләдек. Беренче тапкыр «Без барыбыз да кешеләр» спектаклен чыгардык. Шундый катлаулы пьесаны ничек итеп халыкка җиткерә алды бит.

Безнең театрда тел ягы әйбәт. Яшьләребез телне камил белә, башка театрлар белән чагыштырганда, дим. Бездә күбрәк авыл балалары, алар телнең тәмен, кыйммәтен сизә, тоя. Артистларыбызда ясалмалык, уйнау юк, ә яшәү дигән нәрсә бар.

Иң яраткан эшем – гөмбә җыю. Аны чистартканда бөтен мәшәкатьләрне онытасың. Үзем тозлыйм да. Кызганыч, быел гөмбә юк, корылык бит. Җәйне хатыным белән Спас районы Чәчәкле авылында уздырдым. Бик рәхәт авылда, театрдан китсәм, күбрәк авылда гына яшәр идек. Әле генә үзебез өчен яши башладык, дип саныйм. Шуңа да күбрәк карчыгым белән, тыныч кына, кабаланмый гына көн итәсе килә. Аллаһ Тәгалә саулык бирсен. Шуннан да кыйммәтлесе юк...

ВИЗИТ КАРТОЧКАСЫ

Нуретдин Нәҗмиев 1946 елның 5 октябрендә Балык Бистәсенең Балыклы Чукәй авылында туа. Татарстанның халык артисты.

1965 елда Минзәлә татар дәүләт драма театрында эшли башлый. 1971 елда Казан театр училищесын тәмамлый. 1976 елда Казанда Күчмә театрга урнаша. Һәм бүгенгә кадәр Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында эшли.

Нуретдин Нәҗмиевнең йөздән артык роле бар.

12+
«КИТАП» ТЫҢЛА!
КИТАП МИЛЛИ РАДИО
КАЗАН 98,6 FM
АО «ТАТМЕДИА» Адрес: 420066, г. Казань, ул. Декабристов, д. 2 ГРН 1071690057834
Реклама

ГАЛИМ ҺӘМ МӘГЪРИФӘТЧЕ

Автор: Илдус Заһидуллин

XX гасыр башы фикри үзгәреш-яңарыш хәрәкәте шәһәрләрдә, җәдит мәдрәсәләрдәге заман яңалыкларына сизгер яшьләр арасында формалаша. Белемле һәм мөстәкыйль фикерләүче кадрлар әзерләү дә, милли гореф-гадәтләргә тугрылык саклаган хәлдә Европа илләре үрнәгендә татар милләтенең алга хәрәкәт итүе дә татар сәүдәгәрләре һәм морза-дворяннарының шәхси матди ресурслары хисабына башкарыла.

Бу язмабыз бик кыска вакыт эчендә милли югары уку йортын – «Галия»не (1906–1919) – гамәлгә куйган, татар җәдитчелек хәрәкәтендә иң билгеле затларның берсе, мәгърифәтче һәм дин белгече Зыя Камали хакында булыр.

«ЗЫЯ» – «ЯКТЫЛЫК, НУР» ДИГӘН СҮЗ

Пәрвазетдин Камали Казан губернасы Тәтеш өязе татар авылларының берсеннән Уфа өязе Келәш авылына китеп төпләнгәнче Иделдә бурлак булып эшләп йөргән ярлы крестьян Җәләлетдин гаиләсендә 1873 елның 9 декабрендә туа. Алты яшендә мәктәпкә керә, зиһенле һәм тырыш шәкерт булып танылган Пәрвазетдин укуын 30 чакрым ераклыктагы Уфада, Хәйрулла Госманов мәдрәсәсендә дәвам итә. Соңрак ул шушы уку йортында хәлфә булып урнаша.

Камали укыган елларда Уфада зур үзгәрешләр була. Бу төбәктә капиталистик мөнәсәбәтләрнең югары тизлек белән үсүе шәһәрләшүдә ачык чагыла. 1888 елда шәһәр Самара–Златоуст тимер юлына тоташа, Көньяк Урал төбәгендәге товар алмашу үзәгенә әйләнә. Калага күченүчеләрнең, шул исәптән татарларның да саны арта. XIX гасыр ахырында шәһәрдә 5,8 мең мөселман яшәсә, 1910 елда Уфа төрки-татарлар саны буенча, Казанны да «узып», беренче урынга чыга – 32,2 мең кеше! Биредә күпсанлы татар дворяннары катламы яшәве дә мөһим үзенчәлек булып тора. Шәһәрдә Мәхкәмәи шәргыя урнашу Уфаны мөселман руханиларының административ үзәгенә әверелдерә. 1898 елның 6 гыйнварында Мәхкәмәи шәргыя казыйлары Хәсәнгата Габәши һәм Ризаэтдин Фәхретдин гомуммилли мәсьәләләр белән шөгыльләнә торган беренче иҗтимагый оешма төзиләр. Ул «Мөселманнарның төрки телен, мәктәп эшләрен һәм укуукыту китапларын бастыруны яңарту» дип атала. Шул ук елны Уфада мөселман хәйрия җәмгыяте уставы теркәлә. 1898 елда хәйрия җәмгыяте Хәйрулла ахун Госманов тәкъдиме белән 22 яшьлек Пәрвазетдин хәлфәне, барлык чыгымнарын каплап, чит илгә белем эстәргә җибәрә. Бу факт егетнең акыллы, сәләтле, тырыш, киң карашлы булуы, яшьтәшләре арасында аерылып торуы хакында сөйли.

Пәрвазетдин Истанбулда башта табигать һәм математика фәннәрен үзләштерә, аннары, остазларыннан рөхсәт алып, Мисырга, Каһирәгә юнәлә, әл-Әзһәр университетының фәлсәфә факультетына укырга керә. Әл-Әзһәрдә татар егете тормышында чын мәгънәсендә зур үзгәрешләр була. Остазлары – университетның ректоры Мөхәммәд Абдо һәм Дагыстани киңәшен тыңлап, егет Пәрвазетдин исемен Зыяга (гарәпчәдән «нур» яки «яктылык» дип тәрҗемә ителә) алыштыра. Исем алыштыру вакыйгасын аның үз тормышын җәмгыятьтә нур һәм яктылык таратуга багышларга карар кылуын атарга мөмкин. Камали Каһирәдә киләчәктә чын дус-

Фотолар автордан алынды

лар булачак әл-Әзһәрдә укучы татар егетләре Муса Бигиев һәм Закир Кадыйри белән таныша. Муса Бигиев белән бергә Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләренә сәяхәт кыла.

Мөхәммәд Абдо талантлы студентын, Париждагы Сорбонна университетында тел өйрәнеп кайтып, әл-Әзһәрдә укытырга калырга кыстый. Ләкин Зыяның максаты ачык билгеләнгән була – гыйлем аша туган халкын алдынгы милләткә әверелдерү.

«ГАЛИЯ» МӘДРӘСӘСЕ МӨДИРЕ

Зыяның укуын тәмамлап Ватанга әйләнеп кайтуы Беренче рус инкыйлабы елларына туры килә. Илдә башланган иҗтимагый хәрәкәт һәм социаль үзгәрешләр милләт мәнфәгатен алга сөргән шәхесләргә ихтыяҗ тудыра.

1904 елда Уфага кайткач, Зыя туган мәдрәсәсендә югары сыйныф шәкертләренә белем бирә, иҗтимагый тормышта актив катнаша башлый. Ул 1906 елның язында «Госмания»дән китә һәм шәһәр җәмәгатьчелегенә заманча, чит илләрдәге дини университетлар тибында югары белем бирә торган мәдрәсә ачарга теләвен җиткерә. Аны ишетәләр. Икенче мәхәллә имамы Зариф Галикәев мәчете бинасының өске агач катын – уку бүлмәләре, аскы ярымподвал таш катын шәкертләргә ятак итеп бирергә риза була. 1906 елның октябрендә, югары сыйныфның хәзерлек бүлегенә һәм беренче югары сыйныфка керү имтиханнары алгач, укырга 70 шәкерт кабул ителә. Камали идеяләре белән рухланган дүрт мөдәррис беренче уку елында бушка эшләү шартына ризалашып, төрле төбәкләрдән Уфага җыйналган көчле, фикерле шәкертләр исә иске, тар һәм караңгы бинада яшәргә күнеп, уку процессын башлап җибәрә. Яңа мәдрәсәнең югары уку йорты икәне исеменә чыгарыла һәм ул «Галия» («гали», «галия» сүзләренең бер мәгънәсе уку-укыту системасында югары белем баскычын аңлата) дип куела. Уку вакыты 6 ел булып, беренче өч ел хәзерлек бүлеге итеп, югары бүлектә тагын өч ел белем алу карала.

1906 елда яшь мөдирнең шәхси тормышында да олы вакыйга була. 8 декабрьдә ул морза кызы Гайшә Дәүләткилдиева белән никахлаша. Бәхетле гаиләдә бер ул һәм ике кыз бала үсә. Гайшә, иренә таяныч булып, мәхәллә мәктәбендә кыз балалар укыта.

1907 елның гыйнварында шәкертләр тәфсирдән, ислам фәлсәфәсеннән, хәдисләр, фикх, гарәп әдәбияты, рус теле һ.б. фәннәрдән шәһәр җәмәгатьчелеге катнашында телдән һәм язма имтихан бирәләр. Искиткеч югары нәтиҗәләр киләчәктә Зыяның планнарын тормышка ашыруда төп иганәчеләр булачак сәүдәгәр Садри Насыйровның, дворяннар Суфия һәм Сәлимгәрәй Җантуриннарның әлеге проектның уңышлы тормышка ашачагына ышанычын арттыра.

1907 елның 7 маенда булачак мәдрәсә бинасының нигезенә беренче таш салына (Уфа урамы, 7 нче йорт). Төзелеш кызу темплар белән барып, 18 ноябрьдә биредә укулар башлана. «Галия»нең үзәкләштерелгән суүткәргеч системалары булган, кызыл кирпечтән салынган яңа уку бинасы техник һәм санитария ягыннан ул заман татар мәдрәсәләренекеннән уңай якка аерылып тора. Аның подвалында – юыну, ашау-эчү бүлмәләре, ашарга әзерләү һәм үзәкләштерелгән җылыту урыннары; беренче катында – шәкертләргә ике катлы караватлы тулай торагы, икенче катында парталар тезелгән һәм түр диварга кара такта эленгән 4 уку бүлмәсе, мәчет һәм мәдрәсә идарәсе урнаша. Бинага электр уты кертү өчен акчаны 1913 елны күренекле дин белгече Муса Бигиев бирә.

Мәдрәсәне карап тоту, матди мәсьәләләр белән шөгыльләнә торган икътисадый бүлек рәисе итеп Сәлимгәрәй Җантурин сайлана. Шәкертләр дә 1907–1908 уку елыннан беркадәр акча түли башлый. Мәдрәсәнең уку-укыту эшләре бүлеген Зыя Камали үзе җитәкли. Мөдир, югары хезмәт хакы тәкъдим итеп, иң гыйлемле мөдәррисләрне эшкә җәлеп итәргә тырыша. «Галия»дә күпчелек укытучылар чит илләрдә, Каһирә, Хиҗаз, Истанбул уку йортларын тәмамлаган шәхесләр була. Шулай ук Казан һәм Мәскәү университетларын, Казан укытучылар мәктәбен, акрынлап – «Галия»не тәмамлаган яшьләр дә белем бирә. Биредә төрле елларда Галимҗан Ибраһимов (татар теле һәм әдәбияты), Әхмәтзәки Вәлиди (фәлсәфә, төрки халыклар тарихы), Гомәр Терегулов (психология), Фатих Сәйфи-Казанлы (тарих), Габдулла Ибраһимов-Шенаси (химия, физика) укытучы булып эшли. Зыя Камали үзе калям, фәлсәфә, тәфсир, Мөхәммәд пәйгамбәр тормышы һәм психология фәннәре укыта. Шәкертләр мөстәкыйль уйласын, бәхәсләшсен, фикерләрен курыкмыйча, ачыктан-ачык әйтсен өчен, зур тырышлык куя, махсус диспутлар оештыра. 1914 елдан музыка да укытыла башлый. Варшава университеты профессоры В.Клеменц 1915–1916 уку елыннан шәкертләр хоры һәм кыллы оркестр оештыра, монда музыкаль һәм әдәби кичәләр үткәрелә. Дөрес, таяк ике башлы булып, мондый иреклек-иркенлек кайсыбер вакыт мәдрәсә шәкертләренең чуалышларына һәм укудан куылуларына яки протест йөзеннән үзләре укуларын калдыруларына җирлек бирә. Өч елга якын биредә укыган, укыту программасын һәм системасын тәнкыйтьләгән, мәдрәсә идарәсенә каршы чыгып сөйләгәне һәм, мәдрәсә шәкерте була торып, «Коръән Алладанмы, түгелме?» дигән китап язган өчен куылган Галимҗан Ибраһимов 1913 елда болай дип яза: «Мин төрле мәдрәсәдә, төрле мәдрәсәләрнең дәресендә булдым. Ләкин Зыя әл-Камали кадәрле шәкертнең гакылына хөррият биргән бер мөдәррискә очрамадым. Аның кадәрле шәкертнең фикердә истикълялын уятырга тырышучы бер остаз күрмәдем... Гакылымның киң хөррият алуында аңа бурычлымын».

1 «Галия» мәдрәсәсе бинасы. 1962 ел.

Сәяси яктан Камали – либераллар лагере вәкиле, кадетлар партиясе тарафдары. Хөр фикерле, киң карашлы Зыя, шул рәвешле, дини уку йорты исеме астында югары белем бирүче ярымдөньяви югары мәктәп төзи. Аның даны Россиянең барлык төбәкләренә тарала. «Галия»дә белем алырга теләп йөзләгән яшьләр Уфага агыла.

«ДИПЛОМАТ»-МУЛЛА

1908 елда дәүләттә реакцион сәясәт көчәйгәч, империя хакимияте җәдитчеләрне панисламчылыкта гаепли башлый. Яңа сәясәтне кадимчеләр үз максатларында кулланырга омтыла. Чиләбе шәһәре руханиларының шикаяте нигезендә жандармерия 1909 елның 15 февралендә уку йортында тентү үткәрә, Камалины сак астына ала. Китап-дәфтәрләр, тикшерелгәч, хуҗаларына кайтарып бирелә. Тентү-тикшерү барышында жандармерия, аудиторияләрдә ирекле тыңлаучыларга юлыгып, мәдрәсә «халык университеты»на әверелгән дигән нәтиҗә ясый; Камалиның лекцияләре гыйльми темаларга багышланган булып, аларда мөдәррис тыңлаучыларны гыйлем хезмәтенә һәм үз-үзеңне үстерү өстендә эшләргә чакыруын билгеләп үтә.

2 Мәдрәсә шәкертләре уку бинасы янында. 1910 ел.

Шул ук елны «Галия»гә ирекле тыңлаучы сыйфатында дәресләргә йөргән, авыр чакта ярдәменнән ташламаган 2 нче мәхәллә имам-хатыйбы Зариф Галикәев вафат була. Россия кануннары буенча дини уку йортлары мәчетләр каршында эшләргә тиеш табыла. «Галия» рәсми рәвештә икенче мәхәллә мәдрәсәсе булып санала. Уфа шәһәренең алдынгы җәмәгатьчелеге 1909 елның 29 маенда мулла итеп Зыя Камалины сайлый, шул рәвешле уку йортының тотрыклы эшләве тәэмин ителә. Зыя, укыту программаларын яшереп, хакимияткә «Галия»нең дини мәдрәсә булуын раслап тора.

Чынлыкта исә «Галия» Идел-Урал төбәгендә Иж-Буби мәдрәсәсеннән соң иң аз күләмдә дини фәннәрне укыткан белем йорты була. Бигрәк тә 1912–1913 уку елында 52 шәкерт мәдрәсәне ташлап киткәч, дөньяви фәннәр укытуга игътибар көчәя. 1914 елда дини фәннәрнең күләме 28,2% тәшкил итә. Башка фәннәр түбәндәгечә бүленә: гарәп теле – 14,7%, төрки (татар) теле – 4,9%, рус теле – 14,1%, дөньяви фәннәр – 35,6%, калган фәннәр – 2,5%. 1911 елны полиция Иж-Буби мәдрәсәсендә тентү үткәреп, аны ябып куйгач, «Галия» беренче дөньяви уку йортына әверелә.

1914 елны мәдрәсә чыгымнарының яртысын каплап барган икътисадый бүлек әгъзалары белән Зыя Камали арасында низаг чыга. Зыялы дин белгечләре әзерләргә тиешле мәдрәсәдә дөньяви белем бирүгә артык зур игътибар булу иганәчеләрдә борчу тудыра. Аларның сүзләрендә хаклык ярылып ята: беренче ун елда мәдрәсәне тәмамлаган 950 шәкертнең (76% татарлар) 38 е генә рухани вазыйфасын сайлый! Икътисадый бүлек әгъзалары Зыя Камалига мөдирлектән китү таләбен куя. Зыяэтдин гомерен багышлаган хезмәтеннән ваз кичә алмый. Ул моңарчы ярдәмнәреннән ташламаган иганәчеләргә рәхмәт әйтеп, матди ярдәм сорап, татар җәмәгатьчелегенә мөрәҗәгать итә.

Уфа байлары акча бирүдән туктагач, 1915 елның җәеннән башлап Мәскәү, Кызыльяр, Казан, Бөре, Зәйсән, Төмән калаларында һәм башка җирләрдә яшәүче татарлар, казахлар, кыргызлар «Галия»нең вакыф фондына 10 мең сумнан артык акча күчерәләр. Шул рәвешле «Галия»не тоту илдәге җәдитчеләрнең уртак иганә проектына әверелә. Әйтергә кирәк, биредә казахлар, кыргызлар, нугайлар, чиркәсләр, үзбәкләр һ.б. халык вәкилләре дә белем-мәгърифәт эсти. Мәдрәсә төркимөселман халыклары өчен югары уку йортына әверелә.

ГАЛИМ ЗЫЯ

Патша бәреп төшерелгәч, 1917 елның мартында Зыя Камали вакытлыча Үзәк Диния нәзарәтенең казые итеп сайлана.

Ул 1917 елның октябрендә Уфа губернасы мөхтәсибе итеп сайлана, Милләт мәҗлесенә милли-мәдәни автономия тарафдарларыннан депутатлыкка тәкъдим ителә, ләкин акрынлап «туфракчылар», ягъни җирле-территориаль автономия лагерена күчә. Большевиклар 1918 елның апрелендә Милләт мәҗлесен тараткач, Камали иҗтимагый эшчәнлектән читләшә. 1919 елда «Галия» мәдрәсәсе дә ябыла. Зыя Камали руханилык хезмәтен дәвам итә: 1924 елга кадәр Уфада 2 нче мәхәллә мулласы, 1936 елга кадәр Үзәк Диния нәзарәте казые вазыйфасын башкара.

Бу елларда Зыя Камали исламият фәне, фәлсәфә белән шөгыльләнүен дәвам итә. Галим буларак, дини мәсьәләләргә заман күзлегеннән якын килергә омтыла. Әйтик, инкыйлаб алды елларында яза башлаган «Халикатталәм вә халикатбәшәр» («Дөньяның һәм кешелекнең килеп чыгышы») дигән хезмәтеннән 1924–1926 елларда Үзәк Диния нәзарәтенең «Ислам мәҗалласы» исемле журналында мәкаләләр бастыра. Аның бу язмаларында изгеләргә, ахырзаманга ышану кискен тәнкыйтьләнә, күпмедер күләмдә исламны социальләштерү омтылышы ясала.

Хәер, авторны күренекле дин галиме буларак таныткан «Фәлсәфәи исламия» («Ислам фәлсәфәсе») хезмәте 1909 елдан нәшер ителә башлый. Дүртенче кисәге «Фәлсәфәи гыйбадәт» исеме белән дөнья күргәч, Риза Фәхретдин аны татар телендә ислам йолалары темасына мөрәҗәгать иткән беренче җитди гыйльми хезмәт буларак хуплап чыга. «Фәлсәфәи игътикадия» («Иман фәлсәфәсе», 1910) дигән беренче һәм «Аллаһы гадәләте» («Аллаһның гаделлеге», 1911) дигән икенче кисәкләре дә галимнәр һәм руханилар арасында бәхәс уята. Кызганыч, ислам хокукы мәсьәләләренә кагылган өченче кисәк кульязмада килеш кала. Бәхәсләр авторның исламны заман күзлегеннән, җәдитчеләр позициясеннән, шул ук вакытта саф дин буларак аңлату омтылышы белән бәйле була. Хезмәтләренең заманчалыгы җәдитчеләр өчен аларны өстәл китабына әйләндерә. Шушы елларда Камали Коръәнне татар теленә тәрҗемә итүгә керешә, бу ике томлык хезмәтен тәмамлый. Әмма ул да басылып чыга алмый. Моннан тыш, галим «Коръән һидаятьләре» («Коръәннең туры юллары») дигән Изге китапка шәрехләр яза.

1913 елны Зыя Камалиның мөселман реформаторлыгы мәсьәләләренә багышланган «Дини тәдбирләр» («Дини чаралар») дигән хезмәте басылып чыга һәм татар-мөселман дөньясында гаять зур шау-шу тудыра.

Шуңа күрә Зыя Камалиның СССРда исламны яңарту хәрәкәтенең лидерларыннан берсенә әйләнүе табигый тоела. Ул дини мәсьәләләрдә күпсанлы чыгышлар ясый, диспутларда катнаша, рәсми булмаган дини басмаларда мәкаләләр бастыра. 1923 елның 3 гыйнварыннан мөселман мәктәпләрендә дин нигезләрен укытуны тыю турында карар чыккач, Мәскәүгә барып аның дөрес түгеллеген исбатларга алынган шәхес тә Зыя Камали була. Ул дин нигезләрен факультатив формада булса да уку йортларында калдыруны сорый. Аның бу эшләре 14 яшьтән олкән балаларга вакытлыча булса да дәрестән тыш дин нигезләрен укытырга рөхсәт алу белән тәгәлләнә.

Әлбәттә, совет хакимияте тарафыннан Зыя Камалиның исламны үстерүне кайгыртуы – ике көчле сыйныф канлы көрәш алып барган вакытта өченче юлны билгеләү кебек кабул ителә. Аны чын-чынлап кысрыклау, фикри сындыру эше алып барыла. Әмма большевиклар хакимияте кыска гомерле булачак дип ышанып, ул илдән китәргә теләми. Әйтик, 1925 елда Харбин татарларының мулла итеп чакыруларын кабул итми.

1936 елны мөфти Ризаэтдин Фәхретдин вафатыннан соң Диния нәзарәте шурасының күпчелек әгъзалары аның урынына Кәшшафетдин Тәрҗеманине сайларга теләсә дә, Совет хакимияте мөфти итеп Габдрахман Рәсүлевне билгели. Зыя Камали протест белдерә һәм Тәрҗемани белән бергә панисламчылыкта гаепләнеп кулга алына. 1938 елны 7 елга төрмәгә хөкем ителә. 1942 елда Самара төрмәсендә бакыйлыкка күчә. Исеме 1956 елда аклана... Т

3

«Галия» мәдрәсәсе мөгаллимнәре һәм шәкертләре. Икенче рәттә утыралар: сулдан икенче Галимҗан Ибраһимов, өченче – Зыя Камали, бишенче – Галимҗан Нигъмәти. 1916 ел.

4

«Галия» мәдрәсәсе мөгаллимнәре. Утырганнар (сулдан уңга): Фатих Сәйфи-Казанлы, Галимҗан Ибраһимов, Зыя Камали, Җиһанша Абдюшев, Закир Шакиров. 1916 ел.

ҮЗЕ ТАНЫШ, ҮЗЕ УЙДЫРМА ЧЫНБАРЛЫК

Автор: Луиза Янсуар

Netflix стриминг сервисы тәкъдим иткән фильм һәм сериаллар ташкыны арасында күңел ачуга йөз тоткан киң масса аудитория өчен дә, бер үк вакытта таләпчән, интеллектуаль һәм зәвыклы караучы өчен дә чын мәгънәсендә затлы тәгам бөртекләре очрый. Шуларның икесе – сезон рейтингы фаворитларына тукталып узыйк.

Фотолар: www.kinopoisk.ru сайтыннан алынды.

ӘГӘР УЛ ЧЫН БУЛСА?..

Мессия / Messiah
Сериал, 2020
1 сезон, 10 эпизод
Иле: АКШ
Жанры: драма, детектив, триллер

Тәнкыйтьчеләр, хаклы рәвештә, бу сериалны дини тәгълимат һәм кануннарга артык инанган һәм аларны анализ күзлеге аша уздырырга, яки чиркәү аталары, раввиннар белән ислам руханилары күзалларга өйрәткәнчә генә шәрехләмәскә дә мөмкин булуына әзер түгел тамашачыга карамаска тәкъдим итә. Тулысынча килешәм. Юкка гына кыю проектларга һәвәс Нетфликс «Мессия»не беренче сезоннан соң ук япмагандыр да бәлки. Сериал платформаларга чыгу белән, Якын Көнчыгыштан башлап АКШ ның үзенә кадәр аңа каршы тыюны дәгъвалаган хатлар дулкыны куба. Хәер, бу шаукым узгач, бәлки, аны яңартырлар да, кем белә. Һәрхәлдә, соңгы эпизодларга караганда, дәвам итәргә һәм яңа тармакларга чыгарга мөмкин дигән тәэсир һәм тоемлау калды.

Әлбәттә, сәяси эчтәлек – беренче планда, һәм сериал, әйтерсең, дөнья аренасында күп еллар дәвамында барган хәлләргә турыдан-туры җавап буларак гәүдәләнеш ала. Әмма шунысы әһәмиятле: сериал авторлары аны һич кенә дә бу якка борып җибәрми, киресенчә, локаль язмышлар һәм система механизмнары аша гаять кешелекле драматик укылышка китерә. Безнең һәрберебезнең үз Алласы һәм Аның белән гомер буена сузылган диалогы бар. Үз зар-интизарлары, үз килешүләре, үз дәгъвалары һәм үз тәмугы белән, үз җәннәте. Әгәр менә бүген, нәкъ шушы мизгелдә безнең каршыбызда чынлап та Мәсих үзе пәйда булса һәм үз артыннан чакырса, кайсыбыз нәрсә эшләр иде? Бу турыда уйланганыбыз бармы? Һәм, гомумән, әзерме без моңа?

Әгәр Ул чын булса, нишләргә?
Әгәр чын булмаса, нишләргә?

Һәм менә тынгысыз һәм хәвефле гадәти көннәрнең берсендә Сүриядә озын кара чәчле чандыр гына бер яшь егет мәйданда пәйда була да авыз эченнән генә нидер пышылдый башлый. Ком бураны, актарылып кубып, Дәмәшкъ шәһәренә һөҗүмгә юнәлгән ДАИШ артиллериясенә ябырыла. Ә егет пышылдавын дәвам итә. Бу хәлләрнең шаһиты булучылар аңа килеп баш ора һәм, «Мәсих» дип, иман китерә. Без, тамашачы буларак, өзлексез сугыш һәм хәвеф халәтендә яшәргә күнеккән кешеләрнең бу адымга баруларына, әлбәттә, аңлау белән карыйбыз. Егетнең ваемсыз һәм тыныч йөзенә, үзен берни булмагандай тотышына һәм кешеләр белән артык нык аралашуга бармавына игътибар итәбез. Менә ул, өметен җуйган һәм кемгәдер ышанырга сусаган кешеләр төркемен ияртеп, Израиль чигенә юнәлә. Арадан бер яшь кенә малайны үз итә, аның белән гәпләшә. Ә малайның исеме – Җәбраил. Израиль чигендә чүл кичеп килеп туктаган бу бәндәләрне автомат тоткан чик сакчылары каршы ала. Алар биредә туктала һәм, ризыктан, судан мәхрүм калып, төн-көннәрен уздыра башлый. Ә Мәсих... Ә Мәсих, аларны шунда калдырып, юкка чыга. Аның чын булуына шикләнә башлыйлар... Әмма, бер йотым суга тилмереп, чүл уртасында яткан теге малай – Җәбраил – инанудан туктамый. Алга таба нәкъ менә ул, артыннан барысын да ияртеп, чик аша алып чыга да...

Сценарий авторы белән режиссер сериалны фрагментар форматка корып, безне бер җирдән икенчесенә сикертеп йөртә, һәм бу эффект чынлап та үтемле. Менә без, Иисус эзләреннән атлап, Гыйбадәт тавына менәбез һәм Мәсихнең беренче вәгазен тыңлыйбыз, аның белән бергә кулга алынып, сорау алу бүлмәсенә эләгәбез, чебен дә очып үтмәслек тимер зинданнан кинәт кенә, күз ачып йомган арада, экраннарны бозык хәлгә китереп, ә аннан яңадан кабызып, юкка чыгабыз, Техас штатындагы кечкенә генә бер шәһәрчектә пәйда булабыз. «Берәү дә болай тик торган җирдән юкка чыгалмый, аңа булышалар!» – ЦРУ агенты Ева Геллерның вердикты әнә шундый.

10 эпизод дәвамында проект авторлары безне төрле геройлар һәм язмышлар белән очраштыра – әлеге дә баягы профессиясендә «ак белән кара» гына бар дигән инану белән яшәгән, биремнәрдән башканы гомумән күрмәскә ияләшкән агент Ева Геллердан башлап, гаиләсе белән мөнәсәбәтләре җимерелгән, намусында кешеләрне җәзалаудан калган җәрәхәт эзләрен йөрткән Израиль разведчигы Авирам Дахан белән дә, үз чиркәвен булдырып, еллар буе Ходайга сыгынып яшәп, кешеләрне иманга китерә алмаган, Аның барлыгына инде ышанудан туктаган диярлек рухани Феликс, аның хатыны һәм Мәсих барысы арасыннан «Аңа аерым миссия йөкләнгән» дип сайлап алачак кызы белән дә, авыру баласын терелтер өчен соңгы өмете

калган ана һәм бала белән дә... Аларның һәрберсе бу үзләре үк игълан иткән коткаручыдан үзенекен көтә. Аның дәшми утыруын, бертуктаусыз вәгазьләр укымавын һәм халык алдына чыгып табыну таләп итмәвен үзләренчә аңлый, гасабилана, дәгъвалый, могҗиза таләп итә. Һәм менә бу ярсыган, каударланган халык өерен үз артыннан ияртеп, Мәсих Ак Йортка юнәлә, инде күптәннән яңа булмаган, хәтта моветон буларак кабул ителердәй фокуска мөрәҗәгать итә – судан йөреп күрсәтә. «Кемне көттегез сез һәм нәрсә көтәсез?» – әнә шул сорау кызыл җеп булып сузыла фильмның буеннан-буена...

Ул арада ЦРУ кинәт пәйда булган геройга досье туплый, фактлар җыя. Безгә махсус агент белән Мәсихнең абыйсы сөйләшүен күрсәтәләр. «Фокуслар ясарга безне әти-әниебез үлгәннән соң алып үстергән агабыз өйрәтте...» – ди ул. Мәсих үзе бу сүзләргә елмаеп, сабыр гына һәм бик гади җавап кайтара: «Әйе, мине ул исем белән беләләр иде, әмма бу берни турында да сөйләми».

Ева Геллер: Кыска гына вакыт эчендә сез берничә җирдә булырга өлгердегез – Сүрия, Израиль, Техас...
Мәсих: Минем эшем шундый.
Ева Геллер: Ул нинди эш инде?
Мәсих: Ходай эше.

Сериалда урыны-урыны белән «Эһ, менә хәзер баналь чишелешкә китерәчәкләр» дигән линияләр пәйда була, мисал өчен,Мәсих артында Россия торганлыгына ишарә, йә булмаса, Ак Йорт, Президент белән бәйле рәвештә халыкара террорны юкка чыгару глобаль планына юнәлтелгән өлешләр. Әмма юк, авторлар сентиментальлеккә дә, баналь чыгармаларга да юл куймый, азакка кадәр интриганы да, чишелешнең гадәти булырга мөмкин түгеллегенә инануны да саклый. Бер генә мизгелгә дә бер генә якны һәм хакыйкатьне сайламыйча, ике чик арасында тамашачыны сират күпере аша уздыргандай йөртәләр. Һәм бу – искиткеч тәэсирле алым.

Стиль ягыннан да, гәүдәләнеш һәм укылыш ягыннан да нәкъ төп геройның үзенә тәңгәл булган бу тыныч, ваемсыз диярлек хикәяләү безгә үз уйларыбыз белән параллельдә булырга мөмкинлек бирә. Мин нәрсә эшләр идем дигән сорау туктаусыз пульсациядә тора. Әнә шуңа да бу бөтен диннәр һәм аның вәкилләре өчен бердәй индерелгән мәсихме, әллә шамакай, шарлатанмы дигән сорау икенчел булып кала. Син аннан тирәнрәк уй һәм хис катламнарына төшәсең. Сайлау алдында калсаң, акылдан шашмас идемме, дип, үзеңне бимазалыйсың. Иманның көче чыннан да таулар күчерерлек икән, дөрес адымның кайсы икәнен ничек аңлар идем, дип шомланасың.

Кыскасы, кешегә бирелгән инану һәм инанмау, сайлау хокукының никадәр зур кодрәткә ия булуыннан әсәренеп калырга мәҗбүр буласың «Мессия» сериалыннан соң. Әгәр бу фильм гына булмаса, нишләргә?!

ИМПЕРИЯЛӘР БЕЛӘН АКЫЛ ЧИГЕНДӘ

Фрейд / Freud
Сериал, 2020
1 сезон, 8 эпизод
Иле: Австрия, Германия
Жанры: детектив, криминал, триллер

Әлеге гаҗәеп атмосфералы, стильле тарихи фантазияне безгә Netflix тәкъдим итсә дә, төшерелүе буенча ул Австрия һәм Германия киноиндустриясенә карый. Беренче мәртәбә күрсәтелүе дә Австриянең ORF каналында була. 2020 елның мартында ук, проект старт алганнан соң, аны әлеге каналда 400 меңнән артык тамашачы карый, һәм ул рекордлы рейтинг туплый.

Әгәр без сериалны XX йөз башында дөнья картинасын баштанаяк үзгәрткән иң каршылыклы һәм атаклы фигураларның берсе Зигмунд Фрейд турындагы байопик дип уйласак, бик нык ялгышабыз. Проект авторлары Фрейд биографиясен һәм эшчәнлеген яктыртуны үз алларына гомумән максат итеп куймый, аларның ниятләре бөтенләй башка –поэтикасы, стиле ягыннан немец киноэкспрессионизмы мирасы һәм Американың детектив, триллер, хоррор ише жанрлы кино кагыйдәләре нигезендә заманча киң социаль тукыма тудыру. Әйтергә кирәк, алар бу максатка ирешә дә.

Шулай да Фрейд тормышыннан аерым фактлар һәм нигезләмәләр алынган. Беренче кадрлардан ук без клаустрофобик тарлыкка һәм дымлы, юеш, тынчу-чиркандыргыч, шул ук вакытта серле-сихри атмосферасы белән үзенә тартып торган Вена урамнарына килеп эләгәбез. 1886 ел – бу Фрейдның яңа гына Парижда әйләнеп кайткан һәм, Жан-Мартен Шарко исемле остазда стажировка үтеп, үзе өчен психиатриядә кокаин һәм гипноз сихәтен ачкан чагы. Шарко – ул чактагы психиатриянең йолдызы, аны хөрмәт итәләр, аның белән исәпләшәләр. Нәкъ менә аңардан Фрейд

психиатриядә истериягә булган кызыксынуны мирас итеп ала.

Терапиядә, бигрәк тә заман чире – истериядә актив рәвештә гипноз кулланыла башлаган бу елларны безгә нәкъ менә символик укылышта тәкъдим итә сериал авторлары. Бу медицина өлкәсендәге истерия генә түгел, бу – гасыр азагындагы катаклизмнар, тарихи болганышлар җәйгән метастазалар фонында һәм киләсе яңа йөзьеллык бусагасында сулыш алып булмаслык тар империя коридорларында барлыкка килгән истерия дә. Яңа пәйда булган һәм барлык авырулардан «дәва» булып исәпләнгән кокаин тәэсирендәге галлюцинацияләрме болар барысы да, әллә чынбарлыкмы? Ахыр чиктә, үлем белән яшәү чигендә йөри-йөри, чик сызыгын җуясың...

Сценаристлар фантазиясе нигезендә, Зигмунд Фрейд герое Австрия-Венгрия тәхете тирәсендә барган империалистик заговор уртасында кала һәм аның хәл ителешенә тәэсир итәргә мөмкин булган төп фигураларның берсенә әверелә. Сериал персонажлары һәм тарихи тукыма шулкадәр виртуозларча эшләнгән, аны карау барышында ирексездән үз белемнәреңне барлый һәм параллельләр эзли (таба һәм югалта) башлыйсың. Шәхсән мин үзем Австро-Венгрия тарихына багышланган хезмәтләргә башым-аягым белән кабаттан кереп чумдым. Әмма тарихи җирлекне пунктуаль рәвештә торгызу күтәргә кирәкми авторлардан, юк-юк, алар кыю һәм куркусыз рәвештә рокировка алымын сайлый, дөресен генә әйткәндә, безнең коллектив һәм индивидуаль хәтергә басым ясап, психоанализ алымнары белән уйный. Һәм менә, гипноздагы сыман, без, полиция офицеры һәм сугыш ветераны Альфред Кисс белән яшь психиатр Фрейд артыннан ияреп, бер үтерелеш вакыйгасыннан икенчесенә атлыйбыз, диварга кан белән сызып калдырган серле символларның асылына төшенергә тырышабыз, Австро-Венгрия аристократиясенең яшерен импульслары һәм уеннары белән очрашабыз. Милли автономия таләп итүче венгрлар һәм империянең югары катламында барган метаморфозалар фонында безне венгр аксөякләре – ирле-хатынлы Сапарилар һәм аларның йортында яшәүче серле туташ – күрәзәче, медиум Флер Саломэ белән таныштыралар. Мавыктыргыч квестка тиң сериал фактурасы интеллектуаль караучыга зур ләззәт китерәчәк, дип уйлыйм. Мәсәлән, Сапарилар нәселе һәм аларның сәяси дәгъваларының нигезенә төшенергә теләсәк, бу атаклы аксөякләр йортының гасырлар дәвамында империягә күренекле дипломатлар, гаскәриләр һәм дәүләт эшлеклеләрен биргәнен ачыклый алабыз. Аларның утарындагы ритуаллар бу йортның Европа масоннары белән бәйләнешенә ишарәли. Шулай ук, ярымчегән, ярымхәзәр мистерияләренә барып тоташкандай тойгы калдыручы Флер күрәзәләре безнең өчен тарих белән психоанализ ишекләрен генә түгел, ә шаманизм белән мәҗүсилек ишекләрен дә ачып җибәрә. Моннан тыш, аның образы безне гасыр башының өч визионеры Фридрих Ницше, Зигмунд Фрейд һәм Райнер Мария Рильке биографияләре белән тыгыз бәйле тагын бер бик тә кызыклы шәхескә алып чыга – ул да булса өч даһиның музасы булган Лу Андреас-Саломэ. Бу хатынкызның XX йөз башы мәдәниятенә, фәненә керткән өлеше әйтеп бетергесез. Юкка гына Ницшеның «сверхчеловек» идеясен Лу Саломэ белән бәйләмиләр дә, аны «Заратустра»ның прототибы дип исәпләмиләр.

> *«Без бер-беребезне юкка гына сайламыйбыз. Без бары тик инде аң катламыбыз төпкелендә булган затлар белән генә очрашабыз»*
>
> *Зигмунд Фрейд*

Әнә шулай итеп, фильмда очраклы очрашулар да, детальләр дә, персонажлар да юклыгына инана башлыйсың.Фактлар да. Эрцгерцогны һәлак итәр өчен корылган заговор да, аның артында торган кешеләр дә очраклы түгел. Флер Саломэ белән Фрейдның очрашуы һәм берберсен бер караштан тоемлавы, игез күрүе дә. Борынгы йортларның берсендә, ташландык фатирда медиум Флерның өрәкләр белән очрашуы, һәм алардан 1881 елдагы Рингтеатрда булган янгынның сәбәпләре турында белүе дә. Тикшерү эшләрен алып баручы Кисснең сугыш вакытында алган психологик ярасы нәтиҗәләре һәм анарда вакыт-вакыт кубарылган хтоник агрессия, фобияләр дә. Композицион яктан, кеше аңының һәм психикасының халәтләрен ассызыклап, сериал Фрейд хезмәтләренең төп тәгълиматлары нигезендә бүленә: «Истерия», «Травма», «Лунатизм», Тотем и табу», «Влечение», «Регрессия», «Катарсис», «Вытеснение».

Массачыл гипнозмы бу? Юк икән, тоташ вакханалиядән соң, ничек яңадан беренчел сафлыгына кайтыр бу адәмнәр, бу мәмләкәт, кешелек? Хәер, юк, катарсистан соң үз аңыннан булган хәлләрне кысрыклап чыгаруга йөз тоткан дәвер, киресенчә, моннан да коточкычрак вакханалиягә йөз тотачак – ике бөтендөнья сугышына, фашизмга, концлагерьларга, кан белән коенуга. Шуңа да Флер Саломэ эчендә яшәгән аның икенче бер истероид ясссылыгын – «Талтыш»ны бары тик психоанализ символы буларак кына кабул итү беркатлылык булыр иде. Мажар мифологиясендә «Талтыш»ны сихерче дип тә, кеше образына керә алучы инферналь зат дип тә тәгаенлиләр. Имеш, «Талтыш» туганда ук ниндидер бер үзенчәлек белән туа һәм аның җирдә үз миссиясе була... Психоанализ белән генә җиңә алырдай көчләрме бу, юкмы...

...Ретроспектив ноктадан торып алга таба тарихи контексттаниләр булачагын белгән без бары тик сериал атмосферасындагы хәвеф тойгысының үз апогеена җитәчәген генә раслый алабыз.

КЫЧЫТКАНЛЫ – ТУГАН НИГЕЗНЕ ОНЫТМАУ

Автор: Руфия Фазылова

Нурлат районында әнә шундый исемдәге авыл бар. Әгәр ул кайсы ягы белән истә калды дип сорасалар: «Ун балалы төп белем бирү мәктәбе, гаҗәп тырыш кешеләре белән», – дияр идем. Тырыш дип әйтүем юкка түгел – биредә һәр ике йортның берсендә умарта тоталар. Көтүгә йөз кырык башка якын мөгезле эре терлек йөри.

Фото: Александр Ефремов



КЫЧЫТКАНЛЫ

ЯЛГЫЗЛЫКНЫ ҖИҢЕП...

Кычытканлы кайчандыр зур авыл саналган. Революциягә кадәр монда биш йөзләп йорт булган. Ни кызганыч, бер гасыр эчендә авыл ике тапкырдан артыкка кимегән. Бүген биредә 216 хуҗалык бар, 424 кеше яши.

Авылда беренче булып күзгә ташланган нәрсә – төзек юллар булды. Үзәк урамнарга асфальт түшәлсә, урам эче юлларына таш җәелгән. Моны үзара салым акчасына эшләгәннәр.

– Башка авыллар да үзсалымны җыя, тик бу кадәр таш түшәлгән юлларны күргән юк иде, – дидем Кычытканлы авыл җирлеге башлыгы Фалис Сабировка.

– Бу яктан безнең бәхет бар – исемнәре республикага билгеле берничә авылдашыбыз сөендерә. Алар даими рәвештә Кычытканлыга ярдәм итеп тора. Мисал өчен, берсе узган ел 500 мең сум акча бирде. Үзсалым сыйфатында аның акчасы гына да ике миллион булып әйләнеп кайтты. Менә шундый дәрәҗәле якташларыбыз ярдәме белән юлны да, чишмәләрне дә карап, төзекләндереп торабыз. Быел да үзсалым акчасына юлларга таш түшәргә уйлыйбыз.

Бу яктан Кычытканлы башка бик күп салаларга үрнәк – Сабан туеннан башлап, тирәюньне төзекләндерүгә кадәр читтә яшәүче авылдашлары ярдәм итә. (Берсе хәтта авыл мәктәбе түбәсен дә яптырган). Дүрт-биш чишмәгә «өй» ясап, янына ял итү урыны да эшләп куйганнар. Саный китсәң...

– Безнең авыл бик укымышлы булган. Күп җитәкчеләр, зыялыларның моннан чыгуы гаҗәп түгел, – ди гомере буе биредә яшәгән Сөләйман Мотаһиров. – Һичшиксез, Кычытканлы – Нурлат районының йөзек кашы. Менә аның бүген шулай картаеп баруына гына эч поша. Яшьләр калмый бит. «Без читкә киткәч тә авылны онытмыйбыз, ярдәм итәбез», – ди алар. Әлбәттә, барысына да зур рәхмәт. Тик яшәргә кеше калмагач, тудырылган ул уңайлыклар да юкка булып чыга...

Сөләйман абый үзе дә ун ел колхоз рәисе, аннан мәктәп директоры булып эшләгән кеше. Соңгы елларда исә Кычытканлы мәктәбендә тарих укыткан.

1

– Мәктәбебезнең йолдызчыгы, – дип таныштырды Аделина Галиуллина белән башлангыч сыйныфлар укытучысы Әминә Әхмәтвалиева.

2

Ирле-хатынлы Мотаһировлар.

3

Кычытканлы манзарасы.

4

– Үз акчабызга фермерлык эшен башладык, – ди Инсаф Атауллин.

– Балалар саны азайгач, мәктәптән киттем. Аз бала белән эшләү кызык түгел, бәхәсләшеп, фикер алышып та булмый, – ди.

Мотаһировларның бакчаларында ни генә үсми! Сентябрь уртасы булуга карамастан, бакча, өй аллары шау чәчәктә утыра.

– Хатыным Әмһилә белән бергә эшлибез, – ди хуҗа кеше. – Быел хәтта җиләк үсентеләрен саттык та. Әмһилә телефондагы авыл төркеменә юри генә язган иде, алып бетерделәр. Җиләкләр сортлы безнең. Уңыш бик әйбәт булды. Гади җиләк мәңге аның кадәр үсми. Ел саен Самарадан Нурлатка сортлы җиләк-җимеш, төрле чәчәк үсентеләре китереп саталар. Менә шуннан алып кайтабыз.

Ир белән хатынның икенче никахлары икән – унөч ел элек кушылганнар.

– Сөләйман хатынын җирләгән иде. Минем дә җәмәгатем мәрхүм булды,-диде Әмһилә апа. – Илле биш яшемдә Нурлаттан Кычытканлыга күчендем. Сөләйман кияүгә сорарга ике баласы белән килде. Минем балалар да кабат кияүгә чыгуыма каршы булмады. Хәер, алар инде барысын да аңлый – әти-әни бер генә була. Сөләйман – әти, мин – әни урынына дәгъва кылмадык. Аллага шөкер, бик тату, бер гаилә булып яшибез. Ике яктан да балалар кайтып йөри. Әле менә зур өстәлгә заказ бирдек. Аш бүлмәсенә сыймыйбыз, оныклар да җидәү бит.

Картлыкта ялгыз яшәргә теләмәгән бу икәү бездә җылы тәэсир калдырды. Сөләйман абыйның туры сүзлелеге, зыялылыгы янына Әмһилә апаның уңганлыгы, көләч йөзе бик килешә. Пар канат булып яшәгәндә күңел дә үсә – берничә дистә сарык асрыйлар, егермеләп баш умарта тоталар, шуның өстенә каз-үрдәк, тавык-чеби...

ТУГЫЗ СЫЙНЫФКА УН БАЛА?!

Кычытканлыда төп белем бирү мәктәбе бар, дидем. 1985 елда салынган ике катлы, зур бинада урашкан ул. Кайчандыр йөз укучы белем алган мәктәптә бүген ун бала укый. Аерым сыйныфлар – өченче, дүртенче, тугызынчылар бөтенләй юк.

Тарихка күз салсак, Кычытканлыда мәктәп 1922 елда ачылган. Шуннан соң ул берничә бинаны алмаштырган. Сиксәненче елларда авыл мәктәбендә икешәр пареллель сыйныфлар булган. Бүген исә әнә шундый бик күңелсез күренеш...

– Мондый хәлдә калуыбыз үзебезгә дә бик авыр, – ди Кычытканлы төп белем бирү мәктәбе директоры Эльмира Сабирова. – Иң кызганычы – алга таба да бала саны артмый. Киләсе елларга да берәр бала гына керәчәк.

Тугызынчы сыйныфны дүрт бала тәмамлаcа, беренчегә бер бала гына кергән. Менә шулай итеп укытучылар, техник персонал саны укучылардан артып киткән.

– Ә ничек мәктәпне япмадылар? – дим, шактый гаҗәпкә калып.

– Беренче чиратта ата-аналар сүзенә колак салдылар. Балаларын еракка йөртәселәре килмәде. Аннары, Кычытканлы районда шактый атаклы авыл, җитәкчеләрнең аны мәктәпсез калдырасы килмәде булса кирәк.

Директор белән белем үзәген карап чыктык. Мәктәпкә капиталь төзекләндерү үткәрелгән, бер дигән сыйныфлар. Белем, тәрбия

5

Кайчандыр йөз бала укыган Кычытканлы мәктәбендә бүген ун бала белем ала.

бирергә укытучылар да җитә, дәреслекләр белән дә проблема юк. Тик шундый шартларда укырга балалар гына юк...

– Аз бала белән эшләү бик авыр, – дип, үз фикерен белдерде мәктәпнең инглиз теле укытучысы Сания Нотфуллина. – Бала өчен дә кыен – конкурентлык дигән нәрсә юк. Ул бит башкаларга карап тартылырга, фикер алышырга тиеш. Хәтта чын бишленең нинди буласын да белми.

– Сыйныфта бер бала гына булгач, белем дәрәҗәсе әйбәтрәк түгелме? Ни дисәң дә, аерым шөгыльләнгән кебек килеп чыга, – дим.

– Юк, аңа карамый ул. Кайбер балага күпме бирсәң дә, фәнне үзләштерү мөмкинлеге чикле була. Нәтиҗәдә, дәрес буе аңлатуың бушка килеп чыга. Укытучы өчен стимул бетә димме.

Ничек кенә булмасын, мөгаллимнәр укучыларның мәктәп елларын күңелле итү өчен кулдан килгәнне эшлиләр. Даими рәвештә төрле чаралар үткәрәләр. Аңлашыла ки, андый вакытта бөтен мәктәп укучыларын җәлеп итәләр.

– Бу безнең мәктәпнең йолдызчыгы – бишкә генә укый, – дип таныштырдылар Аделина Галиуллина белән. Сөйкемле кыз беренче сыйныфтан шулай яхшы укый икән. Олимпиадаларда катнаша, призлы урыннар ала.

– Балалар саны буенча безнең сыйныф мәктәптә иң зурысы – дүртәү без, – диде Аделина. – Безгә күңелле. Бер-беребез белән ярышып укыйбыз. Әле башлангычта җидәү идек, ике кыз гаиләсе белән Чаллыга күченде, бер малаебыз интернатка укырга китте.

– Бик тырыш кыз ул, дәрестә биргәнне «йотып бара», – дип сүзгә кушылды Кычытканлының башлангыч сыйныфлар укытучысы Әминә Әхмәтвәлиева. – Мин аның абыйсын да укыттым. Ул да «5» билгесенә генә укыды, мәктәпне алтын медальгә тәмамлады. Хәзер инде КФУның Физика институтында белем ала. Алла боерса, Аделинабыз да сынатмаячак. Мин моңа шикләнмим.

ЯШЬ ФЕРМЕР

Күп еллар элек Кычытканлы җирләрен «Кызыл Шәрык» оешмасы арендага алган. Кайчандыр биредә гөрләп фермалар эшләгән. Бүген исә ул биналар ташландык хәлгә килгән. Бөтен җирен чүп үләне баскан. Ни кызганыч, мондый хәлне Кычыткан-

лыда гына түгел, башка бик күп авылларда да очратабыз. Җирләрне алган инвесторлар аерым бер ният белән килә, мисал өчен, башаклы культура үстерүне максат итеп куя. Мөгезле эре терлек аларны кызыксындырмый. Нәтиҗәдә, фермалар әнә шундый ташландык хәлгә килә. Димәк, җирле халыкка эш урыннары да бетә.

Әнә шундый ташландык биналарның берсен Кычытканлының тырыш егете – Инсаф Атауллин арендага алган. Максаты – сыер фермасы булдыру. Егерме өч яшендәге егет бүген туган нигезендә әти-әнисе белән яши, Нурлатта эшли.

– Ике ел элек Әлмәт дәүләт нефть институтын тәмамладым, – диде Инсаф. – Һөнәрем буенча эшлим дә. Шактый уйлаганнан соң авыл хуҗалыгы тармагын сайладым. Эшне бертуган абыем белән башладык. Әлегә ферма бинасын ремонтлыйбыз. Алла боерса, бер айдан монда егерме баш нәселле тана алып кайтачакбыз.

– Дәүләттән ярдәм алдыгызмы? – дим.

– Юк. Әлегә дәүләттән бер субсидия, грант та алмадык. Үз акчабызга эш башладык. Аннан соң күз күрер. Берәр конкурста катнашу ниятебез бар.

– Нефть тармагыннан авыл хуҗалыгы бик ерак тора. Фермер булу теләге кайдан килде?

– Беренчедән, без авыл балалары. Өйдә гомер буе мал асрадык. Хәзер дә асрыйбыз. Шулай булгач, минем өчен ят өлкә түгел ул. Икенчедән, әти шәхси эшмәкәр, халыктан сөт җыя. Аның белән дә шактый киңәшләштек. Бүген сөткә бәя начар түгел – егерме дүрт сумнан тапшыралар. Әлбәттә, узган елгыга караганда аның быел игене, печәне дә кыйммәтрәк. Тик бу очракта бер нәрсәне истән чыгармаска кирәк – иген, печән белән бергә сөтнең, итнең дә бәясе арта. Димәк, фермер минуста калмаячак.

Университетта укыганда ук Инсаф үз эшен ачарга хыялланган. Ниһаять, тәвәккәлләгән.

– Шәһәрдә конкуренция көчле, ә авыл хуҗалыгында алай түгел. Бөтен зур инвесторлар да авыл хуҗалыгына килә.

Атауллиннар бүгенге көндә җирләрне арендага алу белән мәшгуль. Өч тракторлары бар. Мөгезле эре терлеккә дигән бөтен азыкны үзләре чәчеп үстерергә планлаштыралар.

Инсафны авырлыклар куркытмый, барысы да килеп чыгасына ихластан ышана ул. Яшь фермерларга без дә чын күңелдән уңышлар телибез!

...Сөенеп тә, көенеп тә кайттык Кычытканлыдан. Менә дигән юллар. Яшәр өчен бөтен мөмкинлекләр бар – мәдәният йорты, ФАП, мәктәп, китапханә, ике кибет, барысының да ишекләре ачык. Тик яшьләр калмагач, алар егерме елдан соң эшләрме? Шомлы, ачык сорау...

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

Сөләйман Мотаһиров, Кычытканлы мәктәбенең элеккеге тарих укытучысы:

– Кызганыч, авыл тарихы документларда сакланып калмаган. Телдән-телгә күчеп килгән тарих кына бар. Иң кызыгы – Кычытканлы документларда Кичкальня дип атала. Югыйсә, кычыткан сүзенең рус теленә тәрҗемәсе – крапива. Ни өчен шулай кереп киткән, һич аңлашылмый. Бу очракта бер генә нәтиҗә ясап була – руслар татар сүзен аңламагандыр.
Бездә укыткан мөгаллим Җәүдәт абый Камалов авылның исеменә бәйле тарихны болай сөйли иде: «Чукындырылудан качып, Идел елгасы ярында яшәгән бер төркем кеше бу якларга күчеп килгән. Башта алар күрше Әлмәт авылына җир сорап барган, әмма теләләр бирмәгән. Шуннан юлны дәвам итеп, әлеге урынга килеп чыкканнар. Монда куе урман үскән. Йөри торгач, бер җирдә ачыклык күргәннәр, анда кычыткан үскән. Бабаларыбыз, сөенеп, шушы урынга килеп төпләнгән. Землянкалар казыганнар. Күрше-тирә авылларда яшәүче халык, әлеге хәлне күреп: «Кычытканлыкта кешеләр яши башлаган», – дип сөйләгән. Менә шулай итеп халык арасында Кычытканлы исеме барлыкка килгән».
Миңа калса, әлеге тарих чынбарлыкка туры килә. Татар авылларының күбесе Казан ханлыгы юкка чыгарылганнан соң барлыкка килгән. Кычытканлы да шулар рәтендә йөри, дип уйлыйбыз.

КҮККӘ КҮТӘРЕЛӘБЕЗ!

Казан – гаҗәеп урын. Бирелә самолетта, байкта, күктә, җирдә, су өстеннән, мәхәббәттән очарга була! Шәһәрне сөю очыш вакытында кичерә торган хисләрне тирәнәйтә, көчәйтә генә кебек. Чөнки бу очышлар төштә түгел, ә уяу хәлдә, чынбарлыкта бара. Тизлек, Җил, Казан һәм Мәхәббәт – тулы бәхет өчен тагын ни кирәк?! «Татарстан» журналында истәлек фотосы булса гына инде.

Фото: Александр Ефремов, Рамил Гали

2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

* Иң яхшы теләкләр белән Татарстаннан! (үзбәк теленнән тәрҗемә).

Татарстанда 8881 үзбәк кешесе яши. (2010 елгы халык санын алу нәтиҗәләре буенча).

Сентябрь аенда «Татарстан Республикасы үзбәкләренең милли-мәдәни автономиясе» Үзбәкстанның бәйсезлек алуының 30 еллыгын билгеләп үтте.